БИКЛЕ ИШЕКЛӘР

Чират – авыл фермасында

> 5

ПАРТА АРАСЫ

Татарстанда 55 мең бала беренчегә бара

> 15

БӘХӘСЛЕ БҮЛӘК

Тукай премиясе быел кемнәргә әләгер?

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 41 (29008) | Җомга | 24 март | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Анна Арахамия

БАНКАДА ТҮГЕЛ, БАНКТА

АКЧАНЫ КАЙДА САКЛАРГА?

Акча: сакларга ярамый тотарга. Өтерне кая куярга? Илдә үткәрелгән соңгы сораштыру нәтиҗәләреннән күренгәнчә, халыкның 26 проценты җыйган акчасын артык әрәм-шәрәм итмичә, банкка салмыйча, өйдә генә саклый. Белгечләр исә бертавыштан, болай эшләргә ярамый, ди. Кесәдәге акчаны нишләтергә? Заманасына күрә, иртәгәсен белгән юк дип яшәгән чорда, гомумән дә, акча җыярга кирәкме? «Финанс мендәре» астында ничә сум акча булырга тиеш? «ВТ» хәбәрчесе әнә шул сорауларга җавап эзләде.

> 6

Ишетми калмагыз

Татарстанда юка боз өстенә кергән өчен 35 кешедән штраф түләткәннәр. Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәрләре узган елның ноябреннән бирле һәр муниципаль берәмлекнең сулыкларында дежур тора. Алар балыкчыларның юка яки көпшәк бозга чыгуларын булдырмас өчен тырыша.

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстандагы Баш идарәсе белгече Регина Гаязова әйтүенчә, барлыгы 10 меңнән артыграк дежур тору оештырылган. 57 мең кешегә аңлату эше үткәрелгән. Калынлыгы 7 сантиметрдан кимрәк булган боз өстенә кергән өчен 35 балыкчы административ җаваплылыкка тартылган.

Татарстанның Ульяновск өлкәсе белән чиге турында төгәл мәгълүматлар булдырылып, Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына (ЕГРН) кертелгән. Асылда ул кырлар һәм урманнар аша уза. Гомуми озынлыгы – 380,9 чакрым.

Татарстанның Ульяновск өлкәсе белән чиге республиканың көньяк-көнбатыш территориясе аша уза. Анда Нурлат, Әлки, Спас, Тәтеш, Буа һәм Чүпрәле районнары урнашкан. Роскадастрның Татарстан буенча филиалы директоры Артем Костин сүзләренә караганда, ел азагына кадәр тагын өч чикне – Чувашия, Удмуртия республикалары һәм Киров өлкәсе белән чикләрне ЕГРНга кертү эшен төгәлләү күздә тотыла.

Рамазан аеның беренче көнендә Татарстанда «Рамазан – изге гамәлләр ае» хәйрия марафоны башланып китте. Ел саен үткәрелеп килүче акцияне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте авыру балаларга, аз керемле гаиләләр һәм мохтаҗларга ярдәм йөзеннән оештыра. Татарстан мөфтиятенең «Зәкят» хәйрия фонды быел да марафон кысасында авыру балаларга ярдәм күрсәтәчәк, мохтаҗлар өчен ифтарлар уздырачак, авыррак тормышлы гаиләләрне ризык белән тәэмин итәчәк, социаль ифтарлар оештырачак, мохтаҗлар файдасына фитыр, фидия сәдакалары һәм зәкәт җыеп таратачак. Изге эшкә кушылырга теләүчеләр тәфсиллерәк мәгълүмат белән Диния нәзарәте сайтында таныша ала.

Атна ахырында Татарстанда бик җылы һава урнаша. Гидрометеоүзәк фаразына караганда, һава температурасы +15 градуска кадәр күтәреләчәк.

Шимбә – 25 мартта төнлә һәм иртән яңгыр көтелә. Секундына 15–17 метр тизлектә көчле җил, көндез +7...+12, төнлә +3...+8 градус. Якшәмбе – 26 мартта да аз-маз яңгыр булачак. Көндез һава температурасы +10...+15 градуска кадәр җылыначак. Төнлә секундына 15 метрга кадәр тизлектә көчле җил, +3...+8 градус җылы.

Синоптикларның башлангыч мәгълүматлары буенча, киләсе атна башында да бик җылы һава сакланачак. Көндез +10...+15 градус җылы һәм яңгыр.

Сүз уңаеннан, апрель, майда, шулай ук җәйнең өч аенда Татарстанда айлык уртача температураның норма чикләрендә тирбәлүе көтелә.

Районнарда ни хәлләр?

Яшел Үзән

Район башлыгы Михаил Афанасьев телеграм-каналында Яшел Үзән шәһәренең бер урамына Сара Садыйкова исемен бирергә ниятләүләре турында язды. Татарның танылган композиторы Сара Садыйкова һәм режиссер Газиз Айдарскийның кызы Әлфия ханым белән очрашканнан соң, әнә шундый фикергә килгәннәр. «Без Әлфия Газиз кызы белән 2022 елның октябрендә Айдар авылында очраштык, анда авыл мәктәбендә күренекле кешеләрнең музей булмәсе бар. Газиз Айдарский һәм Сара Садыйкованың бабасы – тумышлары белән Яшел Үзән районыннан. Айдар авылында 1999 елда режиссер Айдарский истәлегенә беренче юбилей концерты узды», – дип язган Афанасьев.
(«Татар-информ»)

Түбән Кама

Калада 27 марттан 3 апрельгә кадәр Россиянең нефть-газ химиясе шәһәрләре театры атналыгы узачак. Сигез көн дәвамында Татарстанның милли театрлары, шулай ук Түбән Новгородның – «Комедия», Екатеринбургның – «Нитья», Мәскәүнең «Милләтләр театры» шәһәр халкына үз спектакльләрен күрсәтәчәк. Спектакльләр Түбән Камaның өч мәйданчыгында – Халык иҗаты йортында, «Җәлил» театр комплексында һәм Туфан Миңнуллин исемендәге Татар драма театры бинасында узачак. Атналык кысасында танылган җырчы Элвин Грей концерты да булачак.
(e-nkama.ru)

Арча

Рамазан ае башланыр алдыннан Көтек авылында яңа мәчет ачылу тантанасы булып узды. Әлеге күркәм чарада Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев та катнашты. Гыйбадәтханә узган ел ахырына төзелеп бетсә дә, рәсми ачылыш тантанасы рамазан-шәриф аен каршы алып үткәрелде. Мәчет төзелешенә 2021 елда Көтек авылы фермеры Дамир Шакирҗанов алына. Шул ук елны июнь аенда мәчет төзеләчәк урында кое казыла, саф чишмә суы табыла. Халык аның суын ярата, нәтиҗәдә коены мәчет эченә кертеп, елның теләсә кайсы вакытында су алырга уңайлы булсын дип калдыралар. Яңа мәчеткә берьюлы 60 кеше кереп намаз укый ала. Дини дәресләр уздыру мөмкинлеге бар, хатын-кызлар өчен якшәмбе көннәрендә дәресләр алып барыла. Хәзерге вакытта Арча мөхтәсибәтендә 93 мәчет эшли.
(Татарстан мөселманнарының
Диния нәзарәте)

Ютазы

Район башлыгы Аяз Шәфигуллин һәм «IT парк – югары технологияләр өлкәсендәге технопарк» дәүләт автоном учреждениесенең директор урынбасары Ләлә Бикчәнтәева узара хезмәттәшлек турында килешүгә кул куйды. Аяз Шәфигуллин районда IT парк филиалы ачу бурычын куйды. Мондый белекчәләр республиканың инде өч районында эшләп килә. «Киләчәк – IT технологияләр кулында. Шуңа күрә без бу юнәлештә эшләргә тиеш», – диде ул.
(«Ютазы таңы»)

ТАТАР БЕЛӘН ҺИНД БЕР ТҮГЕЛ

tatarstan.ru

Югалган кәсепләрне кайтарырга, милли киемне популярлаштырырга, халык һөнәрчелеге осталарын бер урынга тупларга. Кайтарырга тырышучыларга исә булышырга. Татарстан Рәисе каршындагы Мәдәният һәм сәнгать буенча совет утырышында киләчәкне кайгырту турында сөйләштеләр.

Хәер, Рәис Рөстәм Миңнехановка сөйләшүләрнең гамәл-нәтиҗәләре мөһимрәк иде. Сөйләшә-сөйләшә, шактый сулар акты инде. Рәис сүзләре белән әйтсәк, ата-бабаларыбыз эш белгән, без исә күбрәк сүз белән эшлибез. Ни кызганыч, югалтуларыбыз күп икән шул. Әйтик, келәм туку, сөяккә уеп язу, Чабакса чүкүе, декоратив сәнгатьнең кайбер төрләрен торгызырга кирәк. Казан музыка уен кораллары фабрикасы, Арча читек фабрикасы кебек предприятиеләрнең ишегенә йозак эленгән. Хәзер барысын да комплексы рәвештә кайтару, заманага яраклаштыру, кызыклы итү мәсьәләсе тора.

Гаеп үзебездә дә. Барысы да бик гади нәрсәләрдән башлана бит. Мәдәният министры Ирада Әюпова әйтүенчә, милли киемнәрне кимәсәк, көндәлектә борынгыдан килгән аш-суларыбызны әзерләмәсәк, савыт-саба кулланмасак, бизәнү әйберләре такмасак, туристларга гына өметләнсәк, ерак китеп булмас.

Рәиснеке дә мәдәният министры фикере белән охшаш. Бу җәһәттән Рөстәм Миңнеханов тагын бер кат Якутиягә сәфәрен искә төшерде. Республика җитәкчесе аларның Ысыах милли бәйрәмен аеруча үз итеп кайткан иде. «Безнең Сабан туе хәзер «килдем, ашадым-эчтем, биедем»гә әйләнде. Якутлар үз традицияләрен саклый. Милли бәйрәмгә барысы да милли киемнән килә. Югыйсә безнең дә Сабан туе бик тирән мәгънәле бит. Эчтәлек кирәк. Мин алардан ак көнләшү белән көнләштем. Министр дөрес әйтә. Үзебез кимәсәк, үзебезгә кирәкмәгәч...» – диде ул.

Югалтуларыбызны акларга да тырышты Рәис. Ни дисәң дә, авыр еллар кичелгән, кыйммәтләр дә башка төрле булган. Шулай да кәсепчелек белән ата-бабаларыбыз кебек шөгыльләнә алмаячагыбыз көн кебек ачык. «Без алар эшләгән кадәргә якын да килә алмыйбыз. Алар остарак булган димме соң?! Музыка уен кораллары, зәркән эшләнмәләр, дисеңме. Без күбрәк сөйләшергә яратабыз шул. Торгызырга кирәк, әлбәттә. Әмма ул волонтерлык хәрәкәте дәрәҗәсендә генә булмасын иде», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Димәк, белмәгәннәрне укытырга, осталарның осталыкларын камилләштерергә, эшмәкәрләргә мөмкинлекләр бирергә, сатарга өйрәтергә кирәк.

Белем бирү дигәннән, республикада 13 балалар сәнгать мәктәбе, Фешин исемендәге училище эшли, техникум бар. Тик бу гына җитәме икән? Балалар бакчасы, гаилә, мәктәп тә бар бит әле. Бу уңайдан «Адымнар» мәктәбен үрнәк итеп куйдылар. Балалар анда халык кәсепләренә дә өйрәнә.

Өйрәтү дигәннән, мәдәният министры әйтүенчә, районнардагы мәдәни-ял итү учреждениеләрендә бу юнәлештә күчмә уку оештыру нияте дә бар. Ә инде осталарны өйрәтү дигәндә, аларга маркетолог, дизайнер ярдәме кирәк. Еш кына кулы һөнәр белгәннәр икътисад базарындагы үзгәрешләрне чамалап бетермәскә дә мөмкин бит. Әмма, Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, өйрәткәндә дә кәсепнең табыш китерә торган булуын аңлатырга кирәк.

Рәис Рөстәм Миңнеханов исә, барысын да берләштергән үзәк кирәк, ди (IT парк, Химград кебек). Хакимиятләгеләр инде урынын да тапкан бугай.

– Һөнәрчеләргә шартлар тудырылган мәйданчык кирәк. Анда алар эшләсен дә, өйрәнсен дә, тәҗрибә дә алмашсын. Шунда ук сату эшен дә көйләргә була, – ди ул.

Утырышта Ирада Әюпова һөнәрчеләрне һәм үзен борчыган тагын бер мәсьәләне күтәрде. Ул да булса – патент алу. Мәдәният министры китергән мәгълүматка карасаң, республикада патент алу хакы 58767 сум икән. Чагыштыру өчен: Мәскәүдәгеләр моның өчен 29836 сум түли. Финанс министрлыгының утырышта катнашкан вәкиле моны салым салуның гадиләштерелгән системасына күчү белән аңлатты.

Министр куллары һөнәр белгән кешеләргә мактаулы исем бирү турында да хыялланa. Шундый дәүләт бүләген оештырып булмасмы, дип сорады Ирада Әюпова Рәистән. Чыннан да, исемле булу – азмы-күпме, стимул инде ул.

– Мин сине мактармын да, мине мактадылар дип, тынч кына кайтып китәрсең, – диде Рөстәм Миңнеханов утырыш ахырында министрга. – Тик, асылда, мин сезне шелтәләргә тиеш идем. Инициатива юк. Артта калган тармакларыбыз күп. Без ата-бабаларыбыз шөгыльләнгән кәсеп белән шөгыльләнергә тиеш, бу – безнең үзенчәлегебез.

Сүз уңаеннан, чара башында Ирада Әюпова, кайбер осталар белән күптән түгел Һиндстанда булып кайтуын әйтте: «Фәридабадтагы зур ярминкәдә үзебезнең сәнгатебезне тәкъдим иттек, анда 45ләп ил үз продукциясен китерә икән. Продукциянең күп өлеше эчке куллануга юнәлдерелгән. Туристлар һәм продукцияне үзебездә куллану бер-берсен тулыландырырга тиеш».

Рөстәм Миңнеханов исә: «Һиндстан дисең дә син, алар бит – миллиард ярым. Без азрак», – диде. Татар белән һинд бер түгел шул. Безгә әле миллилекнең дә актуаль икәнен, искелек калдыгы түгеллеген аңыбызга сеңдерү кирәк иң элек.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

2023
ГОД НАЦИОНАЛЬНЫХ КУЛЬТУР И ТРАДИЦИЙ
МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР ҺӘМ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ЕЛЫ

САН

Зәркән, күн әйберләр, бижутерия, музыка кораллары җитештерү юнәлешендә эшләүче 1,5 меңнән артык кече һәм уртак бизнес субъекты бар. Бары тик 41е генә «халык сәнгате кәсепләре» буларак теркәлгән. Шуларның 13е социаль предприятие статусын рәсми рәвештә раслаган.

Белгечләр республикада традицион халык кәсепләренең һәм һөнәрләренең 11 төрен теркәгән. Элек бу сан 35тән артык булган.

Тамашачы булсын

Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театры режиссеры Айдар Җаббаров, илнең театр сәнгатенә зур өлеш кертүе өчен, Россия Президентының яшь мәдәният әһелләренә бирелә торган премиясенә лаек булды.

Бүләкләү тантанасы Кремльдә узды. Россия Президенты Владимир Путин кулыннан дәрәҗәле бүләк алган яшь режиссер сүзен рәхмәт әйтүдән башлады.

– Иң беренче чиратта туган ягым Татарстанга рәхмәт әйтәсем килә. Үзем эшләгән татар театры – Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театрына, аның сәнгать җитәкчесе Фәрит Бикчәнтәевкә, Татарстанның мәдәният министры Ирада Әюповага, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановка рәхмәт белдерәм. Республикада театр сәнгате үсешенә зур игътибар бирелә. Татарстанда «юк» дигән сүзне, гомумән, белмиләр. Барлык иҗади башлангыч тәкъдимнәрне барлык дәрәҗәдә күтәреп алалар. Монда хезмәт куюым белән бәхетлемен, – диде ул үз чыгышында.

Россия Президенты белән рәсми булмаган сөйләшүдә Айдар Җаббаров кайбер төбәкләрдә эшләп килгән милли театрларга, халыкны җәлеп итү өчен, спектакльләрне рус телендә куярга туры килүен дә искәртте.

– Мин үзем өчен яңа татар авторларын ачарга ратам. Әле бер тапкыр да сәхнәдә куелмаган татарча проза әсәрләре бихисап. Аңлыйсызмы, Татарстанда театр – театр гына түгел, – диде яшь режиссер. – Кайбер күрше төбәкләргә карыйм да кызганып куям. Алар, план тутыру өчен, спектакльләрне рус телендә генә уйнарга мәҗбүр. Татарстанда исә «Нәүрүз» фестивале бар. Анда спектакльләрне татар телендә генә уйнамыйлар. Чеховны якут телендә куйсалар, кызык бит инде!

Яшь режиссерның фикерен Президент та куәтләде. Владимир Путин Россиядә телләр төрлелеген саклау юлларын табарга кирәклеген искәртте.

– Сез хаклы, бу бик мөһим. Советлар Союзы таркалганнан соң милли телләрне саклау ягыннан югалтулар күп булды, – диде Путин. – Яңа формалар табарга кирәк. Сез сорау аз дидегез, миңа калса, эш шундадыр да. Базар мөнәсәбәтләрендәге кебек үк монда да сорау тәкъдимне тудыра. Сорау юк, халык театрга йөрми икән – тынлык дигән сүз.

БУЛМАГАННЫ ЭЗЛӘМӘГЕЗ

Парламентның 42 нче утырышына да гадәт буенча иртәрәк килдем. Сессия утырышына кагылышлы документлар белән алданрак танышсаң, язасы да ансат була.

Сәгать тугыз да тулмаган, ә Дәүсовет бинасы каршында бер пикетчы басып тора иде инде. Кулында «Депутатов – сепаратистов в отставку!» дип язылган кызыл ситсы. Әй, энем җаным, безнең депутатлар арасында сепаратистларны табып буламы соң инде! «Долой» дисәң дә, димәсәң дә, юк арабызда аерылып чыгарга теләүчеләр. Без гомер буе ил белән бергә инде. Безнең татар аерылганны – аю, бүленгәнне бүре ашаячагын белә. Энем, депутатларны отставкага китәргә чакырган кызыл чүпрәгеңне бер читкә куеп, Дәүсовет утырышына кереп утырсаң, безнең бердәмлекнең ни дәрәҗәдә нык икәнен үзең дә күргән булыр идең!

Утырышка мин әнә шундый якты уйлар белән кердем һәм чыгыш ясаучыларны тыңлаганда, дөрес уйлаганмын, дип куанып та утырдым әле. Көн тәртибендәге өч дистә чамасы мәсьәләне тикшергәндә, ник бер тавыш-гауга чыксын. Юкса үзара бәхәс куптарырлык мәсьәләләр бар иде. Мәсәлән, Татарстанның аерым закон актларына үзгәрешләр кертүгә кагылган закон проектларын гына алыйк. Алар, нигездә, үзебезнең законнардан, Конституциябездән «суверенлык» дигән төшенчәнең алып ташлануына кагылышлы иде. Моңа каршы да килә алмый идек, чөнки ил Конституциясе буенча, бәйсез Россия эчендә бәйсез төбәкләр, ягъни катлы-катлы суверенлык була алмый. Без моңа артык борчылмадык, чөнки бәйсезлек дигәннәре инде күпмедер дәрәҗәдә кәгазьдә генә саклана иде. Шулай итеп, Татарстан законнарында «дәүләт суверенитеты» дигән язулар бетте, аның каравы «дәүләтчелек» дигән сүз калды. Дәүләтчелек символы булган гимныбызга, флагыбызга, гербка кул тидермәделәр.

Соңгы елларда депутатларыбызның үзебезнең законнарны федераль законнар белән тәңгәлләштереп-яраштырып утыруларына ияләшеп беттек инде. Традицияләр бу утырышта да бозылмады. Шәхсән үземнең федераль хакимияткә, Россия Думасына рәхмәт тә әйтәсе килеп киткәли әле. Мәскәү безгә эшне җиңеләйтте, төн йокыларын калдырып, нервылар бетереп, яңа законнар уйлап табасы юк. Бер илдә бер үк законнар белән яшәми кая барасың?!

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Ирина Волынец чыгышын тыныч кына тыңлый алмадым. Балалар арасында үз-үзләренә кул салу очракларының 100 процентка артуын әйткәч, куркыныч булып китте. Нинди зәхмәт бу, сәбәпләре нинди? Бу – гаять җитди мәсьәлә һәм бер утыруда гына язып-аңлатып бетерерлек түгел.

tatarstan.ru

Дәүләт Советында «Татар-информ» агентлыгы фотохәбәрчесе Михаил Захаровның Луганск Халык Республикасында фронт буендагы шәһәрләрдәге тормышны чагылдырган «Да все нормально у нас...» фотокүргәзмәсе эшли башлады. Парламент башлыгы Фәрит Мөхәммәтшин агентлыкка һәм Михаил Захаровка кыюлыгы һәм тарихи сурәтләрне күрү мөмкинлеген тудырганы өчен рәхмәт белдерде. «Бу фотосурәтләрне күбрәк кеше күрергә тиеш», – диде Дәүләт Советы Рәисе.

Ә менә гаиләләрдә бала хокуклары бозылуын, мондый гаиләләрнең, нигездә «шайтан суы» корбаннары булуын әйтсәк, кайбер сәбәпләре аңлашылыр. Халык телендә «Бала табу – бер мәшәкать, бала тәрбияләү – мең мәшәкать» дигән әйтем бар. Бүген бала тәрбияләү күп кенә гаиләләр өчен мең мәшәкатькә әйләнгән, ахрысы. Шушы мәшәкатьләр бүген шактый ук дәрәҗәдә хөкүмәт җилкәсенә төшә. Вәкил ханым гаилә кыйммәтләрен, күркәм традицияләрне саклау, бала тәрбияләүдә ата-ананың җаваплылыгын арттыру өчен йөри. Моның ише изге эшләр башкару үзебезнең кулда инде. Дөрес, безнең бер күзебез үзебезгә төбәлгән булса, икенчесе белән Мәскәү ягына караштыргалыйбыз. Мин Татарстан парламентының закон инициативалары белән Россия Думасына еш мөрәҗәгать итүен күз алдында тотам, «айт» дигәнгә, «тайт» дип кенә утырмыйбыз, диюем.

Бу утырышта да Дума рәисе Вячеслав Володинга мөрәҗәгать юллау кирәклеге турында сөйләштеләр. Социаль сәясәт комитеты рәисе Светлана Захарова әйтүенчә, сирәк авырулардан азапланучы гражданнарны дарулар белән тәэмин итүне федераль үзәк үз өстенә алырга, ягъни дарулар өчен акча федераль казнадан бирелергә тиеш. Захарова мондый вәкаләтнең «Россия Федерациясе гражданнарының сәламәтлеген саклау нигезләре турында» федераль законда языганын да искә төшерде. Парламент рәисе Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, Татарстан мөрәҗәгате хуплансын өчен, бездән сайланган Дума депутатлары да үз сүзен әйтергә тиеш. Фәрит әфәнде шәхсән үзе дә, Дума рәисе Вячеслав Володин белән очрашып, шул хакта сөйләшергә ниятләп тора икән.

Без һәр эшкә бергәләп тотынырга, бергәләп эшләргә өйрәнгән халык. Мәсәлән, Россия төбәкләренең шактые санкцияләр авырлыгыннан сыгылып төшкәндә, без үсешкә – үзгәрешкә атларга омтылдык. Утырышта эшмәкәрләр хокукын яклау буенча Татарстан Рәисе каршындагы вәкил Фәрит Габделганиев чыгыш ясаган иде. Соңгы өч елның безнең эшмәкәрләр өчен авыр сынау елы булуын әйтте үзе, әмма зарлану шуның белән тәмамланды. Без кече һәм урта эшмәкәрләктә тотрыклылык саклап кына калмаганбыз, бу бизнес вәкилләренең санын арттыруга да ирешкәнбез. Саннар белән әйтсәк, быелның март аена эш кешеләре саны моннан алдагы ел белән чагыштырганда 4 меңгә арткан. «Бу – эшмәкәрлекнең теләсә нинди шартларга тиз арада яраклаша алуына бер дәлил», – дигән иде Фәрит әфәнде. Әлбәттә, барысы да ал да гөл бара дигән сүз түгел, вәкилнең кабул итү бүлмәсенә эшмәкәрләрдән мөрәҗәгатьләр килә тора икән.

Әмма аларның саны кимүгә бара. Димәк, эшмәкәрләрне борчыган сорауларны үз вакытында хәл итәргә тырышалар дигән сүз. Шул ук вакытта Фәрит әфәнде дәүләт хакимияте һәм җирле хакимият органнарының тиешенчә эшләп бетермәвен дә яшермәде. Бөтен мөң-зарларның 26 проценты түрәләрдән канәгатьсезлеккә бәйле икән. Икенче урындагы зар (24%) гамәлдәге законнарны аңлау һәм аңлата белмәүгә бәйле. Эшмәкәрләр республика җитәкчелегә, хокук сагында торучылар белән очрашып торалар икән үзе, әмма йә файдалы очрашулар саны кимрәк, йә эшмәкәрләргә биргән вәгъдәләр үтәлеп җитми булып чыга инде. Ә административ басымга килгәндә, вәкил әйтүенчә, бу һаман да дәвам итә икән әле. Бездә генә түгел, бөтен илендә шул хәл икән. Бергәләп тотынсалар, бу «зәхмәт»не дә җиңәрләр, дип ышаныйк. Бүген Татарстан икътисадында кече һәм урта эшмәкәрлекнең өлеше, үзмәшгульләрне дә кертеп, 42 процент, диделәр. Бу – 828,5 мең эш урыны дигән сүз. Шәп бит! Фәрит Габделганиев эшмәкәрләрнең заманның бөтен кыенлыкларын җиңеп барасына ышана. Әлбәттә инде, алар дәүләт кайгыртуын тоеп эшләсә, кайбер түрәләр аяк чалмаса.

Ә кызыл чүпрәк тоткан теге егет сепаратизм эзләмәсен. Юк ул бездә, кемнең аерылып чыгып китәсе, киресен сукалап утырасы килсен. Бигрәк тә бүгенге катлаулы заманда, диюем.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Үсешкә таба юл

«Былтыр Россиягә моңарчы тарихта булмаган дәрәҗәдә басым ясалды». Россия Дәүләт Думасында ил Хөкүмәтенең узган елгы эшенә еллык хисап белән чыгыш ясаганда, Премьер-министр Михаил Мишустин әнә шулай диде. Илнең нык басып торуына ышаныч та белдерде.

– Россиягә моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә басым ясалды. Әйе, безне башта, бу халыкка каршы эшләнми, дип тә ышандырырга тырыштылар. Тик бүген зур сәясәттән ерак булган кеше дә аңлый: Көнчыгыш боларның барысын да нәкъ менә россиялеләргә каршы эшләде. Халык банк карталарыннан файдалана алмасын өчен, банк системасын җимерергә теләделәр. Кибет киштәләре бушап калсын өчен, үз компанияләрен илдән китәргә мәҗбүр иттеләр. Шул исәптән, ябылырга мәҗбүр булган оешмаларда эшләүче россиялеләрне урамга чыгарып атып, аларны акчасыз да калдырырга теләделәр. Үзләренә үк миллиардлаган суммада керем китерүче эшчәләр бит бу. Кыскасы, илдәге эшсезлек дәрәҗәсен арттырып, бездә тормыш сыйфаты түбән тәгәрәгәнне көттеләр, – диде Премьер-министр.

Аның әйтүенчә, әнә шундый һөҗүмнәргә каршы тору өчен, Хакимият органнарына бер йодрык булып эшләргә туры килгән. «Россия Президенты җитәкчелегендәге уртак тырышлык нәтиҗәсендә, былтыр алда торган барлык бурычларны да хәл итә алдык», – диде Михаил Мишустин.

– Узган елның язында белгечләр, Россиядә эчке тулай продукт күрсәткече икеурынлы саннар белән кимеячәк, дип фаразлаган иде. Әмма без бирешмәдек. Әйе, бу җиңел булмады. Мондый шартларда түбән тәгәрәү дә бик мөмкин хәл иде. Без исә икътисадны үсеш юлына чыгара алдык. Хәзер хәтта кайбер халыкара оешмалар да безгә 2023 ел нәтиҗәләре буенча уңай фаразларын җиткерә, – диде Премьер-министр.

Ул илнең банк системасы тотрыклы булуын да билгеләп үтте. Товарлар һәм хезмәтләр өчен түләү, акча күчерүгә бәйле операцияләр элек ничек башкарылса, хәзер дә шулай. Банк карталары да үзгәрешсез эшли.

2022 ел нәтиҗәләре буенча, Россиядә илкүләм проектларның үтәлеше 100 процентка кадәр җиткән. Димәк, хастаханәләр, мәктәпләр, балалар бакчаларын вакытында сафка бастырганнар. Михаил Мишустин илдә социаль тармакка зур әһәмият бирелүен аерым билгеләп узды. Киләсе елның 1 гыйнварыннан Россиядә хезмәт өчен минималь түләү күрсәткечен 18,5 процентка арттырачаклар. Моннан ары ул инфляция дәрәҗәсеннән күбрәк булып артып барачак, дип тә ышандырды Премьер-министр. Узган елның 1 апреленнән 8дән алып 17 яшькә кадәр бала тәрбияләүче аз керемле гаиләләргә ярдәм шартлары киңәйтелде. Пособиенең уртача күләме 12 мең сумга кадәр җитте. Былтыр ил күләмендә 5 миллионнан артык бала тәрбияләүче 3,5 миллион гаилә әлеге төр ярдәмнән файдаланган инде. Тагын 1,3 миллион гаилә ана капиталы акчасын алган. Соңгысына бәйле үзгәреш тә бар. Хәзер ана капиталын элеккеге кебек фаразланган инфляция күрсәткечнә карап түгел, ә чынбарлыктагы саннар буенча арттыралар. Быел 1 февральдә, мәсәлән, ул 12 процентка диярлек үсте. Өлкәннәргә дә ярдәм бар. Узган ел Илбашы Владимир Путин кушуы буенча, эшләмәүче пенсионерларның иминият акчасы бер ел эчендә ике тапкыр индексацияләнгән. Шул рәвешле, былтыр аның күләме якынча 3 мең сумга артып, 20 мең сумлык чикне узып киткән. Былтыр илдә 3,5 миллион гаилә яшәү шартларын яхшырткан. 2022 елда рекордлы мәйданда – 103 миллион квадрат метр торак кулланышка тапшырылган.

– Торак мәсьәләсен хәл итүнең төп ысулы – ипотека, әлбәттә. Былтыр яңа йортларда фатир сатып алуга бәйле барлык килешүләрнең дүрттән өч өлеше банк ярдәмендә башкарылган, – диде Михаил Мишустин.

Иртәгәге көн турында сөйләгәндә: «Башка илләрнең Россиягә басымны киметүләре шикле», – диде ул. Моңа да карамастан, 2024 елда ил икътисадының, хәзерге шартларга яраклашып, яңа үсеш юлына чыгачагына ышаныч белдерде.

2023 елда Хөкүмәт алдында торган өстенлекле юнәлешләр:

- ✓ халыкны саклау;
- ✓ илдә яшәүчеләрнең матди хәлен яхшырту;
- ✓ технологик суверенитетны ныгыту;
- ✓ илнең финанс суверенитетын тәэмин итү;
- ✓ транспорт инфраструктурасын үстерү;
- ✓ безгә теләктәшлек белдергән илләр белән элемтәләрне ныгыту, яңа хезмәттәшләр эзләү.

Әйтеп кенә бактым

Каргыш

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Бу язманы укыгач, кайберәүләр: «Шыттырып та караган инде, андый хәл була алмый», – дияр. Әгәр күптәнге дустым сөйләмәгән булса, мин дә әлеге вакыйганы «уйдырма» дип бәяләр идем. Кыскасы, «халык дошманнары»на каршы аяусыз көрәш барган елларда, шул ук халык арасында бер-берсенә яла ягып, төрмәгә утырттыручылар да табыла. Һәм, тарихи мәгълүматлар буенча, нахак яла ягылып, Себергә сөрелү очраклары шактый булган. Мәсәлән, танылган җырчыбыз Габделфәт Сафинның әтисе Габдрахман абыйның да шундый язмышка дучар булуы турында үземнең дә язганым бар. Аны лагерьда вакытта җәлилчеләр белән танышып, совет властена каршы корткычлык эшләре алып баруда гаепләп, 25 елга хөкем итәләр. Суд утырышында фашист лагеренда Габдрахман абый белән бергә иза чиккән «шаһит» та катнаша. Ә Габдрахман абзыйның бу кешене бөтенләй күргәне дә, белгәне дә булмаган.

Минем язмамның геройлары исә – яла ягучы һәм бу яладан зыян күргән ике нәселнең вәкилләре. Алар яшь әле, моннан биш ел элек өйләнешеп, бәхетле тормыш башлаган Зәлия белән Самат. Чын исемнәрен язмауның сәбәбен аңлыйсыздыр инде. Бүген шушы ике нәсел туганлашып яши. Ә бит Зәлиянең бабасы Шакир абзый «Сталинга каршы сөйләп йөргән өчен» Себер киткәч, аның хатыны Мәймүнә Саматлар нәселен, җирдә тәгәри-тәгәри: «Сезнекеләр белән каберләребез дә якын булмасын иде!» – дип такмаклый-такмаклый каргый. Саматның бабасы Гарифҗан Зәлиянең бабасы Шакирга ни өчен шундый этлек эшләгән – бүген моны тәгаен генә әйтүче юк. Сөйләүләренә караганда, Гарифҗан белән Шакир бер үк кызны – Мәймүнәне яратып йөргәннәр. Мәймүнә Шакирны сайлагач, Гарифҗан аннан үч алу өчен җай гына көтеп йөргән. Инде илдә «халык дошманнары»н фаш итү башлангач, Гарифҗан моннан файдаланып калырга, Шакирны «кызык итәргә» теләгән. Мәймүнә өч бала белән тол калган. Гарифҗанның да балалары булган, дустым әйтүенчә, алтау. Әмма Шакир Себердә вафат булганнан соң, бу нәселгә кырау төшә, алты баланың бишесе төрле зәхмәтләрдән үлә. Самат – исән калган бер баланың дәвамчысы инде.

Еллар узгач, һәр ике як тынычланган кебек була, бабалары белән булган хәлләр турында балаларына сөйләмиләр. «Сезнекеләр белән каберең якын булмасын!» – дип каргаган Мәймүнәнең оныгы Зәлия белән Гарифҗан оныгы Самат исә бер-берсенә үлеп гашыйк булалар һәм гаилә корып җибәрәләр.

Укучымны, әлбәттә, бу гыйбрәтнең ничек тәмамлануы кызыксындырадыр. Мин дә дустымнан: «Шуннан, шуннан?» – дип сорый-сорый сөйләттем.

– Шуннанмы? Әйтсәм, ышанмассың инде, Зәлия белән Самат бер караганда бәхетле яши кебек. Тик менә аларның ике баласы үлде инде. Беренчесенә өч яшь иде, икенчесенә яшь тә тулып өлгермәде. Зәлия хәзер өченче балага йөкле, – диде ул. «Каргышка ышанасыңмы?» – дип сорасалар, бераз ык-мык итеп торырмын кебек. «Каргыш» дигән сүз белән бик шаярасы килми. Әмма кешене рәнҗетүнең зур гөнаһ икәнен беләм. Безне шулай тәрбияләделәр. Әбием Мәүлиха без бала чакта ук: «Кешегә авыр сүз әйтмә, кешене рәнҗетмә, рәнҗеше үзеңә кайтыр», – дип кабатларга ярата иде. Әти укытучы, коммунист булса да, әнисе Мәүлиха диннең бөтен йолаларын үтәп яшәде. Кыскасы, атеизм безнең йортка үтеп кермәде. Әби әле: «Кешене каргамагыз, Аллаһы Тәгалә барын да күреп тора ул, үзе җәзасын бирер», – дип тә әйткәли иде. «Алла каргаган нәрсә» дигән сүзнең килеп чыгуы да, бәлки, нәкъ шуңа бәйледер. «Тегенди булыгыз, мондый булыгыз…» – дип акыл өйрәтәсе килми. Мин тормышта чыннан да булган бер вакыйга турында гына сөйләдем, нәтиҗәне үзегез ясарсыз. Ә Зәлия белән Саматка килгәндә, аларның һәм туарга тиешле баланың язмышы белән кызыксынып торырмын һәм, җаен китереп, берәр язмамда телгә алырмын әле.

ГЛОБАЛЬ СИСТЕМАЛАР ЧАЙКАЛГАНДА

Телефоныма көн саен Бөек кризисның дәһшәтле эпизодларын чагылдырган дистәләгән хәбәр килә. Кичә генә иярдә булган һәм гаҗәп зур бонуслардан файдаланган банкирларны тынычсызлык биләп алды, Җир шарының Сингапурдан алып Лондонга, Нью-Йоркка кадәр киң мәйданында хед-хантерларны эш сорап йөдәтәләр. «Аллаһның һәр бирмеш көнен мин кире кагулар белән каршылыйм», – дип сөйли «ТикТок»та Уэсли Анна исемле америкалы синьор-дизайнер. Соңгы көннәрдә генә дә ул вакансияле йөз урынга үзен тәкъдим итеп караган, әмма бер җирдә дә эш бирмәгәннәр.

«Профессиямдә мин яңа кеше түгел, ун еллык стажы булган дизайнер», – ди хатын үзе турында һәм дөньякүләм технологик гигантларда уңышлы эшләвен искә ала (искәртеп үтик: синьор-дизайнер дип интернет проектларда эшләүче тәҗрибәле аерым бер каста белгечләрне атыйлар). Аның ролигы астына үзен бер ел элек кенә өстен катлауга керткән белгечләр үзләренең дә шундый ук проблемалар белән очрашуларын язалар. Цифрлы технологияләр өлкәсендә эшләүче белгечләрне бүген бизгәк тота, чөнки, бердән, технологик стартапларны финанслаучы банклар җимерелү аркасында, эш урыннары кинәт кыскарды, икенчедән, мәйданга программистларны алыштырырга тиешле ясалма интеллект – GPT-4 чыгып килә һәм айтичыларны гына түгел, бухгалтерларны, копирайтерларны, фотографларны эшсез калдырырга вәгъдә бирә. Ул хәтта кешелек җәмгыятен һәлакәткә китерәчәк, дип тә куркыталар.

Әмма әлегә бик зәгыйфь ул. Рөстәм Миңнеханов турында татарча шигырь язарга кушкан биремне менә болайрак үтәде: «Рустам Минниханов, Йыртылы баштанын теле. Туган теле Татарстан, Ул теле, ул өлкәсе». Татарча үзенең сай йөзүен тиз чамалады тагын, кушканны да көтмичә, русчага күчте. «Он бережет свой народ, Стремится к развитию, Сердце полно любви, К Татарстану и народу своему». Эчтәлеге шәп, әмма иң начар графоман да моннан яхшырак яза, билгеле. Гади генә программа язарга дигән биремне дә хата белән башкарды, хатасын күрсәткәч, төзәтте тагын үзе. Димәк, ясалма интеллектка программачыларны да, язучы-журналистларны да алыштырырга иртәрәк әле.

Югары технологияләр өлкәсе белгечләре бүген кычкырып эшсез кала икән, бу – соңгы көннәрнең шау-шулы финанс түнтәрелеше нәтиҗәсе. Глобаль капитализмның түнтәрелеше исә бу юлы үткән гасырның Бөек депрессиясен узып китәр кебек, чөнки берничә кризис бер йомгакка төйнәлә: валюта кризисы (ышанычлы акча булмау), финанс кризисы (банкларның бурычларын түли алмыйча җимерелүе, бюджет дефицитларының прогрессия тәртибендә үсүе), демографик кризис (хатыннар бала табарга теләмиләр я таба алмыйлар), әхлак кризисы (акыл һәм әхлак бетү). Боларга климат кризисы һәм физик параметрларда гасырлар буе яшәгән балансның югалуын да өстәргә кирәктер, мөгаен, чөнки зур табигый катастрофаларның артачагын алдан белгертә.

Капитализм түнтәрелеше фронтларыннан берничә хәбәр карыйк әле. Франция нефть продуктларының стратегик запасын эшкә җикте, чөнки пенсия реформасына протест йөзеннән, нефть эшкәртү заводлары эшчеләре эш ташлады. Илнең Энергетика министрлыгының рәсми мәгълүматы бу. Сишәмбе көнне (бу юллар чәршәмбе иртәсендә языла) 700 ягулык салу станциясендә ягулыкның бер төре дә юк иде, 852 заправкада бензин һәм дизель ягулыгы кытлыгы күзәтелә.

Америка бигтехы (иң эре технологик компанияләр җыелмасы) табышының кискен түбәнәйгәнен хәбәр итә чәршәмбе иртәсенең биржа яңалыклары. Шул ук сәгатьләргә Америка банкларының 600 миллиард долларлык активларын югалтулары турында мәгълүмат та килеп иреште. Бу – атна-ун көн югалтулары. Еврозона һәм Япониянең сәүдә баланслары нык түбәнгә китүе хакында хәбәр дә шуларга килеп ялгана.

Швейцария профсоюзлары Credit Suisse һәм UBSтан («эштие суынган» Швейцар банклары икәнен искәртәм вакыйгалардан хәбәрдар булмаганнарга) эш урыннарын кыскартуны туктатуны таләп итә, чөнки дистәләгән мең кеше эшсез кала. Вазгыять швейцар франкының курсын гына түгел, абруен да төшерде. Хәзер кайчан гына финанс тотрыклылыгы утравы булып саналган бу илгә инвесторлар «финанс банан республикасы» буларак кына карыйлар, дип хәбәр итә икътисад күзәтүчеләре. Цюрихта Credit Suisseның штаб-квартирасы янында демонстрантлар җыелды, «Революция!», «Байларны аша!» – дип кычкыралар, бинага чи йомыркалар ыргыталар. 1917 елның көзендәге Петроград дип әйтерсең.

Бу вакыйгалар миңа нәрсәне хәтерләтә, беләсезме? 1991 елгы Россияне. 31 ел элек булган вакыйгаларга – март аена әйләнеп кайтыйк әле. 13 март, 1991 ел. Илдә – шахтерлар фетнәсе. Дүшәмбе көнне 16–17 шахта эш ташлаган. Сишәмбедә аларның саны 45кә җиткән. Пәнҗешәмбедә (югарыда күрсәтелгән дата) – 50. Күмер чыгаручылар Горбачевның отставкага китүен, хезмәт хакларын 2–2,5 тапкыр күтәрүне таләп итәләр.

20 март, 1991 ел. Күптән түгел генә СССРның Министрлар Кабинеты колхозларга ашлык тапшырган өчен чиратсыз җиңел автомобиль алу хокукы бирүче карар кабул иткән. ГАЗ-2410 «Волга» машинасын чиратсыз алу өчен – 500 тонна, «Москвич-2141»кә – 400 тонна, йөк автомобиленә – 350 тонна, экскаваторга 300 тонна ашлык сатарга кирәк. Кызыклы валюта, шулай бит? Хәзер мин сезгә исәпләп күрсәтәм. Бер центнер ашлыкның дәүләт бәясе ул чакта 10 сум иде, дип хәтерлим. Ул бәягә ирекле рәвештә ашлык сатып ала алмыйсың, билгеле. ГАЗ-2410 «Волга» машинасы өчен 50 мең сумлык ашлык тапшырырга кирәк. «Волга»ның дәүләт бәясе исә 16 мең сум иде. Ашлыкның базар бәясен куйсак, 125 мең сумнар тирәсе килеп чыга. Аңлашыла инде: ашлык тапшырып, «Волга» алган бер генә колхозны да белмим мин. Министрлар Кабинеты дәүләт ресурсларына ашлыкны авылдан валютага сатып алу турында да карар кабул иткән. Ашлык тапшыручылар булгандыр, мөгаен, валюта алучылар гына күренмәде.

28 март, 1991 ел. 300дән артык җиңел сәнәгать предприятиесе эштән туктады, чөнки парча һәм ситец (безнеңчә ситсы) дигән тукымалар юк. Әле генә складлар тулып яткан тукымаларның кая китүен СССР министры аңлата алмый.

28 март, 1991 ел. РСФСР Халык депутатларының чираттан тыш III съезды җыелган һәм СССР Министрлар Кабинетының митингларны вакытлыча тыю турындагы карарын юкка чыгаручы 3 пункттан торган карар кабул иткән. Горбачев, ул карарны хөрмәт итеп, Мәскәү урамнарын тутырган хәрби техниканы чыгарырга фәрман биргән. Үзәк хакимиятләрнең митингларны йөгәнләргә тырышуы аңлашыла, чөнки 22–24 февральдә Мәскәүдә миллионнан артык кеше урамга чыккан.

Социалистик системаның соңгы ныгытмасы булган СССРның җимерелү хроникасын шушы урында туктатып торам. Миңа калса, глобаль капитализм да социалистик система артыннан кабергә таба юл ала. Симптомнар бер үк: акчага ышаныч бетеп килә, финанс системасы җимерелү алдында, Көнбатышның мактанычы булган социаль яклау чаралары киметелә һәм юкка чыгарыла, халык вазгыятьтә гаепле дип саналучыларны «ашарга» тели, урамнарга чыга, забастовкалар ишәя. Беләм, әйтергә телисез: андый хәлләр капитализмда элек тә еш булды бит инде. Сез хаклы, әлбәттә, әмма бу юлы кризистан чыгу юлы юк, алда тупик тора. Путин доллар системасының табут капкачына юань кадагы кагарга тели әнә: Латин Америкасы илләре белән чин валютасында сәүдә итмәкче була. Гарәпләр тарихта беренче тапкыр юаньда кредит рәсмиләштерделәр. Юань доллардан яхшыракмы? Юк, киресенчә… Ә ни өчен сумнарда түгел? Путин ва-банкка бара һәм хәвефле-куркыныч юл сайлый. Пекин биргән карт-бланш кына җитми бу адымны ясау өчен. Инициатива Көнбатыш – Россия конфликтын котылгысызлык дәрәҗәсенә үстерә. Мәсьәләне тагын бер нәрсә катлауландыра: Кытай да, Россия дә, Согуд Гарәбстаны да – глобаль капитализмның состав өлешләре. Бина җимерелгәндә, түбәнге катларның исән каласына гарантияне беркем дә бирми һәм бирә алмый да. Нигез чатнаган һәм ишелә икән, йорт тулысынча җимерелә. Берничә ел калтырау һәм турбулентлык шартларында яшәрбез, мөгаен. Вакыйгалар без уйлаганга караганда да тизрәк әйләнә башларга да ихтимал. Көтик һәм, Аллаһ теләсә, язганны күрербез. Романнарга тиң вакыйгалар эчендә яшибез, әмма бу бер дә сөендерми.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Зөһрә САДЫЙКОВА

ТОТКАСЫЗ АВЫЛ



«ВТ» архивыннан

Без еш кына, мәктәпсез авылның киләчәге юк, дип әйтергә күнеккән. Мәктәп янына терлек фермаларын да өстәргә кирәк, чөнки ул – табыш чыганагы да, авыл тоткасы да. Аларның ишеген кадаклау халык тормышында, авылның киләчәгендә ничек чагылыш таба? Шул турыда фикерләшәбез.

Эшсезлек

Җитәкчеләр зур инвестиция проектларының, мегафермаларның икътисадый яктан отышлы булуы турында әледән-әле әйтеп килә. Әйтик, узган ел авыл хуҗалыгында хезмәт җитештерүчәнлеге, 25 процентка артып, 3,8 млн сумга җиткән. Югары технологияләр кулланып эшләүче компанияләрдә ул 10 млн сумга җитә, ә уңышлы агрофирмаларда бер кешегә 5 млн сумнан артып китә. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров сөт җитештерү күләме артуны да яңа инвест-проектларны тормышка ашыруда күрә. Узган ел республикада 18 мең сыерга исәпләнгән 24 яңа сөт комплексы төзелгән. Быел тагын 15,5 мең баш сыерга 22 проект гамәлгә ашырылачак. Министр зур комплексларда эшләүчеләрнең хезмәт хаклары да башкаларныкы белән чагыштырганда зуррак булуына басым ясый.

Тик әлеге уңышлар артында татар авылларының язмышы ята. Чөнки сөт комплексларының бер өлеше кечкенә фермалардагы терлекләр хисабына тулылана. Терлеген тәэп алып китеп бетергәч, бинасының да, гомер буе анда бил бөккән кешесенең дә кирәге калмый.

Узган ел ахырында Чүпрәле районының Иске Кәкерле авылында 500 баш терлеккә исәпләнгән ферманы япканнар. 40лап кеше эшсез калган. Аларның берничәсе башка авылдагы комплекска эшкә урнашкан. Калганнары әлегә өйдә.

– Без – гомер буе авылда, фермада эшләгән кешеләр. Хатыным Гөлфизә сыер сауды, мин механик булып эшләдем, – диде Дамир Бигиев. – Узган ел ферма ябылганнан бирле, өйдә генә торабыз. Шәһәргә чыгып китәр яшьтә түгел инде без. Икебез дә 50гә якынлашабыз. Авылны ташлап, кая китәсең? Өлкән яшьтәге әни дә бар бит әле. Хуҗалыкта терлекләр асрыйбыз, әлегә төп керем чыганагыбыз шул. Безнең кебекләр күп әле. Моңа кадәр фермада эшләгәннәрнең берничәсе күрше Уби авылына йөреп эшли башлады. Нишлисең инде? Яшәргә, тормыш алып барырга кирәк. Үзем дә җәен бригадалар белән йортлар салырга чыгармын, дип торам. Ферма булганда, бу эшне ташлап торган идем.

Дамир Бигиев фикеренчә, авылны авыл итеп тотучы ферма булмау халыкның кәефендә дә чагыла.

– Ферма беткәч, авыл халкы бик борчылды. Чөнки без аны ябуны авылның тамырына балта чабуга тиңлибез. Кайчандыр Иске Кәкерленең кирпеч заводы, колхозы бар иде, комплекслары гөрләп торды. Ахырда сыер фермасын да бетерделәр. Менә хәзер бернәрсә дә калмады. Мондый авылның киләчәге бармы? Белмим.

Хәер, мисалларны әллә каян ерактан эзлисе дә түгел. Барысы да үземнең күз алдында. 2018 елда үзебездә – Азнакай районының Беренче Май авылында да ферманы ябып, малларның кайсын Сукаештагы комплекска алып киттеләр, кайсын иткә тәэп озаттылар. Ул чагында авылдагы балалар бакчасына 13 бала йөри иде. Әтиәниләре фермада эшләде. Эш булмагач, күпбалалы 3 гаилә – шәһәргә, тагын ике-өче башка авылга күченеп китте. Моңа кадәр фермада эшләгән тагын берничә кеше башка җиргә барып хезмәт куя.

> Шулай итеп, бүген балалар бакчасында нибары ике бала калды. Озак та узмады, күрше Урманай авылында да ферма ябылды. Анда да эшчеләрнең кайсы әлегә кадәр эшкә урнаша алмый, кайсылары шәһәргә чыгып киткән, кайсыларын комплекска машина йөртә.

– Авылда күңелсез хәзер. Мин клубта эшлим. 2015 елда, декрет ялына киткәнче, авыл тере, җанлы иде. Бала-чагалар да, яшьләр дә, ферма ягыннан арлы-бирле йөреп торучы тракторлар да бар иде. Хәзер көндез урамга чыксаң да, кеше очратам димә, – ди Ләйсәнә Шәфигуллина.

Җайлашу

Әлеге мәсьәләне Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы коллегиясендә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та күтәрде.

– Чистайда инвесторның терлекләрне бетерүе аркасында, биш авыл халкы эшсез калды. Зәй, Яшел Үзән, Яңа Чишмә һәм Югары Ослан районнарында шундый ук хәл. Әгәр болар вакытлыча булса, аңларга була. Ләкин без бернинди дә карарлар кабул итмәсәк, бу авыллар акрынлап юкка чыгачак. Эшсез булмый. Терлекчелек авыл халкы тормышында бик мөһим, – диде ул.

Чистай районы турында сүз чыккач, без әлеге районга да шалтыраттык. Районның баш зоотехнигы Радик Вафин ышандырганча, биш авылда фермалар бетсә дә, халык эшсез калмаган, чөнки биналар фермерлар кулына күчкән. Киләчәктә алар терлек саннарын арттырачак, ди.

– «Чистай агро» агрофирмасы терлекчелек белән шөгыльләнүдән туктап, тулысынча игенчелеккә күчте. 6 мең мөгезле эре терлек бетерелде, аларның күпчелеге лейкозлы маллар иде. Әйе, башта, чыннан да, халык эшсез калыр, дигән шик булды. Тик Гаделша, Татар Сарсазы авылларында эш акрынлап торгызыла, терлекләр алып кайталар. Мөслимдә шулай ук ферманы рәсмиләштереп йөриләр. Узган ел безнең районда зур комплекслар төзелмәде, булганнары яңартылды, реконструкцияләнде генә, – диде ул.

Билгеле, фермалар ябылгач, бар халык та эшсез кала дигән сүз. Тормыш шулай китереп куйгач, кешеләр яңа шартларга җайлаша. Кемдер, авылда яшәп, читкә эшкә йөри, кемдер, авылны калдырып, бөтенләйгә чыгып китә. Ничек кенә булса да, болар барысы да авылның киләчәгенә йогынты ясый.

– Бездә ферма 2021 елның октябрендә бетте, – ди Урманай авылында яшәүче Илгизә Нигъмәтуллина. – Шуннан соң безне, ике сыер савучыны, Сукаеш авылындагы мегафермага алдылар. Дүрт смена эшлибез. Машина өйдән килеп ала, китереп куя. Эшләгән урыныбыз чиста, якты. Яхшы акча алып эшлибез. Эш яраткан кешегә мегафермада эшләү әйбәт. Мин зарлана алмыйм.

Тәгәрмәч

Озак еллар авыл хуҗалыгында эшләүче агроном Илгизәр Нуретдинов фикеренчә, зур фермалар бетүнең сәбәбе – кадрлар кытлыгы.

– Авыллар картая, яшьләр калмый, фермаларда эшләргә кеше юк. Сыер савучысын да, терлекчесен дә, механизаторын да табып булмый. Соңгы ун елда без читтән килгән үзбәкләр белән эшлибез. Уку йортларын гына карагыз сез. Без укыганда 75әр агрономны укытып чыгаралар иде. Хәзер бер курсны 25–30 белгеч тәмамлый. Фермерларда эшләр өчен кеше бар әле, алар ничек тә тырыша. Шуңа күрә әлегә җирдә эшләргә кеше бар, дибез.

Кыенлыклар булса да, җитештергән продукция үзебезгә җитә, ди ул.

– Булганын, үстергәнен генә сата алмыйча азапланабыз. Ни өчен авыл хуҗалыгында проблема һаман бар? Чөнки без җитештергән продукциянең бәясе бервакытта да булмады. Үзебез сата белмибез. Дөресрәге, без продукция түгел, ә чимал сатабыз. Ашлыкны читкә чыгарыгыз, диләр. Кичәге механизатор бу эшне эшли аламы? Шуның өчен кооперативлар, кабул итү пунктлары булдырырга кирәк, дибез. Сөт, ит һәм икмәкне сатуны дәүләт кайгыртсын иде, – ди Илгизәр Нуретдинов.

Бу – гадәти процесс һәм моннан котылып булмый. Озак еллар Яңа Чишмә районында колхоз рәисе булып эшләгән, Россиянең атказанган агрономы, бүген инде лаеклы ялда булган Гомәр Сөләйманов әнә шулай ди.

– Ферма бетүнең төп сәбәбе – авылда эшләргә кеше калмау. Менә, мәсәлән, үзебезнең фермаларда эшләүчеләрнең барысы да – үзбәкләр, эшчеләрне Чистай районыннан да алып киләләр. Соңгы өч-дүрт елда гына да күрше-тирәдәге дүрт авылда фермалар ябылды, терлекләре бетерелде. «Агро основа» агрофирмасы да Тубылгы Тау авылында 700 башка исәпләнгән комплекс төзи. 700 сыерны өч кеше савачак. Мин сигез ел элек эшемнән туктадым. Ул вакытта ук: «Биш елдан фермада кеше калмый», – дип курка идем. Сыер савучылар – пенсия алды яшендә, терлекчеләр, механизаторлар бик аз булса да, үз авылыбызныкылар иде. Хәзер инде аларның барысы да китеп бетте, берсе дә калмады. Фермер хуҗалыкларында эшләүчеләр бераз бар, тик алар да пенсия яшендәгеләр.

Терлекчелек белән көн иткән, халкы авылга якынрак булган, төп табышларын мал асраудан керткән районнар өчен ферма ябылу зур фаҗига булса, электән үк фермаларында килгән кешеләр бил бөккән авыллар өчен бу – табигый һәм котелгән күренеш, димәк.

– Безнең якларда халык элек-электән авыл өчен җан атып яшәмәде, – дип фикерен дәвам итте Гомәр Сөләйманов. – Авыл хуҗалыгы районнарында вазгыять башкача. Анда халык авылда калырга тырыша әле. Гомумән, авылларның шундый хәлгә каласы билгеле иде инде. Моның өчен барысы да эшләнде. Элек фермада эшләүченең хезмәт хакы булмады. Тик терлекче ферма малыннан арткан фуражын, сенажын капчык, арба төбенә салып кайтканлыктан, үз хуҗалыгында мал асрап, канәгать булып йөри иде әле. Аннан соң фермалар сак астына алынды.

> Халыкның кәефе төште, маллар кимеде, башлары шәһәргә таба борылды. Яшьләрне матур итеп салынган йортлар да авылда тотып кала алмый. Шуңа күрә хәзер инде берни дә эшләп булмый. Барысы да тәгәрмәч төсле тәгәри.

Эльвира
ВӘЛИЕВА

БАНКАДА ТҮГЕЛ, БАНКТА

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Акча санаганны ярата

Дөнья күләмендә билгеле вакыйгалар акча тирәсендә дә ыгы-зыгы тудырды. Хәер, акчага мөнәсәбәт пандемия чорында ук үзгәрде, ди белгечләр.

– Коронавируска бәйле локдаун игълан ителгәч, ярты еллап өйдән чыга алмыйча утырдык. Кибетләргә йөреп булмагач, кесәдәге акча да тузмады. Бу исә мая туплауга китерде, – ди Татарстан Иҗтимагый палатасының финанс мәсьәләләре буенча белгече Фәнис Хөсәенов. – Чикләүләр бетерелгәч, халык ташламалы ипотека программасыннан файдаланып, кесәдә җыелган акчага күпләп милек сатып ала башлады. Илдә милек сату күрсәткечләре үсте. Ә махсус хәрби операция игълан ителгәч, илдә яшәүчеләр банкта булган бар акчасын алып, товар сатып алуга кереште. Хәтерлисезме, ул вакытта инфляция 20 процентка кадәр җитте. Шуңа күрә Үзәк банк төп ставканы 20 процентка кадәр күтәрергә мәҗбүр булды. Моңа бәйле рәвештә банклар да кертемнәр буенча ставканы 20 процентка кадәр арттырды. Бу киеренкелектән чыгарга ярдәм итте. Мобилизация башлану турындагы хәбәрдән соң исә халык акчаны янга калдырыга күчте. Исәп-хисап счетларындагы акчаны шулай ук алдылар, әмма иртәгесе билгеле булмагач, акчаны артык әрәмшәрәм итмәскә тырыштылар. Без бүген дә әнә шул хәлдән чыкмаган әле. Халык мая туплавын дәвам итә.

«Югары икътисад мәктәбе» милли тикшеренү институты үткәргән сораштырудан күренгәнчә, илдә яшәүчеләрнең 26 проценты җыйган акчасын, кем әйтмешли, банкта түгел, ә банкада саклый. «Өйдә торса, ышанычлырак», – дигән алар. Тагын шулкадәр үк чамасы кеше бар булган акчаны милек яки кыйммәтле техника сатып алуга тоткан. Респондентларның 23 процентының банкта исәп-хисап счеты бар икән. Кесәдәге акчаны акцияләргә яки кыйммәтле кәгазьләргә салып куюны иң кызыксындырмый торган юл дип әйткәннәр. Халыктагы маяның 75 проценты – сумнарда, 17 проценты юаньнәрдә саклана. Быелның 1 февраленә алынган мәгълүматларга караганда, илдә яшәүчеләрнең кулында 7,33 триллион сумлык чит ил валютасы бар, дип хәбәр итә Үзәк банк.

– Акчаны өйдә саклау дөрес түгел, – ди Казан дәүләт аграр университеты доценты, икътисадчы Илгизәр Гайнетдинов. – Аны урлап та чыгып китәргә мөмкиннәр бит. Икенчедән, өйдә яткан акча ким дигәндә еллык инфляция күләмендә кимеп бара. Бүген кешенең кулында артык акчасы бар икән, аны нәрсәгә дип җыйган, шуны сатып алырга тотарга яки банкка салып куярга кирәк. Акча әйләнештә булган очракта гына, табыш китерергә мөмкин. Кызганыч, бүген банклар зур кертемнәр вәгъдә итми. Кредит оешмаларында еллык ставка күп дигәндә дә 9 проценттан артмый. Инфляция күрсәткече исә 10 процент дип чамалана. Әмма акчаны өйдә саклаганчы, шул 9 процентка салып куйсаң да, ул маяның азрак артуына китерәчәк. Банкларга кызыктыру чаралары уйлап табарга кирәк, дип уйлыйм. Һич югы кертем ставкасы инфляция күрсәткеченнән ким булмасын. Югыйсә, безне төрлечә җәлеп итәргә тырышып, зур табыш вәгъдә итәләр. Тик бу озак вакытка исәпләнгән кертемнәргә генә кагыла. Бүген халык акчасын өч-дүрт елга банкка салып куярга ашыкмый. Бу очракта, килешүне вакытыннан алда өзеп, акчаны кире ала калсаң, процентлар түләнми. Димәк, бернинди дә файдасы булмаячак. Хәзер күбрәк бер елга яки аннан да азрак вакытка исәпләнгән исәп-хисап счетлары ачалар.

depositphotos.com

> **2023 елда акчаны нишләтергә?**
>
> **Маяны саклау һәм арттыру өчен белгечләрдән биш киңәш**
> 1. Банк кертеме ачыгыз.
> 2. Акчаны тупланма счетка салып куегыз (банк кертеменнән аермалы буларак, тупланма счетның вакыты чикләнмәгән).
> 3. Облигацияләр яки акцияләр сатып алыгыз (акция рәвешендәге инвестицияләрне югалту куркынычы булуы турында онытмагыз).
> 4. Милек, мәсәлән, фатир сатып алып, шуны арендага бирегез.
> 5. Үз эшегезне башлагыз.

Акчаны нәкъ менә банкта саклауның тагын бер отышлы ягы да бар. Көннәрнең берендә акчам җилгә очса, дип борчыласы юк.

– Җыйган акчаны банкта сакларга кирәк. Чөнки финанс оешмасында 1 миллион 400 мең сумга кадәр булган һәр кертем иминиятләштерелгән. Әгәр маягыз моннан күбрәк икән, аны берничә кертемгә бүлеп салырга мөмкин. Иң мөһиме, ул 1 миллион 400 мең сумнан артмасын. Берәр хәл килеп чыкса, мәсәлән, банкның лицензиясен алсалар, исәп-хисап счетындагы акчаны озакка сузмыйча Кертемнәрне иминиятләштерү фонды кайтарып бирәчәк. Бүген халык арасында банкларга ышаныч дәрәҗәсе зур. Ник дисәң, соңгы өч елда илдә бер генә банк та ябылмады, – ди Фәнис Хөсәенов.

Булмаса да кыен, булса да

Финанс киңәшчесе, инвестицион юрист Сирин Зарипов әйтүенчә, акча белән эш иткәндә диверсификация (аны төрле юнәлешләрдә тоту) турында да онытырга ярамый.

– Бу – акча саклауның алтын кагыйдәсе, – ди белгеч. – Мая төрле урыннарда, төрле валюталарда һәм хәтта, мөмкинлек булса, төрле илләрдә сакланырга тиеш. Бу – кәрҗиндәге күкәйләр кебек. Аларны бөтенесен бер урында сакласаң, кәрҗин кулдан төшеп китеп, бөтен күкәйләр ватылып бетү куркынычы зур. Ә аларны бүлеп салсаң, күкәйләр дә исән калачак. Банк кертеме ул начар түгел. Әмма аерым бер максатлар өчен генә ярый. Озак вакытка акча салу турында сөйлибез икән, банк кертеме бик үк туры килми. Чөнки финанс оешмаларында процент ставкасы инфляция дәрәҗәсеннән түбән. Банктагы акча син баеганга караганда, тизрәк үз кыйммәтен югалтачак, кыскасы. Акчаны юрган астында җыеп барырга түгел, ә эшләтергә кирәк. Тегеяки бу компаниянең кыйммәтле кәгазьләрен сатып аласызмы, үз бизнесыгызны башлап җибәрәсезме, фатир алып, шуны арендага биреп торасызмы, акча актив, ягъни табыш китерә торган чыганак булырга тиеш. Аны өйдә саклап тотуның мәгънәсе юк.

Сирин Зарипов фикеренчә, дөньякүләм киеренкелек, инфляция – болар барысы да нефтьтән алып азык-төлек бәясенә кадәр бөтен нәрсәдә чагылыш таба. Тик моңа охшаш хәлләрне без 2008 елда һәм аннан да иртәрәк чорларда кичергән идек инде. Шуңа күрә төшенкелеккә бирелеп утырырга кирәкми. Ә менә төннәрен тынычлап йоклар өчен баш астындагы мендәр генә җитми икән. Өйдә «финанс мендәре» дә булырга тиеш, ди белгечләр.

– Тормыш булгач, бар да була. Шуңа күрә һәр гаилә, керемнәре рөхсәт итсә, көнкүреш чыгымнарыннан калган акчаны туплап барырга тиеш. Көтмәгәндә эшсез калсагыз яки авырып китсәгез, сезгә алдан ук җыеп куйган «финанс мендәре» ярдәмгә киләчәк. Мендәр астында күпме акча булырга тиеш икәне дә билгеле. Ай саен ашау-эчү, коммуналь түләүләр, кредит, дарулар сатып алу, балаларга киткән чыгымнарны кушасыз да шуны алтыга тапкырлыйсыз. Килеп чыккан сумма сезнең «финанс мендәре»н тәшкил итәчәк тә инде. Без ким дигәндә ярты елга җитәрлек куркынычсызлык маясы булдырырга киңәш итәбез. Бу акчаны тотмаска тырышырга кирәк, – ди финанс мәсьәләләре буенча белгеч Фәнис Хөсәенов.

Акча агачта үсми. Шуңа күрә, кесәдәге маяны тиз генә арттырып бирәбез, дип вәгъдә өләшүчеләрне дә читләтеп узарга киңәш итә белгечләр. Югыйсә, байлык артыннан куып, ярык тагарак янында утырып калуыгыз да бар. Шушы арада гына хокук саклаучылар Мамадышта яшәүче 18 яшьлек (!) егетне тоткарлаган. Ул акчаны «югары керемле инвестиция проекты»на кертергә вәгъдә итеп, илнең төрле төбәкләрендә яшәүче 26 кешене төп башына утырткан. Тиз акча турында хыялланучыларга 585 мең сумлык зыян килгән.

– Соңгы арада халыкның кесәсендәге акчасына кызыгып, безне алдарга теләүчеләр саны бик күпкә артып китте. Чөнки җәзасызлыкны сизәләр. Безнең законнар ул мәсьәләдә бик үк камил түгел дип саныйм, – ди икътисадчы Илгизәр Гайнетдинов. – Финанс пирамидаларын гына карагыз. Мондый ялган оешмалар саны үзебезнең Татарстанда да шактый булып чыкты. Күреп торабыз бит, оештыручыларын эзәрлекле башлыйлар да, тегеләр тиз генә чит илгә чыгып качып, Гарәп Әмирлекләре, Төркиядән безгә тагын акча эшләргә өйрәтә башлыйлар. Күпме генә сөйләсәк тә, халык барыбер алдана. Чөнки бүген җиңел акча эшләү культы таралган. Танылган артистлар да, блогерлар да җайлы гына итеп кесә калынайта, акчаны әллә кайларга салып, байлыкларын арттыра, имеш. Тик бу – ялгыш фикер. Акча уен-муен эш түгел!

ҖЫЕЛГАН АКЧАНЫ КАЙДА САКЛЫЙСЫЗ?



Банкта хисап счетында	14%
Банк картасында	9%
Өйдә генә тотам	21%
Җыйган акчам юк	54%
Башкасы	2%

«ВКонтакте»дагы төркемдәге сораштыруда 188 кеше катнашты

Фикер

Венера КАСЫЙМОВА, психолог:
– Биеклектән, ялгызлыктан, очкычка утырудан курку белән беррәттән, бездә күп акчадан курку хисе дә бар. Нәкъ менә шул баерга комачау итә дә инде. Гап-гади тест. Күзегезне йомыгыз да күз алдына бер чемодан акча китерегез. Нишләячәксез? Әгәр акчаны бизнес ачу, белемне арттыру кебек киләчәк эшләренә тотарга ниятләгәнсез икән, котлыйбыз, сезнең акчадан курку хисе юк. Чемоданны күргәч, җыелган бурычларыгыз, күптән диңгезгә ял итәргә бармавыгыз искә килеп төште яки, гомумән дә, булмас хәл бит бу дип, кәефегез кырылды икән, сездә акчадан курку хисе бар. Бу безгә балачактан килә. Килешәсездер, әтиәниләр балаларга гел: «Акча белән уйнама», «Кесәдәге акчаны күрсәтеп йөрмә», – дип кабатлап тора. Нәтиҗәдә, үсеп җиткәч, акча турында сөйләшергә дә уңайсыз була башлый. Ә курку хисе артында гап-гади теләк – күп итеп акча эшләү килү хисе ята. Моны танырга һәм акчаны ярата башларга гына кирәк.

31 мартка сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Гөлгенә ШИҺАПОВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Китапханәбез булырмы?

Сезгә зур үтенеч белән Әтнә районының Күңгәр авыл җирлегенә караган Түбән Шашы, Күңгәр, Югары Шашы авыллары халкы мөрәҗәгать итә. 5–6 ел элек капиталь төзекләндерүдән соң авылда клуб ачылды. Сүз дә юк, ул бик матур. Район җитәкчеләренә бик зур рәхмәт. Тик, кызганыч, төзекләндерелгән бинада китапханәгә урын табылмады. Китаплар да таралып бетте. Авылыбыз кечкенә түгел, яшь гаиләләр дә бар. Мәчетебез, балалар бакчасы, 11 еллык мәктәп, медпункт, шәхси кибетләр эшләп тора. Ул яктан зарыбыз юк. Әмма китапханә булмау күңелне төшерә. Ул – авыл халкы өчен җанлы аралашу урыны, икенчедән, безнең дә яңа чыккан китапларны алып укыйсыбыз килә. Әгәр авылда китапханә оешса, Мокшы авылындагы үзебез төзегән музейны да алып кайтып урнаштырыр идек. Бүген ул ташландык хәлдә.

Түбән Шашы, Күңгәр,
Югары Шашы авыллары халкы

Әтнә районы мәдәният бүлеге җитәкчесе Алия Абдуллина:
– Без әлеге мәсьәләне беләбез. Клубка ремонт мин әлеге вазыйфага билгеләнгәнче ясалган. Әлеге вакытта биредә клуб һәм ФАП эшли. Клубның фойесы зур булса да, бүлмәләре аз һәм алар кечкенә. Зур урынны ФАП алып тора, анда китапханә өчен бүлмә каралмаган. Шуңа күрә аны гомуми белем бирү мәктәбенә урнаштырганнар иде. Тик дөньяда иминлеккә бәйле үзгәрешләр башлангач, теләсә кем мәктәпкә кереп тә йөри алмый. Әлегә китапханә өчен аерым бина төзү күздә тотылмый. Шулай да бу хәлне ничек тә җайларга тырышабыз: китапханәчеләр, укырга яратучы кешеләрдән исемлек алып, китапларны өйләренә илтеп бирә.

Мәйданчык ник юк?

Авылларны саклап калырга кирәк, дип еш әйтәсез. Ә ничек сакларга икән аны? Менә шуңа җавап табарга булышыгыз әле. Әйтик, авылның инфраструктурасын кайгыртырга кирәк, диләр. Бездә балалар мәйданчыгы да юк. Аны ясатыр өчен кая мөрәҗәгать итәргә була?

Фәимә МОРАТОВА.
Чирмешән районы Кара Чишмә авылы

Кара Чишмә авыл җирлеге башлыгы Рәдиф Халиков:
– Балалар мәйданчыгын сатып алдым. Бу апа әлегә белми генә калгандыр. Аны урнаштырыр өчен көннәрнең җылытуын, җирнең кибүен көтәбез. Хәзерге вакытта мәйданчыкны кая урнаштыру турында уйлыйбыз.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Чүп өчен түлимме?

Сезнең газетадан, вакытлыча өйдә булмаган очракта, бу хакта белешмәләр белән дәлилләгәндә, чүп өчен түләгән акчаны кире кайтарырга мөмкин, дип укыган идем. Шул уңайдан үземнең дә сорау бар. Улым бездә теркәлгән, тик аның Балык Бистәсеннән киткәненә 30 ел була. Мин әле дә аның өчен чүпкә түлим. 1994 елда күршемнең улы да армиягә китте, контракт белән шунда калды. Әнисе дә аның өчен чүпкә түли. Без алар өчен түләргә тиешме? Эшләгән җирләреннән документ алып кайтсалар, түләмәскә мөмкинме? Бу сорау белән кая мөрәҗәгать итәргә кирәк?

РАИЛӘ. Балык Бистәсе

Татарстан Тарифлар буенча дәүләт комитетының матбугат үзәге:
– Кулланучы биш көн һәм аннан да күбрәк өйдә булмаган очракта, каты көнкүреш калдыкларын чыгарган өчен түләнгән акчаны яңадан исәпләтә ала. Тик ялга киту, хастаханәдә яту кебек сәбәпләр аркасында, вакытлыча өйдә булмаганлыкны дәлилләргә туры киләчәк.

Газета укучысы түләнгән акчаны кире кайтаруга өметләнә ала. Тик тагын да тулырак мәгълүмат алыр өчен, «УК «ПЖКХ» җәмгыятенә мөрәҗәгать итәргә тәкъдим итәбез. Оешманың колл-үзәк номеры: 8(843)260-02-40. Шулай ук хат та язып җибәрергә мөмкин: operator@rtro.ru.

Ничек котылырга?

Туганым кинәт кенә вафат булды. Аның куллану (потребительский) кредиты булган. Хәзер бурычларын балалары түләячәк. Мондый хәл килеп чыкмасын өчен, кредит алганда нәрсәне белеп тору кирәк?

Гөлсем ИБРАҺИМОВА. Югары Ослан

Юрист Булат Закиров:
– Васыять язган очракта да, закон буенча да, мәрхүмнең мөлкәте аның варисларына күчә. Мөлкәт белән бергә, мәрхүмнең кредит бурычлары да кала. Әгәр дә варислар берничә булса, бурыч суммасы һәркайсының мирасындагы өлешләр нигезендә алар арасында бүленә. Ләкин шуны истә тотарга кирәк: варисларның һәркайсы мирас хокукыннан баш тартырга мөмкин.

Мирасны кабул итеп, аның бурычларын да түләмәү очраклары бар. Тик бу вакытта мирас тапшыручының үзе исән вакытта гомерен һәм саулыгын иминиятләштерткән булуы кирәк. Шуңа күрә, күңелсез хәлдә калганчы, мирас кабул иткәнче мәрхүмнең кредит тарихын тикшерергә һәм йөкләмәләр реестрыннан белешмәләр алырга киңәш итәбез. Бу вариска милек бәясен бурыч суммасы белән чагыштыру өчен кирәк.

Салымны күпме кайтарып була?

Россия Президенты Владимир Путин беелгы Юлламасы вакытында вузларда укучылар өчен салымны кире кайтару (вычет) суммасы, әти-әниләр түләгәндә, 120 меңгә җитә дигән иде. Бу үзгәрешләр гамәлгә кердеме инде?

ГӨЛНУР. Казан

5 нче районара салым инспекциясе җитәкчесе Мөнир Шәйдуллин:
– Әлегә гамәлгә кермәде. Андый үзгәрешләр ел уртасында түгел, ә ел башыннан, 1 гыйнварда үз көченә керә.

Судка бирүдән мәгънә бармы?

Аерылган ирем эшеннән киткән. Әлеге вакытта беркайда да рәсми төстә теркәлмәгән. Кызыма алимент килми башлады. Мондый очракта ни эшләп була? Алимент түләүчеләрнең әллә никадәр бурычлары җыелган, дип гел язып торалар бит. Рәсми төстә эшләмәгән кешедән акчаны ничек алырга?

ГӨЛНУР. Чаллы

Юрист Булат Закиров:
– Әгәр сезнең кулда алимент алуга суд карары булып та, элеккеге ирегез аны үтәми икән, эш тәртибе менә болайрак булачак. Беренчедән, сезгә суд приставларына барып, алимент түләнмәвен әйтергә һәм башкару (исполнительный) документын тапшырырга кирәк булачак. Алар башкару эшен кузгатачак һәм шунда ук баланың әтисенә бурычлары язылачак. Шуннан соң приставлар бурычлының карталары, счетлары һәм милке белән эшли башлый. Эшнең барышын Россия Дәүләт хезмәтләре порталы аша күзәтергә мөмкин. Әгәр әҗәтле кеше өч айдан артык бурычларын түләмәсә, аңа карата җинаять эше ачыла.

Фикер

«Татарстан – Яңа Гасыр» каналында бер җырчы кыз «Шәмдәлләрдә генә утлар яна» дип җырлап, сәхнәгә сукыр лампа тотып чыкты. Татар өчен моннан да оятрак күренеш була аламы? Мәрхүм Әлфия Авзалованың җырын телевидениегә шулай итеп чыгарудан оялырга кирәк иде. Җитмәсә, җырчы дигән туташның тавышы да куелмаган. Телевидениегә, җыр бәйгеләренә җырлый белми торган «йолдыз»ларны чыгаруга бераэ вакыт чик куелыр микән ул? Без, халык, шундый арыдык бит алардан.

Исемем газета өчен генә

Бурыч кемгә кала?

Ирем белән аерылган очракта, ипотека кредитын кем түләр икән? Ипотека минем исемдә, тик фатирыбызда барыбызның да өлеше бар.

Ләйсән САЛИХОВА. Казан

Юрист Булат Закиров:
– Бу очракта ипотека килешүе үзгәртелгәнчегә кадәр, банк каршындагы җаваплылык хатын исемендә булачак. Мондый очракта милекне берничә ысул белән бүләргә мөмкин.
✓Милекне ир яки хатынның бирсенә тулысынча рәсмиләштерергә һәм ипотеканы үзгәртергә. Бу очракта милек тә, бурычлар да бер кешедә булачак. Тик банклар ипотека килешүе шартларын бик авырлык белән генә үзгәртә.
✓Икенче вариант – фатирны сату. Кучемсез милекне сатарга, алынган акчага ипотека бурычын түләп бетерергә һәм калган акчаларны бергә тупланган милек буларак тигез өлешләргә бүләргә мөмкин.
✓Ир белән хатынның килешүе буенча акчалата компенсация. Бу вакытта ипотека яңадан рәсмиләштерелми, өлешләр һәм заем алучы үзгәрешсез кала, әмма ир белән хатын арасында килешү яки расписка төзелә. Анда түбәндәге тәртипләр язылган була:
а) ир белән хатынның берсе ипотека түләвен дәвам итә, ә икенчесе түләүләрнең бер өлешен компенсацияли. Кредит ябылганнан соң, ир белән хатынның һәркайсының фатир өлеше кала, элеккеге ир белән хатынның берсе бу өлешне сатып алырга мөмкин;
б) ир белән хатын аерылышканда, бергә вакытта түләнгән ипотека буенча түләүләрнең суммасын бүләргә мөмкин. Алга таба төп заемчы (хатын) ипотека түләүне дәвам иттерә, ә ире ипотека түләгәннән соң үз өлешеннән баш тартачагын яза;
в) элеккеге ир белән хатынның берсе фатирның яртысына булган хокукыннан баш тартырга һәм акчаны кайтару бурычыннан баш тартырга мөмкин. Тик моның өчен банкның ризалашуы кирәк.

Зөһрә САДЫЙКОВА әзерләде

Укучы сүзе

«МУЛ УҢЫШ ТАМАК ТУЙДЫРАМЫ?» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗЛАР

Түбәнрәк бәядән саткан булса, халык алмый калмас иде. Узган ел икмәк шулкадәр нык унды. Ник 7, я булмаса 8 сумнан сатмаска? Әле бүген дә 11 сумнан саталар.

Зәмзәмия РӘХМӘТУЛЛИНА

***

Алдагы фикер белән килешмим. Фермерлар, ашлык үссен өчен, күпме хезмәтен сала, тирен түгә. Быел Балтач, Кукмара якларында кышын арпа – 9, солы 8 сум булды. Моннан да түбән бәягә сата алмыйлар бит инде. Мал-туар, фураж ашамыйча, сөт тә бирми, ит тә җитештереп булмый. Һәркемнең хезмәтен хөрмәт итәргә өйрәнсәк иде. Авыл җирлегендә эшләүчеләргә үстергән игенне урнаштырырга хөкүмәт ярдәме кайда икән? Биек трибуналардан бик матур сүзләр сөйләнә бит.

Зәлфия ГЫЙМАДИЕВА

«ТАГЫН УН КӨН КӨТӘСЕ» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

19 мартта, хут суыклары чыккач, чын яз башлана дип беләм. Кайчан гына башланса да, хәерле белән килсен, тынычлык алып, сыерчыклар, кыр казлары кайтсын. Ашыгып, Аллаһтан узып, берни эшләп тә булмый. Менә, ичмасам, гөмбә уңар дигән хәбәр куандырды. Игеннәр дә мулдан булыр, алдан хафаланмыйк әле. Болай да, көн туды исә, яман хәбәрләр ишетелеп кенә тора. Бик арытты яман хәбәрләр халыкны, яхшыга юрыйк.

Гөлнар ШАҺИСЛАМОВА

27 март | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ» 16+
10.00, 23.00 «ЛИЧНОЕ ПРОСТРАНСТВО» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 16.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «ПАТШАБИКӘНЕҢ СОҢГЫ ЙӨРЕШЕ» 12+
13.00 «Семь дней» 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество»16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
00.00 «Здоровая семья: мама, папа, я» 12+
00.15 «Если хочешь быть здоровым» 16+
00.25 «Таяну ноктасы» 16+
00.50 «Ком сәгате» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Родная земля» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «СИҢА КАЙТАМ». Телевизион нәфис фильм 16+
15.25 «Заман көзгесе» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Ватандашлар». Пубольга юл. Гала Дали 16+
19.10, 22.10, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.30 «Калеб» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Заман көзгесе» 6+
23.10 «Башваткыч» 12+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
00.40 «Үткәннәр сагындыра» 12+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
04.15 «Башваткыч» 12+

1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
15.30 Премьера. «Всегда на страже!» 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
20.00 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. Сергей Безруков в многосерийном фильме «ШПИОН» (S) 16+
22.40 «Большая игра» 16+
23.40 Премьера. Любовь Аксенова в многосерийном фильме «ПОЧКА» (S) 16+
00.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
00.50 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
01.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
02.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кольцо Милорадовича» 16+
03.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
04.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. «ЗАПОЛЯРНЫЙ ВАЛЬС» 12+
23.25 «Вечер» 12+
02.05 «ДУЭТ ПО ПРАВУ» 12+
03.55 Вячеслав Разбегаев, Кирилл Плетнёв, Наталия Быстрова, Анна Гарнова. «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+

МАТЧ ТВ
06.00, 14.25 «Спортивный век» 12+
06.30 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 0+
07.00, 08.35, 10.15, 14.55, 16.40, 18.25, 21.40 Новости
07.05, 15.30, 21.45, 00.30 Все на Матч! Прямой эфир
08.40 Биатлон. Pari Чемпионат России. Спринт. Мужчины. Прямая трансляция из Ханты-Мансийска.
10.20 Специальный репортаж 12+
10.40, 04.00 Спортивный дайджест 0+
11.40 Биатлон. Pari Чемпионат России. Спринт. Женщины. Прямая трансляция из Ханты-Мансийска.
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
15.00 «География спорта. Малиновка» 12+
16.45 «Бросок в прыжке: история Кенни Сейлорса». Документальный фильм 12+
18.30 «Громко» Прямой эфир
19.40 Смешанные единоборства. UFC. Марлон Вера против Кори Сэндхагена. Яна Куницкая против Холли Холм. Трансляция из США 16+
20.40 Профессиональный бокс. Денис Лебедев против Йоури Каленги. Трансляция из Москвы 16+
22.30 Дартс. Профессиональная лига. Про Тур 1. Прямая трансляция из Москвы
01.00 Биатлон. Pari Чемпионат России. Спринт. Мужчины. Трансляция из Ханты-Мансийска 0+
02.20 Биатлон. Pari Чемпионат России. Спринт. Женщины. Трансляция из Ханты-Мансийска 0+
03.25 «Наши иностранцы» 12+
03.55 Новости 0+
04.55 «Громко» 12+

НТВ
04.55 Сериал «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Макар Запорожский, Николай Козак в детективном сериале «СТРАЖНИК» (S) 16+
22.15, 00.00 Остросюжетный детектив «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
00.45 Прохор Дубравин, Павел Баршак. «ИГРА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «6 кадров» 16+
06.40 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.10 «Давай разведёмся!» 16+
09.10 «Тест на отцовство» 16+
11.25 «Понять. Простить» 16+
12.30 «Порча». «Незаметно» 16+
13.00 «Знахарка» 16+
13.35 «Верну любимого» 16+
14.10 «Голоса ушедших душ» 16+
14.45 «ИРОНИЯ ЛЮБВИ» 16+
19.00 «ЕСЛИ СЕРДЦЕ ДРОГНЕТ» 16+
23.15 «ПРОВИНЦИАЛКА». 1-я – 8-я серии 16+
05.20 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
05.10 «СТАРОЕ РУЖЬЕ». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 00.55 «РОЖДЕННАЯ РЕВОЛЮЦИЕЙ». «ЭКЗАМЕН» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир» 16+
13.20, 15.05 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Бог войны. История русской артиллерии». Документальный сериал. Фильм 1-й 16+
19.40 «Загадки века» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной. 12+
23.25 «УВОЛЬНЕНИЕ НА БЕРЕГ» 12+
02.30 «Финансовые битвы Второй мировой». Документальный фильм 12+
03.30 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ». 1-я и 2-я серии 16+

28 март | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ» 16+
10.00, 23.30 «ЛИЧНОЕ ПРОСТРАНСТВО» 16+
11.00 «Азбука долголетия» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.40 «ПАТШАБИКӘНЕҢ СОҢГЫ ЙӨРЕШЕ» 12+
13.00 «Родная земля» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего…» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Казаннан – Казанга» 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Трибуна Нового Века» 16+
22.10 «Трибуна Нового Века» 16+
00.25 «Видеоспорт» 16+
00.50 «Соотечественники». Юнус Ахметзянов. Повар национального масштаба 16+
01.15 «Здоровая семья: мама, папа, я» 12+
01.25 «Если хочешь быть здоровым» 16+
01.40 «Таяну ноктасы» 16+
02.05 «Манзара» 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Ком сәгате» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Ватандашлар». Н.Фешин. Рәссам монологы 16+
12.05, 18.20, 21.25 «СИҢА КАЙТАМ». Телевизион нәфис фильм 16+
15.25 «Таяну ноктасы» 16+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30, 19.35 «Татарлар» 12+
19.05, 22.10, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Халкым минем» 12+
23.10 «Җырлыйк әле!» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
00.40 «Татарлар» 12+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+

1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
20.00 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «ШПИОН». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Премьера. «ПОЧКА». Многосерийный фильм (S) 16+
00.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
00.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
01.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Неформат» 16+
03.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кот Шрёдингера» 16+
04.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. «ЗАПОЛЯРНЫЙ ВАЛЬС» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «ДУЭТ ПО ПРАВУ» 12+
03.55 Вячеслав Разбегаев, Кирилл Плетнёв, Наталия Быстрова, Анна Гарнова. «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+

МАТЧ ТВ
06.00, 14.25 «Спортивный век» 12+
06.30 «География спорта. Малиновка» 12+
07.00, 08.35, 10.00, 12.55, 14.55, 16.40, 18.25, 21.40 Новости
07.05, 15.30, 21.45, 00.30 Все на Матч! Прямой эфир
08.40 Биатлон. Pari Чемпионат России. Гонка преследования. Мужчины. Прямая трансляция из Ханты-Мансийска
10.05, 05.15 Специальный репортаж 12+
10.25, 04.00 «Лошадиная сила». Документальный сериал 12+
11.40 Биатлон. Pari Чемпионат России. Гонка преследования. Женщины. Прямая трансляция из Ханты-Мансийска.
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир.
15.00 «Ты в бане!» 12+
16.45 «Кулачные бои». Документальный фильм 12+
18.30 Футбол. Еврокубки 2022/2023. Лучшие голы 0+
20.40 Смешанные единоборства. UFC. Сирил Ган против Джона Джонса. Валентина Шевченко против Алексы Грассо. Трансляция из США 16+
22.30 Дартс. Профессиональная лига. Про Тур 1. Прямая трансляция из Москвы.
01.00 «Магия большого спорта» 12+
01.30 «Здоровый образ. Регби» 12+
02.00 Биатлон. Pari Чемпионат России. Гонка преследования. Мужчины. Трансляция из Ханты-Мансийска 0+
03.00 Биатлон. Pari Чемпионат России. Гонка преследования. Женщины. Трансляция из Ханты-Мансийска 0+
03.55 Новости 0+
05.30 «Всё о главном» 12+

НТВ
04.55 Сериал «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Детективный сериал «СТРАЖНИК» (S) 16+
22.15, 00.00 Остросюжетный детектив «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
00.45 Детективный сериал «ИГРА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.10 «Давай разведёмся!» 16+
09.10 «Тест на отцовство» 16+
11.25 «Понять. Простить» 16+
12.30 «Порча». «Флешбек» 16+
13.00 «Знахарка» 16+
13.35 «Верну любимого» 16+
14.10 «Голоса ушедших душ» 16+
14.45 «ОДНО ТЁПЛОЕ СЛОВО» 16+
19.00 «БОЛЬШЕ, ЧЕМ ПРИКОСНОВЕНИЕ» 16+
23.15 «ВЕЧЕРНЯЯ СКАЗКА» 16+
01.15 «ПРИЛЕТИТ ВДРУГ ВОЛШЕБНИК!» 16+
02.45 «Порча» 16+
03.10 «Знахарка» 16+
03.35 «Верну любимого» 16+
04.05 «Голоса ушедших душ» 16+
04.30 «Понять. Простить» 16+
05.20 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
05.10 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 01.10 «РОЖДЕННАЯ РЕВОЛЮЦИЕЙ». «В НОЧЬ НА 20-Е» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир» 16+
13.20, 15.05 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ». 5-я – 8-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Бог войны. История русской артиллерии». Документальный сериал. Фильм 2-й 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» 12+
23.25 «ОТЧИЙ ДОМ» 12+
02.30 «Инженер Шухов. Универсальный гений». Док. фильм 12+
03.30 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ». 5-я и 6-я серии 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың сәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыятенең 15 номерлы цехы башлыгы **Әхмәтшин** Сәет Сәлим улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе, актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «Авангард» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Курчаткин** Николай Григорьевич **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Язучы, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» җәмәгать оешмасы (Иҗат берлеге) әгъзасы **Сухов** Евгений Евгеньевичка **«Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Т.Г. Миңнуллин исемендәге Түбән Кама татар дәүләт драма театры» Татарстан Республикасының дәүләт автоном мәдәният учреждениесе драма артисты **Галиева** Гөлнура Шакир кызына, «Казан шәһәренең үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең Үзәк балалар китапханәсе мөдире **Лебедева** Ольга Алексеевна, «Казан хореография училищесы» (техникум) дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Мамин-Оглы** Марина Әнвәр кызына, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль автоном өстәмә белем бирү учреждениесе укытучысы, концертмейстеры **Матвеева** Вера Евгеньевна, «Нурлатның «Сәләт» балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе укытучысы **Павлова** Нина Михайловна, «Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең хорга дирижерлык итү кафедрасы доценты **Рогов** Денис Александровичка, «Арча балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү оешмасы укытучысы **Фәхретдинова** Альмира Леонидовна, «Салих Сәйдәшев исемендәге Дәүләт зур концерт залы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең Татарстан Республикасы Дәүләт камера хоры директоры **Чупрунова** Анастасия Вячеславовнага, Саба муниципаль районының «Сабанның үзәкләштерелгән авыл клублары системасы» (Район Мәдәният йорты) муниципаль бюджет учреждениесенең 4 номерлы филиалы – Югары Шытсу авылы мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе **Шәрифуллин** Илшат Габдерәфикъ улына **«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«ПромИндустрия махсуслаштырылган эшкәртү предприятиесе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте финанс директоры **Атласов** Николай Михайловичка **«Татарстан Республикасының атказанган экологы»** дигән мактаулы исем бирелде.

КИСТЕРМИЧӘ ДӘ БУЛА

Йоткылык бизе шешү (аденоид) – бала үстергән ата-ананың үзәгенә үткән күренешләрнең берсе. Борынга гына түгел, еш кына колакка да бәрә ул. Йоткылык бизе шешү тагын нәрсәсе белән куркыныч? Аденоидны кистерү мәҗбүриме?

Отоларинголог Айгөл ГАЗИЗОВА белән шул хакта сөйләштек.

:: Аденоид нидән гыйбарәт? Ул нәрсә өчен кирәк?
– Аденоид борын-йоткылык өлешендә урнашкан лимфа тукымасыннан гыйбарәт. Аларны гади күз белән күреп булмый. Табиб та аны еш кына зураеп, алга чыгып тора башлагач кына күреп ала. Аденоид эндоскопия ярдәмендә ачыклана. Организмга ул бик кирәк. Ник дигәндә, андагы лимфа тукымасы иммунитет өчен җавап бирә. Вирус, бактерия, гөмбәчекләр иң элек шунда эләгә.

:: Йоткылык бизе ни сәбәпле шешә?
– Ул еш кына баланың организмында иммунизация башлануга ук, ягъни бала инфекцияләр белән очраша башлагач, зурая. Баланың йоткылык бизе шешүгә, чаң сугарга кирәкми. Ник дигәндә, элегрәк аденоид операция белән генә җиңеп була торган чир санала иде. Хәзер алай түгел. Заманча дәвалау ысуллары аны пычаксыз гына да җиңәргә мөмкинлек бирә.

:: Кайсы очракта аденоидны алдыру котылгысыз?
– Әгәр йоткылык бизе шешү аркасында, балада даими рәвештә отит күзәтелсә, йоклаганда гырлау, сулыш туктап тору (апноэ) кебек күренешләр борчыса, аденоидны кистерү хәерле. Шешкән бизне табиб киңәш иткәннән соң да алдырмасаң, киләчәктә бала начар ишетә башларга, баш сөягенең йөз өлеше үзгәрергә, хроник томаудан интегергә мөмкин. Әлеге операция наркоз белән ясала. Шуңа күрә балага авыр булыр, куркып калыр дип борчыласы юк.

:: Бизләр зураю аркасында ютәл дә пәйда була аламы?
– Әйе. Ник дигәндә, зурайган аденоид лайла белән каплана һәм шул лайла борын яки йоткылык аша тавыш ярылары на кадәр төшә, кеше ютәлли башлый.

:: Аденоидларны алдырганнан соң, балага ничә көннән соң урамга уйнарга чыгарга рөхсәт ителә?
– Операция ясалган көнне үк рөхсәт ителми, билгеле. Әмма 4–7 көн узгач, баланы курыкмыйча урамга уйнарга алып чыгарга була.

:: Мондый операциядән соң бала, салкын тиеп, сирәгрәк авырый, диләр...
– Бу аңа һич кенә дә бәйле түгел. Әгәр аденоидлар аркасында бала начар ишеткән булса, операциядән соң ул яхшы ишетә башлаячак. Шул ук йоткылык бизе зурайгач йөзенең формасы үзгәргән булса, операциядән соң ул да рәтләнәчәк.

:: Диңгезгә барып кайтсаң, аденоидларны дару һәм операциясез дә җиңеп була дигән ышану яши. Бу сүзләрдә хаклык бармы?
– Дымлы һава аденоид белән тилмерүче өчен генә түгел, һәркемгә кирәк. Ул борын һәм йоткылыкның лайлалы тышчасын дымландыра.

:: Аденоид дип дәвалап, чынлыкта яман шеш булып чыккан очраклар да бар...
– Тәҗрибәле табиб борын-йоткылык өлешенә эндоскопия уздырганда, моның аденоидмы-түгелме икәнлеген шундук ачыклаячак. Шик туган очракта шешле урыннан биопсия алына.

:: Йоткылык бизе зураюны кисәтү өчен ни эшләргә?
– Моның өчен ниндидер махсус киңәшләр юк. Аденоидлар зураю – гадәти күренеш. Балалар арасында бигрәк тә еш күзәтелә ул. Вакытында чарасын күрсәң, дәвалауга да бирешә.

Абау!

Киемеңә күрә саулыгың

Сәламәтлек кигән киемгә дә бәйле. Галимнәр шулай дип ышандыра.

✷Пуш-аплы эчке кием. Күкрәкне зурайта торган эчке кием кан әйләнешен әкренәйтә, сөт бизләре тукымаларын кыса. Бу исә киләчәктә шешләр барлыкка китерергә мөмкин. Әлеге төр эчке киемне 12 сәгатьтән артык кияргә, җитмәсә, аны киеп йокларга ярамый. Бу киемне сатып алыр алдыннан да, аның сыйфатлы материалдан эшләнгәненә инанырга кирәк.

✷Тар джинсы чалбар. Ул аяк шешү, кан әйләнеше начараю, ашкайнату проблемалары, тиренең оюы кебек аянычлы нәтиҗәләргә китерә. Даими рәвештә тар чалбар киеп йөргән кешенең сөякләренең формасы үзгәрә.

✷Артык биек үкчәле яисә яссы табанлы аяк киеме. Без үкчәле аяк киеменнән йөргәндә, авырлыгыбыз табан буенча тигез җәелми. Иң күп авырлык аяк бармакларына төшә. Шуңа кадак үкчәле туфли киеп йөрергә яратучыларның аяк формасы үзгәрә. Биек үкчә умыртка сөягенә дә зыян сала. Шулай ук артрит, артроз, сөялләр, буыннарның үзгәрүе, варикоз, умыртка сөягенең кәкрәюенә китерә. Тик тип-тигез табанлы аяк киеме дә зыянлы. Шуңа да аяк киеме сайлаганда, табанның биленә туры килә торганын сатып алырга кирәк.

✷Чәпелдәвек (шлепанцы). Бу аяк киеме йөрешне үзгәртә. Шлепанцы аяктан очып китмәсен өчен, безгә кечкенә адымнар белән генә йөрергә туры килә, аяк бармаклары гел киеренке хәлдә була. Бу буыннар тартылу, мускулларга көч килү, шешенү, көзән җыеруга китерә. Шуңа да комлыкта кияр өчен чыгарылган мондый аяк киемен озак киеп йөрмәскә кирәк.

✷ Бер иңбашына аса торган авыр сумка. Сумканы әле бер, әле икенче иңбашына асып йөртергә кирәк. Сумканың авырлыгы гәүдә авырлыгының 10 процентын гына тәшкил итәргә тиеш. Иң яхшы альтернатива – киң баулы рюкзак.

✷Арзанлы бизәнү әйберләре. Андый бизәнгечләр составында куркыныч металлар һәм химикатлар булырга мөмкин. Галимнәр бу уңайдан уздырылган махсус тикшеренү вакытында Кытайда ясалган 103 бизәнгечнең 12 процентында кадмий барлыгын ачыклаган. Ә ул иң агулы металл булып санала.

Сорау – җавап

Күз ник тарта?

?Бер айдан бирле сул як күзем тарта. Башта артык борчымый иде, хәзер торган саен ешая бара. Кул белән ышкып җибәрсәң, беразга туктап тора, аннан тагын үзен сиздерә. Организмга берәр витамин җитешмәүдән микән бу?

Алсу ХӘЛФИНА. Арча

Сорауга табиб-невропатолог Луиза Шәмсиева җавап бирә:
– Күз тарту еш кына нерв системасы эшчәнлеге бозылу аркасында килеп чыга. Салкын тию, күзгә җил бәрү, төрле борчылу, стресс кичерү (нервлар артык киеренке хәлдә булганлыктан) аркасында да барлыкка килә ул. Сезгә тиз арада районыгыздагы невропатологка күренергә кирәк. Күз табибында тикшеренсәгез дә комачау итмәс. Алар күз тартуның нидән килеп чыгуын төгәл ачыклар һәм дәвалау чараларын билгеләр.

Яхшы хәбәр

БӘРӘҢГЕ АЯККА БАСТЫРГАН

Икенче «икмәк»нең бу сыйфатын Альма Нексе дигән галимә ачкан. Ул үз-үзен бәрәңге белән полиартриттан дәвалаган. Ә аңарчы 20 ел инвалид арбасында утырган.

Көннәрдән бер көнне ул гаҗәп төш күргән. Төшендә аңа дәвалану юлын күрсәтәләр. Кабыклы бәрәңгене бик озаклап пешерергә, суы белән бергә төяргә һәм шул ботканы көне буе ашарга кирәк икән. 2 атна үтмәгән, бәрәңге Альманың хәлен җиңеләйткән. Бераздан ул аягына баса, сәламәтләнә. 70 яшендә дә зифа буйлы актив хатын була ул.

Чеген халкы элек-электән ревматизм белән полиартритны дәвалауда бәрәңге куллана. Моның өчен иртән ач карынга бер бәрәңге, аннары бер яки ике кабыклы килеш пешерелгән бәрәңге ашарга киңәш ителә. Тоз кулланмаска. Дөрес, дәвалану өчен яңа бәрәңге яхшы. Яңа елга кадәр ул файдалы матдәләрен югалтмый әле.

ЯШЕЛ КӘБЕСТӘ КОТКАРА

Хәтерне яхшыртыйм дисәң, брокколи аша. Ул холин һәм К витаминына бай. Алар ярдәмендә сүз белән әйтелгән мәгълүматны кабул итү һәм эпизодик хәтер яхшыра, ул вакыйгаларны җентекләп теркәп бара. Брокколида шулай ук ацетилхолинның таркалуына комачаулый торган глюкозинолатлар бар, бу – нерв импульсларын тапшыручы нейромедиатор. Шулай итеп, брокколи нерв системасының эшен җайга сала һәм баш мие эшчәнлегенә уңай йогынты ясый.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА

ГӨЛ КӘЕФНЕ КЫРМАСЫН

Бүлмәне ямьләүче гөлләр кем өчендер бәлагә әверелергә мөмкин. «Без бөтенләй дә зарарсыз дип санаган гөлләрнең аллергия чыганагы булуы бар», – ди һәвәскәр бакчачы Гөлфия ХӘНИПОВА.

Моңа түбәндәгеләр сәбәпче булуын әйтте бакчачы.
- Чәчәк ата торган бүлмә гөлләре серкәсе.
- Артык дымлы бүлмәдә яки артык су сибүдән гөлләрнең туфрагында һәм яфракларында барлыкка килгән кугәрекләр.
- Гөл яфрагына утырган тузан.
- Кибеттә сатыла торган бүлмә гөлләре өчен ашлама һәм пестицидлар.
- Кайбер гөлләр бүлеп чыгара торган сөт сыман сок.

Күпләрнең яратып үстергән гөлләрен аллергиягә сәбәпче гөлләр исемлегендә күргәч, кәефләре кырылыр, әлбәттә. Тик аларны белеп тору беркемгә дә зыян итмәс.

Яран

Яран яфракларында бик күп микъдарда эфир майлары бар, шунлыктан аның исе бик көчле. Кагылып киткәндә әлеге матдәләр борын куышлыгы ялкынсынуга, ә исе баш авырту һәм күңел болгануга сәбәпче булырга мөмкин.

Диффенбахия

Аны үстермәвең хәерле. Ул агулы үсемлек санала. Тирегә тиеп киткәндә җитди зыян салырга, хәтта пешкән сыман эз дә калдырырга мөмкин.

Фикус

Иң популяр, күпләр мәшәкате дә юк, дип, үз итә торган гөл. Аның зур ялтырап торган яфраклары теләсә кемне «яраттыра». Әмма фикус бүлеп чыгара торган сок тирегә тигәндә пешерергә, ә яфракларына утырган тузан йөткертергә һәм төчкертергә мөмкин.

Спатифиллум

Әлеге гөлне дә ак чәчәкләренә кызыгып һәм мәшәкате булмаганга яратып үстерәләр. Әмма аның серкәләрендәге кальций оксалаты борын куышлыгы ялкынсынуга сәбәпче булырга мөмкин.

Сансевиерия

Әллә ни уңай шартлар булмаса да, яктылык җитмәсә дә, әлеге гөл үзен бик яхшы хис итә. Халык телендә «тещин язык» дип йөртелә торган гөл өй шартларында бик сирәк чәчәк ата. Аның серкәләре аллергиягә сәбәпче булырга мөмкин. Бүлеп чыгара торган согы тәнгә тигән очракта шулай ук ялкынсыну китереп чыгара ала.

Миләүшә

Вак матур чәчәкле, бернинди зарарсыз тоелган миләүшәләр үпкәгә зыян салырга мөмкин, чөнки аның өслегенә бик күп тузан утыруны сизмибез дә. Аның йөнтәс яфракларында тузан талпаннары ишәергә мөмкин. Шуңа күрә аның яфракларын дымлы салфетка белән даими рәвештә сөртеп торырга кирәк.

Белеп тор!

Бәйрәм рухы

Рамазан аенда өйне үзенчәлекле итеп бизәргә була. «Рамазан мөбарәк булсын!» дип язылган плакат, төрле баннер һәм гирляндалар әзләргә мөмкин. Бу, бердән, истә тоту өчен күрсәтмә булса, икенчедән, бизәк булачак. Әлеге эшкә балаларны да җәлеп итсәгез, алар, бик куанып, сезгә ярдәм итәр. Төсле катыргылардан ярымай, йолдыз һәм йөрәк формасындагы түгәрәкләр кисеп, бүлмәләрне бизәү бәйрәм рухы өстәячәк.

Шулай ук ифтарда Коръәннән аять яки хәдис язылган открыткалар тарату да якыннарыгыз күңеленә хуш килер.

Тәмле булсын!

ШАМПИНЬОН МАРИНАДЛАУ

Кирәк:
400 г шампиньон, 1 чәй кашыгы тоз, 2 чәй кашыгы гәрчич, 2 аш кашыгы лимон согы, 4 тырнак сарымсак (эре булса, 2 дә җитә), ярты суган, петрушка, укроп, 1 аш кашыгы үсемлек мае, 80 мл кайнап чыккан кайнар су.

Әзерләү
Шампиньонны кыздырып алабыз. Савытка гөмбәне һәм башка барлык ингредиентларны салып, капкач каплап, яхшылап селкетеп болгатабыз. Аннары 2 сәгатькә суыткычка куябыз. Табынга бирер алдыннан май салып болгатабыз.

Исеңдә тот!

Акны сода агарта

Ак кроссовка, кедыларны яратмаган кеше юктыр, ә менә аны чистартырга яратучылар гына табылмас. Түбәндәге ысулны кулланып карасагыз, ак аяк киеменнән башка йөз чөермәссез. Бераз теш пастасына савыт-саба юа торган гель, сода өстибез дә щетка белән ак төстәге аяк киемен яхшылап чистартабыз. Чиста су белән чайкагач, аяк киеме ялт итәр.

«Күз ату» уены

Күзләрегез арыганда рәсемдәге, күнегүләрне көн дәвамында ясап алыгыз. Күзлексез яки линзасыз ясасагыз, файдасы тагын да яхшырак булыр.

1. Күзегезне зур итеп ачып, аска һәм өскә йөртегез.
2. Сәгать теле уңаена һәм кирегә таба күзләр белән түгәрәк ясагыз.
4. Күзләр белән квадрат ясагыз.
5. Карашны дугалар буенча йөртегез.
6. Күзләрне ромб буенча йөртеп чыгыгыз.
7. Күзләр белән бант ясагыз.
8. Горизонталь һәм вертикаль S хәрефе буенча йөртегез.
9. Күзләр белән вертикаль дугаларны башта сәгать теле уңаена, аннары сәгать теленә каршы ясагыз.
10. Күзләрне бер почмактан икенчесенә таба диагональ буенча йөртегез.



11. Бармакны борынга куеп, күз карашын бераз көч килерлек итеп, әлеге уклар буенча бер-берсенә якын китерәбез.
12. Күбәләк канатларын каккан сыман еш-еш итеп, күзне ачкалап йомгалыйбыз.

Укучы киңәше

«ЭКСИБИШЕН»ЫМ УҢДЫ

Узган ел хәзер бик популяр булган «Эксибишен» суганын утыртып караган идем. Уңышы бик яхшы булды, шуңа үз тәҗрибәм белән уртаклашырга телим.

Суган орлыгы кабында алдан эшкәртергә кушылмаса, шул килеш утыртырга мөмкин. Язылмаган булса, 1 л суга 1 г марганцовка исәбеннән катнашма ясап, орлыкны 45 минут чамасы шунда тотып алырга кирәк. Аннары суын түгеп, орлыкны киптерәсе. Суганның тамырлары хәйран озын була, шуңа күрә биеклеге 15–20 сантиметрдан ким булмаган савыт сайлагыз. Үсенте үстерә торган туфрак салып, шунда орлыкларны чәчәбез. Суны пульверизатордан гына сибәргә кирәк. Алар берәр атнадан тишелеп тә чыга. Суган үсентеләре бераз ныгыгач, балконга чыныктырырга чыгарырга да була. Андагы температура 6 градус җылыдан ким булмасын. Ә май урталарында, туфракта кыраулар күзәтелми башлагач, бакчага күчереп утыртырга мөмкин.

Рәсимә ГАФУРОВА. Казан

Кыяры мул була

Бакчачы блогер Рәмзия Әхмәдуллина үзе сынап караган мул уңыш бирә торган кыяр сортларын санап үтте. Менә алар: Герман, Маша F1 (корнишон), Артист F1 (тәрәзә төбенә дә утыртырга мөмкин), Эколь F1, Сибирская гирлянда, Кураж, Темп F1, Адам F1, Бабушкин внучек, Зятёк, Теща.

КАБУЛ БУЛСЫН!

islam.ru

Изге рамазан аена аяк бастык. Бүген – уразаның икенче көне. Бу чорда мөселман кеше нәрсәләрне истә тотарга тиеш? Ураза тотканда нинди ялгышлардан сакланырга кирәк?

Уразага бәйле сорауларыбызга «Рөстәм» мәчете имам-хатыйбы Исмәгыйль хәзрәт БИККИНИН җавап бирде.

:: Сәхәр ашамыйча гына уразага керергә ярыймы?
– Әгәр кеше сәхәрне йоклап калдырса, ул вакытта аның уразага керергә хакы бар. Әмма белә торып сәхәр вакытын калдыру – мәкрүһ. Ник дигәндә, Мөхәммәд Мостафа салләллаһу гәләйһи вә сәлләм: «Сәхәрдә һәм ифтарда бәрәкәт бар», – дигән. Без, мөселман буларак, менә шушы бәрәкәтне алырга тиеш. Ул – Аллаһының бер бүләге. Сәхәребез һәрвакыт зур ризыктан булмаса да, ашыйсыбыз килмәсә, су эчеп, берәр җимеш ашап куйсак та, кабул булачак, иншалла. Сәхәрдә катнашу үзенә күрә аерым бер гыйбадәт, пәйгамбәребезнең сөннәте булып тора.

:: Иртән йоклап калып, ният кылынмаган булса, аны кайчанга кадәр кылып була?
– Кеше иртүк уянып, сәхәр вакытында ашамаган, иртәнге намаздан соң авызына бер ризык капмаган булса, ул өйлә намазына кадәр ниятләргә мөмкин. Рамазан аенда без ике ният кылабыз. Иң беренчесе – бу ай башланыр алдыннан без ай буе ураза тотарга ниятлибез. Ул ният безнең күңелебездә була. Икенче ният – көн саен. Йоклар алдыннан булсынмы яки иң яхшысы – сәхәр вакытында – без Аллаһының ризалыгы өчен ураза тотарга ниятләп куябыз. Рамазан аенда кешенең ниятсез генә уразага керүен күз алдына да китерү кыен.

:: Тырнак су үткәрми торган гель-лак белән буялган булса, ураза тоту рөхсәт ителәме? Гомумән, ураза тотканда бизәнергә ярыймы?
– Шәригать ягыннан караганда, әгәр хатын-кыз бизәнсә, аның уразасы бозылмый. Чөнки тән эченә нәрсә дә булса сөртелсә – крем булсынмы ул, лак булсынмы – ул аның уразасын бозмый. Тырнактагы су үткәрми торган гель-лак уразаны түгел, тәһарәтне боза. Ник дигәндә, тәһарәт алган вакытта безнең тәнебезнең һәр өлешенә су тиярга тиеш. Әгәр ураза тоткан хатын-кыз бик нык бизәнсә, артык нык хушбуй сибенсә, ул вакытта уразаның әҗер-савабы кими. Шуңа күрә ураза тоткан хатын-кызның бизәнүе күзгә ташланып тормаска, ир-атларның игътибарын үзенә җәлеп итмәскә тиеш.

:: Ураза тотканда хиҗама ясарга рөхсәт ителәме?
– Ураза тоткан кеше кан алдырса, аның уразасы бозылмый. Уразә кешенең авызыннан, борыныннан ризык, су үтеп керсә генә бозыла. Ә тәнебездән кан алу, тән эченә дәва кертү, тән өстенә дәва сылау, ярага буялган дәваларыбыз уразаны бозмый.

:: Балаңны үбү уразаны бозамы?
– Әгәр кеше – үзенең баласын, бала ураза тоткан әти-әнисен үпсә, ул уразаны бозмый. Әгәр ир белән хатын бер-берсен үбү аркасында аларның госелләре югалса, яки алар бер-берсенең сәләгәен йотса, шул вакытта ураза бозылачак. Бу көнне казага калдырырга туры киләчәк.

:: Кеше, кызып, сүгенсә, аның уразасы бозылган саналамы?
– Уразаның мәгънәсе ризыктан, эчемлектән, шәһвәтебездән, хәрам эшләрдән тыелу. Шуңа күрә уразалы кеше үзенең күңелен дә, тәнен дә Аллаһы ризалыгы өчен тыярга тырыша. Әгәр кеше ялгыш сүгенсә, ачуы купса, ул тәүбә итә (истигъфар китерә) һәм бу аның уразасын бозмый, ул аны дәвам итә. Әгәр кеше уразалы килеш махсус сүгенеп йөрсә, ул уразаның кыйммәтен югалта.

:: Авыз ачар вакыт җиткәндә генә хатын-кызның күреме башланса, аның бу көнне тоткан уразасы бозыламы?
– Әйе, уразасы бозылачак. Ифтар вакыты җитәргә биш минут кала күреме килсә дә, бу көнне тоткан уразасын, казага калдырып, яңадан тотарга туры киләчәк. Аллаһы Тәгаләбез – рәхимле, шәфкатьле зат. Хатын-кызның көн буе тоткан уразасына әҗер-савап язачак. Ләкин шушы көн өчен җаваплылык бурыч рәвешендә кала. Шуңа күрә ул аны, рамазан ае тәмамлангач, кайтарырга тиеш булачак.

:: Ураза тотмаган кеше ифтар мәҗлесенә барырга тиешме?
– Ураза тоткан кешегә авыз ачтыруның әҗер-савабы бик зур. Пәйгамбәребез: «Әгәр ифтарда бер кешенең уразасын, ризык белән ашатып ачтырсаң, аның тоткан уразасы аркасында алган әҗер-саваплары синә дә бирелер дәрәҗәдә язылачак», – дигән. Ифтар мәҗлесләрендә кеше ашап кына утырмый, вәгазь дә тыңлый. Шуңа күрә аларның кешене ислам диненә якынайту ягыннан да әһәмияте зур. Шул ук бала- чагалар ифтар мәҗлесләренә ураза тотмаган килеш килә. Хәзрәтләр моны белеп тора. Ләкин шул рәвешле кешеләр, рамазан аенда ифтарларда катнашып, еш кына үзләре дә ураза тота башлый. Шуңа күрә ифтар мәҗлесләре – ураза тоткан кешегә генә түгел, ислам диненә якыная башлаганнар өчен дә зур мөмкинлек. Бер үк вакытта алар туганлык җепләрен дә ныгыта. Шуңа күрә ифтар мәҗлесләренә ураза тотмаган кешегә дә бару рөхсәт.

:: Ураза тотучыга краб таякчыгы, креветка, мидия ише ризык ашарга ярыймы?
– Болар бар да ислам динендә тыелган ризыклар санала. Шуңа күрә ифтар мәҗлесләренә алар урынына балык ризыклары куйсак, хәерлерәк булачак.

:: Хәләл булмаган ризык белән ялгыш авыз ачсаң, көне буе тоткан уразаң кабул булмый, диләр. Бу дөрестән дә шулаймы?
– Кеше, кояш баткач, нинди генә ризык белән авыз ачса да, аның ифтары кабул була. Хәрам ризык дигәндә, ике мәгънә бар. Аларның кайберләре тышкы яктан караганда хәләл кебек тоелырга мөмкин. Мәсәлән, ипи. Аның ничек пешерелгәнен бер Аллаһы Тәгалә генә белә. Әмма безнең өчен ул хәләл булып кала. Шул ук вакытта ачыктан-ачык хәрам ризыклар бар. Хәмер, дуңгыз ите, бисмилланы әйтмичә суелган мал ите – шундыйлардан. Ураза тотучы кешенең көндәлек тормышында бу хәрам ризыклар бөтенләй булмаска тиеш. Әгәр ул, үзе дә белмәстән, хәрам ризык белән ялгыш авыз ачса, ифтар ифтардан китә, ураза, ният кабул ителә. Әмма шушы хәрам ризык өчен тәүбә итәргә кирәк, чөнки ул догаларыбызның кабул булмавына китерергә мөмкин.

:: Гайбәт сөйләү, гайбәт тыңлау уразаны бозамы?
– Аллаһы Тәгалә көдси хәдистә: «Чынлап та, кеше ураза вакытында Минем – Аллаһның ризалыгы өчен шәһвәтен, ризыгын, эчемлеген калдыра. Кыямәт көнендә Мин аңа ризалыкны үзем бирермен», – ди. Ураза – эчке гыйбадәт. Әмма ул безнең тышкы тормышыбызга, телебезгә, күзебезгә дә тәэсир итәргә тиеш. Нәрсә белән? Әйтик, шул ук әдәп-әхлакның яхшы якка үзгәрүе белән. Гайбәт сөйләү, тыңлау уразабызны бозмый. Ләкин мәгънәсен юкка чыгара. Әгәр кеше гайбәт сөйләсә, аңа уразаны яңадан тотарга кирәк түгел. Ул аны каза кылмый. Ләкин пәйгамбәребез бер хәдисендә: «Сезнең төнге намазларыгыз, көндезге уразаларыгыз кеше хакыннан, гайбәттән, алдашудан, хәрам эшләрдән тыймаса, Аллаһ сезнең гыйбадәтегезгә мохтаҗ түгел», – ди.

Уразаны боза торган гамәлләр	Уразаны бозмый, әмма мәкрүһ (шелтәле) гамәлләр	Ураза тоткан кешегә түбәндәге эшләрне башкару тыелмый
Борчак кадәр генә булса да берәр ризык, теш пастасы йоту.	Файдасыз һәм әдәпсез сүзләр сөйләү.	Балага ризык чәйнәп бирү (баланың ризыкны башкача кабул итү мөмкинлеге булмаганда).
Бер тамчы кадәр генә булса да су яки дару йоту.	Ризык һәм сагыз чәйнәү.	Күзгә сөрмә тарту.
Якынлык кылу.	Берәр азыкка телне тидереп карау.	Тәһарәт вакытында мисвәк белән тешләрне пакьләү. Әмма чистарткан вакытта бүленеп чыккан төкерекне һәм мисвәкнең кисәкләрен йотарга ярамый.
Авыз тутырып косу.	Иреннән үбү.	Кан алдыру.
Дару эчү, борынга дару салу, ингаляция, клизма ясау.	Авыз ачмыйча, ике көн рәттән ураза тоту.	Сөлек салдыру.
	Авыруыңның артачагын белеп, ураза тоту.	Гөсел коену.

Изге айның фазыйләтләре

➤Шәгъбан аеның ахыргы көннәрендә вәгазь сөйләгәндә, Аллаһ илчесе болай дигән: «Аллаһы Тәгалә бу айда ураза тотуны фарыз итте һәм өстәмә гыйбадәтләр кылу ае итеп билгеләде. Берәү өстәмә нәфел гамәлне кылса, ул барлык фарыз гамәлен кылган кебек булыр. Бу – сабырлык аедыр, ә аның әҗере – җәннәттер. Бу айда мөэминнәрнең ризыклары киңдер: берәү бу айда ураза тотучыга авыз ачтырса, муенын тәмуг чылбырыннан азат итәр һәм гөнаһлары ярлыканыр».



➤Рамазан аеның һәр кичендә Аллаһы Тәгалә өч тапкыр әйтер ди: «Миннән берәр нәрсә сораучы бармы? Теләгәнен бирермен. Миңа тәүбә итүче бармы? Тәүбәсен кабул кылырмын. Миннән гөнаһларының ярлыкануын үтенүче бармы? Гөнаһларын ярлыкармын!»

➤Рамазан аеның һәрбер көнендә авыз ачу вакытында тәмуг газабыннан бер миллион гөнаһ иясен газаптан азат итәр. Бу айда Аллаһы Тәгалә җәннәт ишекләрен ачтырып, тәмуг ишекләрен чылбыр белән уратып бикләп куяр.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ӘЛЕГЕ БИТТӘ КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ, ДОГАЛАР БУЛУ СӘБӘПЛЕ, КАДЕРСЕЗЛӘМӘВЕГЕЗ СОРАЛА

Мин = милләт

Асыл

МИРЗОЗАРИФ ЗАРИФОВ, ТАҖИК, 27 ЯШЬ

ҺИЧШИКСЕЗ, БЕЗНЕҢ ГАИЛӘДӘ ТРАДИЦИЯЛӘР, ЙОЛАЛАР САКЛАНА. Без үз телебездә иркен аралашабыз. Милли бәйрәмнәр зурлап оештырыла. Милли ашсу рецептларын да хәтерлибез.

ҮЗЕМ ДӘ ӘТИ БУЛГАЧ, БАЛАМДА МИЛЛИ ҮЗАҢ ТӘРБИЯЛӘҮНЕ ИҢ ГАДИ НӘРСӘЛӘРДӘН БАШЛАРМЫН ДИП УЙЛЫЙМ. Рәсемнәр күрсәтүдән, уенчыклардан, өйдә кулланыла торган нәрсәләрне үз телемдә аңлатудан, мәсәлән. Балачактан ук милләтебезнең мәдәниятен күрсәткән чараларга, концертларга йөрербез.

ӘЛБӘТТӘ, АТА-БАБАЛАРЫБЫЗДАН КАЛГАН ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ТУРЫНДА ДА ОНЫТАСЫ ТҮГЕЛ!

ТЕЛНЕ САКЛАУ ГАЯТЬ МӨҺИМ. Тел белән бергә үзебезнең һәм гаиләбезнең мәдәниятен генә түгел, тулы бер халыкның мәдәниятен саклыйбыз дигән сүз бит ул. **УЛ БУЫННАН-БУЫНГА ТАПШЫРЫЛЫРГА ТИЕШ!**

ВАТАНГА МӘХӘББӘТ ҺӘМ МИЛЛӘТКӘ КАРАТА ЧЫН ЯРАТУ – горурлык уята торган хисләр. Син шул милләткә карагылышлы кеше булуыңны аңлыйсың. Син шул телдә сөйләшәсең, шул йолаларны үтисең, сине бер үк нәрсәләр кызыксындыра! **ГОРУРЛАНМЫЙЧА МӨМКИН ТҮГЕЛ!**

Мирзозариф – актив егет. Эшкә дә, иҗтимагый эшчәнлеккә дә җитешә! Инде үз тиңенә өйләнергә дә өлгергән! Белеме буенча – архитектор. КФУда сәнгать мәктәбе җитәкчесе һәм кафедра ассистенты.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде. Фото: Анна АРАХАМИЯ

29 март | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ» 16+
10.00, 23.00 «ЛИЧНОЕ ПРОСТРАНСТВО» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ПАТШАБИКӘНЕҢ СОҢГЫ ЙӨРЕШЕ» 12+
13.00 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Туган авылым» 12+
14.15 «Если хочешь быть здоровым» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Бергәләп әйрәник» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Спортивная среда» 6+
00.00 «Соотечественники». Самый счастливый. Асгат Галимзянов 16+
00.25 «Таяну ноктасы» 16+
00.50 «Здоровая семья: мама, папа, я» 12+
01.05 «Если хочешь быть здоровым» 16+
01.15 «Башваткыч» 12+
02.00 «Манзара» 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Онытa алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
09.40 «Йөрәктән – йөрәккә». Рөстәм Абязов 16+
10.40 «Туган авылым» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «СИҢА КАЙТАМ». Телевизион нәфис фильм 16+
15.25 «Таяну ноктасы» 16+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
19.10, 22.10, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Ватандашлар» 16+
22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
23.10 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+
00.15 «Яшьләр тукталышы» 6+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
04.20 «Әнием нең җылы кочагы» 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
20.00 Премьера. «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «ШПИОН». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Премьера. «ПОЧКА». Многосерийный фильм (S) 16+
00.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
00.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Все хотят летать» 16+
01.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
03.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Хоккей не футбол» 16+
04.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Анекдоты» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Татьяна Лялина, Нил Кропалов, Алексей Анищенко, Олег Фомин, Ольга Кабо, Анна Большова, Вадим Андреев, Алёна Коломина, Александр Тютин. «ЗАПОЛЯРНЫЙ ВАЛЬС» 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Детективный телесериал «ДУЭТ ПО ПРАВУ» 12+
03.55 Вячеслав Разбегаев, Кирилл Плетнёв, Наталия Быстрова, Анна Гарнова, Андрей Арзяев, Дмитрий Ермак. «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.25 «Спортивный век» 12+
06.30 «Ты в бане!» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55, 16.40, 18.25, 21.40 Новости
07.05, 15.30, 21.45, 00.30 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 05.15 Специальный репортаж 12+
10.25, 04.00 «Лошадиная сила». Документальный сериал 12+
11.45 Профессиональный бокс. Тони Йока против Карлоса Такама. Трансляция из Франции 16+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
15.00 «Вид сверху» 12+
16.45 «Суперсерия 72». Документальный фильм 6+
18.30 Голевая феерия Катара! 0+
20.40 Смешанные единоборства. UFC. Ислам Махачев против Александра Волкановски. Трансляция из Австралии 16+
22.30 «Вы это видели» 12+
23.30 Боулинг. Континентальная лига. Про-тур. Трансляция из Тюмени 0+
01.00 «Магия большого спорта» 12+
01.30 «Здоровый образ. Баскетбол» 12+
02.00 Футбол. Еврокубки 2022/2023. Лучшие голы 0+
03.55 Новости 0+
05.30 «География спорта. Малиновка» 12+

НТВ

04.55 Сериал «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Детективный сериал «СТРАЖНИК» (S) 16+
22.15, 00.00 «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
00.45 Детективный сериал «ИГРА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.55 «Давай разведёмся!» 16+
09.00 «Тест на отцовство» 16+
11.15 «Понять. Простить» 16+
12.25 «Порча». «Отрезанный ломоть» 16+
12.55 «Знахарка» 16+
13.30 «Верну любимого» 16+
14.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «ЕСЛИ СЕРДЦЕ ДРОГНЕТ» 16+
19.00 «БЕЛАЯ ЛИЛИЯ» 16+
23.20 «ГОД ЗОЛОТОЙ РЫБКИ» 16+
01.35 «ИСЧЕЗНОВЕНИЕ» 16+
03.05 «Порча» 16+
03.30 «Знахарка» 16+
03.55 «Верну любимого» 16+
04.25 «Голоса ушедших душ» 16+
04.50 «Понять. Простить» 16+
05.40 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ». 7-я и 8-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 01.00 «РОЖДЕННАЯ РЕВОЛЮЦИЕЙ». «ОБОРОТНИ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ». 9-я – 12-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Бог войны. История русской артиллерии». Документальный сериал. Фильм 3-й 16+
19.40 «Секретные материалы». Документальный сериал 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «МАЧЕХА» 12+
02.40 «Долгое эхо вьетнамской войны». Документальный фильм 12+
03.30 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ». 9-я и 10-я серии 16+

30 март | Пәнҗешәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ» 16+
10.00, 00.00 «ЛИЧНОЕ ПРОСТРАНСТВО» 16+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 23.10 «ПАТШАБИКӘНЕҢ СОҢГЫ ЙӨРЕШЕ» 12+
13.00 «Кәмит Җәвит» 16+
14.00 «Туган авылым» 12+
14.15 «Рыцари вечности» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Шома бас» һәм «Алты хәреф» 0+
16.00 «Соотечественники» Абдрахман Зарифов. Учитель всесоюзного масштаба 16+
18.00 «Юлчы» 16+
19.00, 20.00 «Точка опоры» 16+
20.15 «Погружение на 100» 12+
21.10 «Соотечественники» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Наша Республика – наше дело» 16+
00.50 «Видеоспорт» 16+
01.15 «Соотечественники». Медный колокольчик Амирхана Еники 16+
01.40 «Здоровая семья: мама, папа, я» 12+
01.55 «Если хочешь быть здоровым» 16+
02.05 «Манзара» 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Онытa алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
09.40 «Кунак БиТ шоу» 16+
10.40 «Туган авылым» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «СИҢА КАЙТАМ». Телевизион нәфис фильм 16+
15.25 «Таяну ноктасы» 16+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
19.05, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Әнием нең җылы кочагы» 16+
23.10 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
00.15 «Юлчы» (субтитрлы) 16+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
04.15 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
20.00 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «ШПИОН». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Премьера. «ПОЧКА». Многосерийный фильм (S) 16+
00.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
00.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
01.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
03.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Письма» 16+
04.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Татьяна Лялина, Нил Кропалов, Алексей Анищенко, Олег Фомин, Ольга Кабо, Анна Большова, Вадим Андреев. «ЗАПОЛЯРНЫЙ ВАЛЬС» 12+
23.25 «Вечер» 12+
02.05 «ДУЭТ ПО ПРАВУ» 12+
03.55 Вячеслав Разбегаев, Кирилл Плетнёв, Наталия Быстрова. «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.25 «Спортивный век» 12+
06.30 «Вид сверху» 12+
07.00, 08.35, 10.05, 14.55, 16.40, 18.25, 21.40 Новости
07.05, 15.30, 21.45, 00.30 Все на Матч! Прямой эфир
08.40 Биатлон. Pari Чемпионат России. Одиночная смешанная эстафета. Прямая трансляция из Ханты-Мансийска
10.10, 03.40 Спецрепортаж 12+
10.30, 04.00 «Лошадиная сила» 12+
11.40 Биатлон. Pari Чемпионат России. Смешанная эстафета. Прямая трансляция из Ханты-Мансийска
13.30 «Есть тема!» Прямой эфир
15.00 «Большой хоккей» 12+
16.45 «Тош» 12+
18.30 Футбол. Чемпионат мира-2022. Финал. Аргентина – Франция. Трансляция из Катара 0+
22.30 Бильярд. «BetBoom Лига чемпионов». Финал. Трансляция из Москвы 0+
01.00 Биатлон. Pari Чемпионат России. Одиночная смешанная эстафета. Трансляция из Ханты-Мансийска 0+
02.05 Биатлон. Pari Чемпионат России. Смешанная эстафета. Трансляция из Ханты-Мансийска 0+
03.55 Новости 0+
05.05 «Ты в бане!» 12+
05.30 «Третий тайм» 12+

НТВ

04.55 Сериал «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Детективный сериал «СТРАЖНИК» (S) 16+
22.15, 00.00 Остросюжетный детектив «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
00.55 «Позднякoв» 16+
01.05 «Мы и наука. Наука и мы» 12+
01.55 Детективный сериал «ИГРА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.00 «Давай разведёмся!» 16+
09.00 «Тест на отцовство» 16+
11.15 «Понять. Простить» 16+
12.25 «Порча». «Гончий пёс» 16+
12.55 «Знахарка» 16+
13.30 «Верну любимого» 16+
14.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.40 «БОЛЬШЕ, ЧЕМ ПРИКОСНОВЕНИЕ» 16+
19.00 «СЛУЧАЙНЫЕ ВСТРЕЧИ» 16+
23.10 «ОДИНОЧЕСТВА. NET» 16+
02.45 «Порча» 16+
03.10 «Знахарка» 16+
03.35 «Верну любимого» 16+
04.05 «Голоса ушедших душ» 16+
04.30 «Понять. Простить» 16+
05.20 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ». 11-я и 12-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20 «РОЖДЕННАЯ РЕВОЛЮЦИЕЙ». «ПОСЛЕДНЯЯ ВСТРЕЧА». Часть 1-я 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ». 13-я и 14-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
15.40 «РЫСЬ» 16+
18.20 «Специальный репортаж» 16+
18.55 «Бог войны. История русской артиллерии». Документальный сериал. Фильм 4-й 16+
19.40 «Код доступа» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «ГАРАЖ» 12+
01.10 «РОЖДЕННАЯ РЕВОЛЮЦИЕЙ». «ПОСЛЕДНЯЯ ВСТРЕЧА». Части 1-я и 2-я 12+
04.10 «ОПАСНО ДЛЯ ЖИЗНИ!» 12+

31 март | Җомга

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Вести Приволжского федерального округа»
09.15 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.15 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!»16+
09.00, 17.00 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ» 16+
10.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
11.00 «Нәсыйхәт» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00 «Ком сәгате» 16 +
13.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я» 12+
14.30 Новости Татарстана 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан»16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Тизрәк! Алга! Житезрәк!» һәм «Алты хәреф» 0+
16.00 «Әдәби хәзинә» 6+
18.00 «Туган җир» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Юлчы» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «КВН РТ-2023» 16+
23.10 «ОПАСНЫЙ ЭЛЕМЕНТ» 16+
01.00 «Здоровая семья: мама, папа, я» 12+
01.15 «Если хочешь быть здоровым» 16+
01.25 «ТАПШЫРЫЛМАГАН ХАТЛАР». Телевизион нәфис фильм 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Башваткыч» 12+
05.35 «Онытa алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.50 «Ком сәгате» 16+
09.50, 15.25, 00.15 «Нәсыйхәт» 16+
10.30 «Казаннан – Казанга» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 17.30, 19.30, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «СИҢА КАЙТАМ». Телевизион нәфис фильм 16+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
19.10, 22.10, 03.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Туган җир» 12+
20.30 «Заман көзгесе» 6+
23.10 «Ком сәгате» 16+
01.05 «Мин бәхетле». Ришат Төхвәтуллин концерты 16+
03.15 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
04.15 «Ком сәгате» 16+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.40 «Человек и закон» 16+
19.45 «Поле чудес» (S) 16+
21.00 «Время»
21.45 «ГОЛОС» (S) 12+
23.30 «Вызов. Первые в космосе» (S) 12+
00.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «По Первое число» 16+
01.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
01.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
02.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Неформат» 16+
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
03.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
04.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Все хотят летать» 16+
04.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Футбол не хоккей» 16+
05.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Анекдоты» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Прямой эфир» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.15 Местное время. Вести-Татарстан
21.30 Премьера. «Моя мелодия» 12+
23.45 Премьера. «Улыбка на ночь». Программа Евгения Петросяна 16+
00.50 Юлия Майборода, Никита Зверев, Сергей Баталов, Юрий Назаров. «НЕПУТЁВАЯ НЕВЕСТКА» 16+
04.05 Вячеслав Разбегаев, Кирилл Плетнёв, Наталия Быстрова, Анна Гарнова, Андрей Арзяев, Дмитрий Ермак. «ПЫЛЬНАЯ РАБОТА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.25 «Спортивный век» 12+
06.30 «Большой хоккей» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55, 21.55 Новости
07.05, 15.00, 17.30, 22.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 05.15 «Лица страны. Светлана Ишмуратова» 12+
10.25, 04.00 «Лошадиная сила». Документальный сериал 12+
11.50 Смешанные единоборства. INVICTA FC. В. Мачадо против Дэнни Маккормак. Трансляция из США 16+
13.00 «Есть тема!» Прямой эфир
15.30 Смешанные единоборства. One FC. Прямая трансляция
17.55 Мини-футбол. Чемпионат России. PARI-Суперлига. «Тюмень» – «Кристалл» (Санкт-Петербург). Прямая трансляция
19.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. 1/4 финала. Прямая трансляция.
22.50 «Суперсерия 72». Документальный фильм 6+
00.30 Фехтование Международный турнир. Женщины. Трансляция из Казани 0+
02.00 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины 0+
03.55 Новости 0+
05.30 «РецепТура» 0+

НТВ

04.55 Сериал «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «ДНК» 16+
17.55 «Жди меня» 12+
20.00 Премьера. Детективный сериал «СТРАЖНИК» (S) 16+
22.15 Остросюжетный детектив «НЕВСКИЙ. ОХОТА НА АРХИТЕКТОРА» (S) 16+
00.00 «Своя правда» 16+
02.00 «Захар Прилепин. Уроки русского» 12+
02.25 «Квартирный вопрос» (0+
03.20 «ИГРА» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.55 «Давай разведёмся!» 16+
08.55 «Тест на отцовство» 16+
11.10 «Понять. Простить» 16+
12.15 «Порча». «Безымянный палец» 16+
12.45 «Знахарка» 16+
13.20 «Верну любимого» 16+
13.55 «Голоса ушедших душ» 16+
14.30 «БЕЛАЯ ЛИЛИЯ» 16+
19.00 «СЕРАЯ МЫШЬ» 16+
23.15 «Я ТРЕБУЮ ЛЮБВИ!» 16+
02.45 «Порча» 16+
03.10 «Знахарка» 16+
03.35 «Верну любимого» 16+
04.05 «Голоса ушедших душ» 16+
04.30 «Понять. Простить» 16+
05.20 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.40 «БЕЛЫЕ ВОЛКИ». 13-я и 14-я серии 16+
07.50, 09.20 «К ЧЕРНОМУ МОРЮ» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
10.00 «РОЖДЕННАЯ РЕВОЛЮЦИЕЙ». «ПОСЛЕДНЯЯ ВСТРЕЧА». Часть 2-я 12+
12.00, 13.20 «РАЗРЕШИТЕ ТЕБЯ ПОЦЕЛОВАТЬ» 16+
14.25, 15.05 «РАЗРЕШИТЕ ТЕБЯ ПОЦЕЛОВАТЬ... СНОВА» 16+
15.00 Военные новости 16+
17.10, 18.40 «РАЗРЕШИТЕ ТЕБЯ ПОЦЕЛОВАТЬ...НА СВАДЬБЕ» 16+
19.55 «РАЗРЕШИТЕ ТЕБЯ ПОЦЕЛОВАТЬ...ОТЕЦ НЕВЕСТЫ» 16+
22.00 «Здравствуйте, товарищи!» Премьера! 16+
23.00 «Музыка+». Премьера! 12+
00.10 «РАФФЕРТИ». 1-я – 3-я серии 16+
03.25 «Шарль де Голль. Его Величество Президент». Документальный фильм 12+
04.15 «БЛИЗНЕЦЫ» 6+
05.35 «Москва – фронту» 16+

1 апрель | Шимбә

ТАТАРСТАН

08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
07.00 «Sиңа Миннән Sәлам» 16+
09.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00 «Туган авылым» 12+
11.20 «Сула!» Ришат Төхвәтуллин концерты 12+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 16+
13.00 «Ватандашлар» 16+
13.30 «Созвездие – Йолдызлык-2023» 6+
14.30 «Халкым минем...» 12+
15.00 «Наша Республика – наше дело» 16+
16.00 «Уроки истории» 6+
17.00 «Татар халык җырлары» 0+
17.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
19.30 Новости в субботу 16+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
21.30 Новости в субботу 16+
22.00 «Кунак БиТ шоу» 16+
23.25 «БЕГЛЕЦЫ» 12+
01.00 «Спортивная среда» 6+
01.25 «Вехи истории». Большой террор в Татарии 16+
01.50 «Сула!» Ришат Төхвәтуллин концерты 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә». Рөстәм Абязов турында телеочерк 16+
07.00, 15.15 «Sиңа Миннән Sәлам» 16+
09.00 «Кәмит Җәвит» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00 «Башваткыч» 12+
12.05, 19.05, 03.50 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Туган авылым» 12+
13.20 «Су буенда учак яна». Концерт 6+
14.20 «Йөрәктән – йөрәккә». Рөстәм Абязов турында телеочерк 16+
17.15 «Мәхәббәт чишмәләре». Зөһрә Шәрифуллина җырлый 6+
17.45 «Халкым минем» 12+
18.15 «Башваткыч» 12+
20.00 «Адымнар» 16+
20.30 «Акча корты». «Мунча ташы» татар эстрада театры спектакле 16+
23.25 «СИҢА КАЙТАМ». Телевизион нәфис фильм 16+
03.00 «Башваткыч» 12+
04.40 «Юлчы» (субтитрлы) 16+
05.05 «Халкым минем» 12+
05.30 «Нәсыйхәт» 16+

1 КАНАЛ

06.00 Телеканал «Доброе утро. Суббота»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 Премьера. «Поехали!» 12+
11.10 Премьера. «ПроУют» (S) 0+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «ПО ЗАКОНАМ ВОЕННОГО ВРЕМЕНИ 3». Многосерийный фильм (S) 12+
16.35 К 75-летию Владимира Винокура (S) 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Премьера. «Первое апреля как повод для улыбки» (S) 16+
21.00 «Время»
21.35 «Сегодня вечером» 16+
23.15 Эммануэль Дево в фильме «МАДАМ ПАРФЮМЕР» (S) 12+
01.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
01.50 ПОДКАСТ.ЛАБ «Анекдоты» 16+
02.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
03.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
04.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
04.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Триггеры» 16+
05.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Местное время. Вести-Татарстан
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
11.30 «Доктор Мясников». Медицинская программа 12+
12.35 Елена Захарова, Сергей Астахов, Владимир Яглыч. «ПРИНЦЕССА И НИЩЕНКА» 16+
15.05 К 75-летию Владимира Винокура. «Аншлаг и Компания» 16+
17.00 Вести
18.00 «Привет, Андрей!» Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
20.00 Вести
21.00 Премьера. Татьяна Ратникова, Константин Соловьёв, Илья Ильиных, Елена Дробышева, Вадим Андреев. «ИЗ ЗАМКНУТОГО КРУГА» 16+
00.35 «ГРАЖДАНСКАЯ ЖЕНА» 12+
04.00 «ТРЕТЬЯ ПОПЫТКА» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Спортивный век» 12+
06.30 «Магия большого спорта» 12+
07.00, 08.35, 13.40, 21.30 Новости.
07.05, 13.10, 16.00, 19.15, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир.
08.40 Биатлон. Pari Чемпионат России. Эстафета. Женщины. Прямая трансляция из Ханты-Мансийска.
10.35 «КОМАНДА МАТЧ». Анимационный сериал 0+
10.45 «БОЛЕК И ЛЁЛЕК». Мультипликационный фильм 0+
11.00 «Вы это видели» 12+
11.40 Биатлон. Pari Чемпионат России. Масс-старт. Мужчины. Прямая трансляция из Ханты-Мансийска.
13.45 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. «Динамо» (Москва) – «Сочи». Прямая трансляция
16.45 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. Финал конференции. Прямая трансляция
19.25 Футбол. Чемпионат Германии. «Бавария» – «Боруссия» (Дортмунд). Прямая трансляция
21.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Ювентус» – «Верона». Прямая трансляция
00.30 Фехтование. Международный турнир. Мужчины. Трансляция из Казани 0+
02.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. 1/4 финала 0+
03.55 Новости 0+
04.00 Karate Combat 2023. Прямая трансляция из США

НТВ

05.05 «Жди меня» 12+
05.50 Остросюжетный сериал «ВИЖУ-ЗНАЮ» 16+
07.25 «Смотр» 0+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «Поедем, поедим!» 0+
09.20 «Едим дома» 0+
10.20 «Главная дорога» 16+
11.00 «Живая еда» с Сергеем Малозёмовым 12+
12.00 «Квартирный вопрос» 0+
13.00 «Модный vs Народный» 12+
14.20 «Своя игра» 0+
15.20 «Игры разумов» 0+
16.20 «ЧП. Расследование» 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение» с Вадимом Такменевым
20.20 «Страна талантов». Новый сезон (S) 12+
23.00 «Ты не поверишь!» 16+
00.00 «Международная пилорама» с Тиграном Кеосаяном 18+
00.40 «Квартирник НТВ у Маргулиса». Группа «Рекорд Оркестр» (S) 16+
02.05 «Дачный ответ» 0+
03.00 Лев Дуров, Полад Бюльбюль оглы, Мухтарбек Кантемиров. «НЕ БОЙСЯ, Я С ТОБОЙ! 1919» 12+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.35 «Предсказания 2023» 16+
07.25 «ДЕВИЧИЙ ЛЕС» 16+
11.15 «Пять ужинов» 16+
11.30 «ПАРФЮМЕРША». 1-я – 8-я серии 16+
19.00 «ВЕТРЕНЫЙ». 222-я – 228-я серии 16+
00.45 «ТЫ МОЙ» 16+
04.00 «ИСЧЕЗНУВШАЯ» 16+
05.35 «6 кадров» 16+
05.40 Предсказания 2023 16+

ЗВЕЗДА

06.10 «МАТРОС ЧИЖИК» 6+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
08.15 «Морской бой» 6+
09.30 «БОЛЬШАЯ СЕМЬЯ» 12+
11.45 «Легенды музыки». Алексей Рыбников 12+
12.10 «СССР. Знак качества» с Иваном Охлобыстиным» 12+
13.15 «Не факт!» 12+
13.40 «Война миров». Документальный сериал 16+
14.30 «Легенды кино». Г. Милляр 12+
15.15 «Время героев». Премьера! 16+
15.35 «Главный день». «Ансамбль «Березка» и Надежда Надеждина» 16+
16.25, 18.30 «ПРИКАЗАНО ВЗЯТЬ ЖИВЫМ» 12+
18.55 «ЛИЧНОЕ ДЕЛО МАЙОРА БАРАНОВА» 16+
21.00 «Легендарные матчи» 12+
00.00 «Десять мгновений». Ольга Белова. Премьера! 12+
00.55 «СИЦИЛИАНСКАЯ ЗАЩИТА» 12+
02.25 «ВРЕМЯ СВИДАНИЙ» 12+
03.30 «ВЗЯТКИ ГЛАДКИ» 16+

2 апрель | Якшәмбе

ТАТАРСТАН

08.00 Местное время. Воскресенье

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 Виталий Агаповның юбилей концерты 12+
08.00 «Адымнар» 16+
08.30 «Полосатая зебра» 0+
08.45 «Әти һәм мин» 0+
09.15 «Тамчы- шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 0+
10.15 «Ачыктан-ачык». И. Биктаһиров 16+
11.00 «Туган авылым» 12+
11.30 «Тархан» 12+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество» 16+
13.00 «Адымнар» 16+
13.30 «Погружение на 100» 12+
13.40 «Татар сүзе» 0+
14.00 «Созвездие – Йолдызлык-2023» 6+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
16.00 «Ком сәгате» 16+
17.00 «Видеоспорт» 16+
17.30 «Соотечественники» 16+
18.00 «Башваткыч» 12+
19.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30 «Болгар радиосы» 12+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16 +
22.00 «Семь дней» 16+
23.00 «ОДИНОКАЯ ЖЕНЩИНА ЖЕЛАЕТ ПОЗНАКОМИТЬСЯ» 6+
00.35 «Ком сәгате» 16+
01.25 «Кыр үрдәге». Концерт 12+
02.00 «Манзара» 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Заман көзгесе» 6+
06.30 «Татар халык җырлары» 6+
07.00 «Адымнар» 16+
07.30 Татарстанның атказанган артисты Фердинанд Сәлаховның юбилей кичәсе 16+
09.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
10.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
10.30 «Калеб» 6+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05 «Яшьләр тукталышы» 6+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00 «Туган авылым» 12+
13.20 «Музыкаль мәйдан» 16+
13.40 Р.Батулла. «ЗӘЙТҮНӘКӘЙ». Г.Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театры спектакле 16+
15.05 «Мин бәхетле». Ришат Төхфәтуллин концерты 16+
16.20 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит» 16+
19.05 «Ком сәгате» 16+
20.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
21.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
21.50 К.Тинчурин. «ҖИЛКӘНСЕЗЛӘР». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
00.40 «Яшьләр тукталышы» 6+
01.05 «Манзара» 16+
02.45 «Адымнар» 16+
03.15 Т.Миңнуллин. «БЕЗ КИТӘБЕЗ, СЕЗ КАЛАСЫЗ». Телефильм 16+

1 КАНАЛ

06.00 Новости
06.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «Все хотят летать» 16+
06.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.40 «Часовой» (S) 12+
08.10 «Здоровье» 16+
09.20 «Мечталлион» (S) 12+
09.40 «Непутевые заметки» 12+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 «Жизнь своих» (S) 12+
11.10 «Повара на колесах» 12+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Премьера. «ИСТОРИЯ ЛЮБВИ ШАХЕРЕЗАДЫ» (S) 0+
13.55 К 90-летию Александра Митты. «О любви, компромиссах и предчувствиях» 12+
14.50 «ГОРИ, ГОРИ, МОЯ ЗВЕЗДА» 0+
16.40 «Век СССР». Часть 1 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
19.00 «Три аккорда». Новый сезон. Финал (S) 16+
21.00 «Время»
22.35 «Что? Где? Когда?» Весенняя серия игр (S) 16+
23.45 «На футболе» (S) 18+
00.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Гори огнем» 16+
00.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «По Первое число» 16+
01.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «АстроУмные» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
02.50 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
03.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Произвольная программа» 16+
04.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
04.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Письма» 16+

РОССИЯ 1

06.00 Анастасия Стежко, Борис Хвошнянский, Инна Коляда, Станислав Эрдлей. «ПРОСТАЯ ДЕВЧОНКА» 12+
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома»
09.25 «Утренняя почта»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
11.30 Премьера. «Большие перемены»
12.35 «ПРИНЦЕССА И НИЩЕНКА» 16+
17.00 Вести
18.00 Премьера. «Песни от всей души». Вечернее шоу Андрея Малахова. 12+
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 «Воскресный вечер» 12+
01.30 «ПРОСТАЯ ДЕВЧОНКА» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Спортивный век» 12+
06.30 «Магия большого спорта» 12+
07.00, 08.35, 13.40 Новости
07.05, 16.00, 19.15, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
08.40 Биатлон. Pari Чемпионат России. Масс-старт. Женщины. Прямая трансляция из Ханты-Мансийска
10.05 «С БОРУ ПО СОСЕНКЕ». Мультипликационный фильм 0+
10.20 «СТАДИОН ШИВОРОТ-НАВЫВОРОТ». Мультфильм 0+
10.30 «География спорта. Малиновка» 12+
11.00 Биатлон
11.50 Биатлон. Pari Чемпионат России. Эстафета. Мужчины. Прямая трансляция из Ханты-Мансийска
13.45 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. «Химки» (Московская область) – «Краснодар». Прямая трансляция
16.45 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. Финал конференции. Прямая трансляция
19.40 Смешанные единоборства. One FC. Виталий Бигдаш против Ренье де Риддера. Трансляция из Сингапура 16+
20.30 Смешанные единоборства. One FC. Анатолий Малыхин против Ренье де Риддера. Трансляция из Филиппин 16+
20.40 После футбола с Георгием Черданцевым
21.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Наполи» – «Милан». Прямая трансляция
00.30 Фехтование. Международный турнир. Команды. Трансляция из Казани 0+

НТВ

05.00 «ВИЖУ-ЗНАЮ» 16+
06.35 «Центральное телевидение» 16+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача» 16+
11.00 «Чудо техники» 12+
11.55 «Дачный ответ» 0+
13.00 «НашПотребНадзор» 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «Человек в праве» 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации» 16+
19.00 «Итоги недели» с Ирадой Зейналовой
20.20 «Маска». Новый сезон (S) 12+
23.40 «Звезды сошлись» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 Предсказания 2023 16+
07.20 «ТЕНЬ ПРОШЛОГО» 16+
10.55 «СЕРАЯ МЫШЬ» 16+
14.55 «СЛУЧАЙНЫЕ ВСТРЕЧИ» 16+
19.00 «ВЕТРЕНЫЙ». 229-я - 235-я серии 16+
00.45 «ПРОПАСТЬ МЕЖДУ НАМИ» 16+
04.00 «ИСЧЕЗНУВШАЯ» 16+
05.35 «6 кадров» 16+
05.40 Предсказания 2023 16+

ЗВЕЗДА

05.30 «ДОЖИТЬ ДО РАССВЕТА» 12+
06.55 «ЛИЧНОЕ ДЕЛО МАЙОРА БАРАНОВА» 16+
09.00 «Новости недели» с Юрием Подкопаевым 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.45 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Альманах №136» 16+
11.30 «Код доступа» 12+
12.20 «Легенды армии» с Александром Маршалом. Иван Борзов 12+
13.05 «Специальный репортаж» 16+
13.55, 03.45 «СИНДРОМ ШАХМАТИСТА». 1-я – 4-я серии 16+
18.00 Главное с Ольгой Беловой 16+
19.40 «Легенды советского сыска. Годы войны». Док. сериал 16+
22.05 «Просто Жизнь» 16+
23.05 «Фетисов». Ток-шоу 12+
23.50 «БОЛЬШАЯ СЕМЬЯ» 12+
01.50 «МАТРОС ЧИЖИК» 6+
03.15 «Перелом. Хроника Победы» 16+

РАДИО РОССИИ

«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?
Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

Дүшәмбе, 27 март

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50,7.50,18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10 Мөхәммәд Мәһдиев. «Без – кырык беренче ел балалары». Моноспектакль
13.10 «Татарстан дулкынында»
18.10 Яңалыклар
18.25 «Сердәшханә»
18.35 «Җыр – минем гомерлек юлдашым»

Сишәмбе, 28 март

6.00-8.00 «Новый день». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуальное интервью»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Күркәм эшләр эзеннән»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Фидакарьләр» проекты. 6 нчы тапшыру
18.25 Сирәк яңгырый торган музыкаль язмалар

Чәршәмбе, 29 март

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Юллар чатында».
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Актуальное интервью»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Время молодых»
18.25 Рөстәм Зәкуан шигырьләренә җырлар

Пәнҗешәмбе, 30 март

6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Перекресток»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «На волне Татарстана»
15.20 «Офыклар»
18.25 «Газиз тавышлар». Әлфис Кыямов язмалары

Җомга, 31 март

6.00-8.00 «Иртәнге нур». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00-7.10 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Вести ПФО
11.30 «Доброе братство лучше богатства» (на мордовском языке)
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Фидакарьләр» проекты. 4 нче тапшыру
18.25 Мөнәҗәтләр һәм бәетләр

Шимбә, 1 апрель

8.10 «Таңнар артында – таңнар». Ә. Рәшит әсәрләреннән әдәби-музыкаль композиция
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00 Трансляция радио России
10.10 «Язучылар – балаларга»
10.30 «7 көн». Атналык күзәтү
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 «Мин әтине өйрәтәм». Радиосериал
11.25 «Игелекле «Балкыш». Концерт
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 «Шигърият». Рәшит Әхмәтҗанов
15.30 «Чәчәкләр бирегез кешегә». Самат Шакир әсәрләреннән композиция

Якшәмбе, 2 апрель

8.10-9.00 «Между Волгой и Уралом». Объединенный радиожурнал семи республик
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-16.10, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней». Обзор событий недели
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Ял концерты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10, 16.10 Әхәт Гаффар. «Язлар моңы». Минзәлә ТДДТ спектакле

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«Ватаным Татарстан» газетасы коллективы, заманында редакциядә стенографистка вазыйфасында булган

Фирдәүсә ГАТИЯТУЛЛИНА

вафат булу сәбәпле, гаиләсенең, туганнарының, якыннарының авыр кайгысын уртаклаша. Фирдәүсә Гомәр кызына нибары 64 яшь иде, урыны оҗмах түрләрендә булсын!

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65,
222-09-70.
E-mail:
vtreklama@mail.ru

Сәрия МИФТАХОВА

УНАЛТЫНЧЫ ПАРТА СЫЙМАСА...

30 марттан 1 нче сыйныфка кабул итү кампаниясе башлана. Быел республикада яшәүче 55 мең сабый (шуларның 20 меңнән артыгы – Казанда) беренче тапкыр парта арасына утырыр дип фаразлана. Мәктәпне ничек сайларга? Шартлар мөһимме, белем сыйфатымы? «ВТ» хәбәрчесе беренчеләрне кабул итү буенча вазгыятьне белеште.

Урамда калмыйлар

Сабые 1 нче сыйныфка барачак әти-әниләр баласын урнаштырмыйча тынычланмый. Бигрәк тә шәһәр җирендә, мәктәпкә элэгү өчен, төнлә чират торган яки ишек төбенә иртә таңнан килеп баскан әти-әниләрне дә беләбез. Һәркайсының якындагы белем йортына эләгәсе килә. «Гаризаны кайчан һәм ничек язарга?», «Урыннар җитәрме?», «Яхшы укытучы туры килерме?», «Мәктәпне ничек итеп дөрес сайларга?» дип, редакциягә киңәш сорап шалтыратучылар да бар.

Әлмәт районында быел 1 нче сыйныфка 3107 бала килер дип фаразлана. Анда кайбер уку йортларында «К» сыйныфы ачкан мәктәпләр дә бар хәтта.

– Әти-әниләр арасында 1 нче сыйныфка кабул итү буенча бәхәсләр тумыйча калмый. Бездә яңа микрорайоннар бик күп. Шуңа күрә анда яшәүчеләрне берничә мәктәпкә беркеттек. Берсенә кермәсә, икенчесенә керәчәк. Әти-әниләргә җайлы булсын дип тырышабыз. Аларга уку йорты якын, өйдән чыгарга да тизрәк кирәргә булсын. Сүз дә юк, аларны да аңларга мөмкин. Әти-әниләргә, мәктәп киңәя торган түгел бит, дип аңлатам. Аптырагач: «Сез 4 урынлы машинагызга 15 кешене утырта аласызмы?» – дип тә сорау биргәлим. «Юк», – диләр. «Ә мәктәп нишләргә тиеш?» – дим. «Класска 15 парта куелган, уналтынчысын сыйдырып булмый бит. Шуңа күрә сезне башка мәктәпләргә дә беркеттек», – дип әйтеп тә карыйм. Аңламасалар сорасыннар, шалтыратсыннар, – ди Әлмәт шәһәре мәгариф идарәсе җитәкчесе урынбасары Галия Урманова.

Аның әйтүенчә, быел кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертелгән. Хәрби операциядә катнашучыларның балалары беренче чиратта кабул ителәчәк. Директорлар әти-әниләр җыелышында барысын да җентекләп аңлата.

– Әти-әниләрнең төрлесе бар. Әйтик, балам саф татар сыйныфында укысын, дигәннәре дә. Аларга гимназияләр тәкъдим итәбез. «Нур» хосусый мәктәбе бар. Әти-әниләр өчен шартлар да, яңа мәктәпләрдә укытучыларның тәҗрибәле булуы да мөһим. Гел яшьләр генә булмасын, диләр. Заманча уку йортына бирергә теләүчеләр дә бар. Тик 50–60 ел элек төзелгән мәктәпләрдә бассейн куеп булмый. Әмма шуны әйтә алам: күбесе яхшы белемгә кызыга, – диде Галия Урманова.

Чаллы шәһәрендәге вазгыятьне дә белештек. Мәгариф идарәсе башлыгы Рөстәм Хуҗин белдергәнчә, быел беренчегә 8 меңгә якын бала көтәләр, бу былтыргыдан 500гә кимрәк. Ел саен бирердә 1 нче сыйныфка якынча 280 класс туплана, мәктәпләрдә татар төркемнәре дә ачыла. Шәһәрдә 11 татар мәктәбе бар.

– Урын булмау сәбәпле, теләгән мәктәпкә бара алмаган чаклар да була. Безнең максат – барлык балага да урын булдыру. Урамда калган бер бала да юк. Өстәмә урыннар ачтырабыз. Кайбер мәктәптә укучылар санына карап, 10–13әр сыйныф булдырабыз. Ике сменада эшләүче уку йортлары да бар. Анда 1 нче сыйныфларны күчермибез, әлбәттә. Мәктәпләр җитә. Быел 2 яңа мәктәп төзелә, – диде Рөстәм Хуҗин.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Укытучылар кытлыгы

Казандагы «Адымнар» күптелле белем бирү комплексы директоры Айдар Шәмсетдинов белән дә сөйләшеп алдык. Туган телне укыту турында да кызыксындык.

– Бондаренко урамында урнашкан мәктәпкә татар телен туган тел буларак өйрәнүче балаларны кабул итәбез. Дәресләрне мөмкин кадәр татар телендә укытырга тырышабыз. Әмма хәзерге вакытта татар балалары да туган теленнән читләшкән. Һәрвакыт татарлаштыруны күз алдында тотабыз һәм тормышка ашырабыз. Бичурин урамындагы мәктәптә ике телле сыйныфлар ачыла. Анда төп белем рус телендә алып барыла, ләкин уку планына республиканың дәүләт теле дә кертелгән. Кабул иткәндә, татар телен бөтенебез дә өйрәнәбез, дип ассызыклап әйтәбез, – ди Айдар Шәмсетдинов.

Ачылган елны беренчегә 649 бала кабул иткәннәр. Хәтта сыйныфлар саны «Ф»га кадәр җиткән. Узган ел укырга 500дән артык сабый килгән. Хәзерге вакытта туучыларның бераз кимүе күзәтелә. Шуңа күрә беренчегә керүчеләр саны 450–460 булыр дип көтәләр. Кергәндә имтихан алмыйлар, чөнки рөхсәт юк. Әмма балалар әзерлек төркемнәренә йөри, шуннан карап алалар.

– Безнең беркетелгән микрорайон бар, – ди директор. – Укырга теләгән барлык баланы кабул итеп була аныгы. Әмма аларны урнаштырып бетерергә, уку сыйныфлары ачарга кирәк һәм, гомумән, укытучы табу җиңел түгел. Казанда бу бик катлаулы. Дөресен әйткәндә, укытучы булам дип чират тормыйлар. Әлбәттә, бездә буш урыннар юк, әмма укытучыларның күбесе өстәмә сәгатьләр алып эшли. Тармакта һөнәр ияләре кытлыгы бар һәм аны яшерү дөрес түгел.

Түләүле белем

Казандагы инглиз телендә белем бирүче халыкара мәктәпкә керү тәртибе белән дә кызыксындык. Монда бүген 550 бала белем ала. Быел 1 нче сыйныфка 48 бала кабул итәргә җыеналар. Уку түләүле.

– Кампуска һәм яшькә карап, беренче елны 1 миллион сумга кадәр түләргә кирәк. Байлар дип әйтмик, түләргә мөмкинлеге булган гаиләләрнең балалары укый. Дүртенче ел грант ярдәме бирелә. Һәр елны уртача биш бала, шуны отып, тулысынча бушлай укый ала. Бу – өлкәнрәк сыйныфлар өчен, – диде мәктәпнең директоры Нияз Гафиятуллин. – 1 нче сыйныфка белемнәрен тикшереп алабыз. Уку инглиз телендә бит. Бездә балалар бакчасы эшли, анда 3 яшьтән йөри башлыйлар. Шуңа күрә 1 нче сыйныфка җиткәндә, берничә генә урын кала. Хәзерге вакытта өч урын бар. Әмма кайбер балалар, Россия программасы буенча укыйм дип, башка мәктәпкә күчәргә мөмкин. Безгә Чаллы, Әлмәт шәһәрләреннән, башка төбәкләрдән килүче гаиләләр дә бар.

1 нче сыйныфка кабул итү тәртибе

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгыннан мәктәпкә кабул итү кагыйдәләре турында белештек.

Кайчан башлана?

Гаризалар ике этапта кабул ителә. Беренчесе теркәлү урыны (прописка) буенча, ягъни якында урнашкан мәктәпләргә кагыла. Әти-әниләрдән гаризалар 30 марттан 30 июньгә кадәр кабул ителә. Әгәр яңашәдәге уку йорты сезне канәгатьләндермәсә яки балагызны башка райондагы уку йортына бирү җаен карасагыз, бу вакытта гариза тапшыруны икенче этапка, ягъни 6 июльгә кадәр көтәргә туры килер. Мәктәп җитәкчелеге буш урыннар булмаганда гына кабул итүдән баш тарта ала. Документлар сыйныфта укучылар саны тулганчы, ягъни 5 сентябрьгә кадәр кабул ителә. Кызганыч, теләгән мәктәптә урыннар калмаган чаклар да була. Бу очракта яшәү урыны буенча мәгариф бүлегенә барырга кирәк. Алар баланы башка мәктәпкә урнаштырырга ярдәм итәргә тиеш.

Ташламалар кемнәргә каралган?

Интернаты булган мәгариф оешмаларына тикшерү комитеты судьялары, прокурорлары һәм хезмәткәрләренең балалары чираттан тыш кабул ителә. Беренче чиратта әлеге хокуктан хәрбиләр, полиция, эчке эшләр органнары хезмәткәрләре балалары файдалана ала. Балаларның абый-апалары укыган мәктәптә укырга хакы бар. Абый-апасы кайда, эне-сеңлесе шунда. Шундый ук өстенлек тәрбиягә алган гаиләләргә дә бирелә.

Йортның кайсы мәктәпкә беркетелүен кайдан белергә?

Әлеге мәгълүмат, 15 марттан да соңга калмыйча, мәктәпләрнең сайтларында урнаштырыла.

Кирәкле документлар исемлеге:

✓ *баланың әтисе яки әнисенең (законлы вәкиленең) документы күчермәсе;*
✓ *баланың туу турында таныклыгы;*
✓ *абыйсы яисә апасының туу турында таныклыгы;*
✓ *баланы теркәү турында, беркетелгән территориядә яшәү урыны турында документ;*
✓ *ташламага ия булганда, чираттан тыш, беренче чиратта кабул итүне раслаучы документ;*
✓ *психология-медицина-педагогия комиссиясе карары (мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен)*

Әгәр сез балагызны иртә яки соңрак, ягъни 6,5 яки 8 яшьтә бирергә уйлыйсыз икән, бу очракта яшәү урыны буенча мәгариф бүлегеннән рөхсәт кәгазе алырга туры киләчәк.

Гаризаны ничек тапшырырга?

✓ *РФ һәм ТР Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша;*
✓ *белем бирү оешмасына барып;*
✓ *почта элемтәсе операторлары аша.*

Мәктәпнең сайтында кабул итү тәртибе һәм башка мәгълүматлар күрсәтелә. Әти-әниләргә укыту телен һәм туган телне сайларга кирәк булачак.

Укырга керү өчен тестлар үткәрү, имтихан алу тыелган. Мәктәпкә әзерлек төркемнәренә йөрү уку йортына керү өстенлеге бирми. Бу – түләүле өстәмә хезмәт күрсәтү. Андый дәресләр бала укырга кергәндә үзен уңай хис итсен өчен файдалы. Мондый курсларга йөртү-йөртмәүне әти-әни үзе сайлый.

mchs.tatarstan.ru

Гөлгенә
ШИҺАПОВА

ЯЗ СӘЛАМЕ

СУ БАСМАСЫН ӨЧЕН, АЛДАН ӘЗЕРЛӘНЕРГӘ КИРӘК

Татарстанда 220 торак пунктка су басу куркынычы яный. 13636 кеше язгы табигать казасыннан зыян күрергә мөмкин. Язгы ташуга әзерлек турында республиканың Гадәттән тыш хәлләргә каршы тору һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссия утырышында да сөйләштеләр. Премьер-министр урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин район-шәһәр җитәкчеләренә, язгы ташу аркасында берәү дә зыян күрергә тиеш түгел, дигән боерык куйды.

Көймә әзер

Хәл белешеп шалтыратканч, Әлмәт районының Тугай авылында яшәүче Фәния Сәгыйдуллина шатлыклы хәбәрен җиткерде. Узган ел бакчаларына, идән асларына су кереп интектерсә, быел андый мәшәкатьләре булмаган: кар эреп беткән, су җиргә сеңәргә дә өлгергән инде. «Быел беренче тапкыр су кермәде», – ди ул.

Яшел Үзәннең Татар Танае авылындагы бер урам халкы алдан хәстәрен күреп куя. Аларның бер елны да «судан коры чыга» алганнары юк. Моңа ияләшкәннәр дә инде. Кирәк-яракны өскәрәк күтәрәләр, су баскан очракта йөзеп йөрергә дип, көймәгә кадәр әзерлиләр икән. Авыл җирлеге башлыгы Фәнис Мирхәтуллин сүзләренә караганда, Гөбенә елгасы тулган инде.

– Безнең авыл урамына су кереп чыкты инде. Башка булмас дип уйлыйбыз. Әмма Гөбенә күтәрелә. Елга суы 2,5 сантиметр биеклеккә арткан, диделәр. Карлар эреп бетте инде. Елга күтәрелсә дә, ярларыннан чыкмас дип өметләнәбез, – ди ул. – Авыл халкы әзер. Ташу көтәләр. Быелгы су басу соңгысы булыр инде. Татарстан Рәисе ярдәме белән безгә 90 миллион сум акча бирделәр. Авылга елга суы кермәслек итеп, юл салып куячакбыз.

Кайбыч районының Борындык авылында яшәүче Роза Саттарова хуҗалыгына ел саен су керә. Әбекәй моңа ияләшкән инде. Әмма күңелендә курку да бар.

– Кызым, хәлемне белгәнең өчен рәхмәт, – дип башлады ул сүзен. – Су килер дип куркып торган вакытта хәл сорашуыңа да күңелем тула. Тәрәзәдән карап кына торам инде. Бу вакытта күзгә йокы керми. Бәрле елгасы тулды инде. Әмма ярларыннан ташымады әле. Өйгә дә су кермәде. Урамга да төшмәде. Берәр ел керми калса иде, дип телим. Бездә кар да эреп бетте бит инде, – ди ул.

Роза апаның өен 53 ел рәттән су баса. Шундый урынга йорт салганнарын белсәләр дә, алар аннан китми. Бар тормышны су керүгә каршы көйләп куялар. Йортлары башкаларныкыннан аермалы буларак күтәртелеп салынган. Кирәк-яраклар бәздә түгел, түбәдә саклана. Бәрәңгеләрен инде базга салмыйча булдыра алмыйлар. Аның каравы аны күршеләрдән иртәрәк чыгаралар. Чыгару дигәне лапас түбәсенә менгереп кую икән.

– Ел саен курыксам да, агып киткәнем юк бит әле дип тынычландырам үземне. Әмма борчулар эзсез үтмәде. Быел авырдым әле, кызым. Йөрәгем сиздерде. Дәваландым инде. Әнә шуңа да су керүгә аптырамаска, дидем. Баш исән булсын, – ди Роза Саттарова.

Балтач районының Борнак авылында яшәүче Зөлфия Мөбарәкшина хуҗалыгына да ел саен су керә. Янәшәләрендә Шушма елгасы җәелеп ята. Алар да балаларын алдан сызганган.

> **Белгеч сүзе**
>
> **Рафис ХӘБИБУЛЛИН, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча идарәсе башлыгы:**
> – Төп проблемаларның берсе – кечкенә елгалар. Су күселәре, агачларны аударып, сулыкларны буып куйды. Аларны вакытында чистартырга, карап торырга кирәк. Ташуга алдан әзерләнмичә булмый. Су күтәрелгән вакытта юлсыз калган, элемтә өзелгән кешеләрне дә кайгыртырга кирәк. Алар берниндән мәхрүм булырга тиеш түгел. Табибы да вакытында килсен, пенсиясен дә алсыннар, ризыклары да булсын!

– Бәрәңгеләрне базга капчыкка тутырып салган идек. Су керә башлауга тартып алу җиңел булсын, дидек. Урамыбызда биш хуҗалыкта кеше тора. Муллагали, Хәтирә һәм безне су баса инде. Өй астына булса да керә. Хәзерге ташудан куркып ятмыйбыз. 1979 елгысы төсле була күрмәсен. Мин ул чакта булды ул ташу. Акмаган нәрсә калмады. Аллаһы Тәгалә әнә шундый зурларыннан сакласын, – ди Зөлфия апа.

1979 елгы ташуны күрүчеләр арасында Мамадышта яшәүче Гөлчирә Ханова да бар. Ул чакта лапасы белән тавыклары, сарыклары, бәдрәфе, эте-мәчесе агып китә.

– Безнең йорт түбән урнашкан. Йортны ел саен иминиятләштереп куябыз. Тагын нишләп булсын инде? Башка хәсрәт килмәсен. Суны гына җиңәрбез, – ди Гөлчирә апа.

Хәлләр белешкәндә, шатлыклы хәбәрләр дә ишеттек. Узган ел «ВТ»га Биектау районының Тимофеевка авылыннан шалтыратып, күперне су басуын, утрауда калганлыкларын әйткәннәр иде. Быел сөенечле хәбәрләрен җиткерделәр.

– Сез килеп язып киткәч, ташу белән бергә «боз» да кузгалды. Ничек итеп рәхмәт әйтергә белмибез. Күпер салдырдылар бит! Хәзер безне су басмый, – диде шушы авылда яшәүче Юрий Петров.

Нормадан югары

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча идарәсе башлыгы Рафис Хәбибуллин «ВТ» хәбәрчесенә: «Берничә көн җылы торып, яңгыр да яуса, ташу булачак, су басачак», – диде. Татарстанның Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне күзәтү идарәсе башлыгы Сергей Захаров та бар нәрсәнең һава торышына бәйле булуын әйтә. Су кинәт күтәрелмәсен өчен, һава температурасының кичен салкын, көндез җылы булуы кирәк. Әлегә шулай тора. Тик менә КФУ профессоры, география фәннәре докторы Юрий Переведенцев әйтүенчә, инде бүгеннән көннәр нык җылыначак.

– Быел яз иртә килде. Гадәттәгедән 10 көн алдан җылы һава торышын күзәттек. Атлантикадан циклон килә. Җомгадан 10 градус җылы булачак. Төнлә дә температура күтәрелә. Менә шул чакта кар катламы бөтенләй эреп бетәчәк. Су күтәрелү ихтималы да зур. Әлегә бездә һава температурасы нормадан 6–7 градуска югары. Апрель аенда бераз салкынайтып та алыр ул. Әмма кояш җылысы үзенекен эшләячәк. Температура төшсә дә, без аны сизмәячәкбез, – ди ул.

Газетабызның даими синоптигы – Балтач районының Яңгул авылында гомер итүче Әмир Шәрәфиев тә әзерләнебрәк торырга киңәш итә.

– Март ае көткәннән җылы килде. Күзәтүләремнән чыгып әйтәм: ташу икегә аерылырга мөмкин әле ул. Җылы вакытта бер тапкыр булыр, аннан соң урман сулары елгага төшкәч, икенче мәртәбә күзәтелер дип уйлыйм. Ник дигәндә, март җылы тора да, апрельдә суыта. Хәтта бураннар булыр дип көтәм. Тагын бер сәбәп бар: быел каргаларның бер партиясе 5 мартта күренде. Котүләре белән 15 мартка кайтып җиттеләр. Әмма алар әле ояларына якын да килмиләр. Рәтләмиләр дә. Шуларга карап, мин әле көннәрнең суытасын әйтәм. Карганы алдап булмый ул. Җылы булса, алар ояга утырып, йомырка сала башлар иде, – ди Әмир Шәрәфиев.

Халык синоптигы сыерчыкларны да күзәткән. Алар туган якларына 18 мартта кайткан икән инде. Димәк, яз җиткән, ди ул.

> Идән асларына, өйләргә су кермичә калмас. Быел кар тигез ятты. Әмма кайбер районнарда туң бар. Чөнки кар яуды да җылытты. Шулай итеп боз катламы барлыкка килде. Чын ташуны апрельнең беренче ункөнлегендә булыр дип көтәм. Фаразларым буенча, май ае салкын килер дип уйлыйм. Алмагачлар чәчәк атканда кар явачак әле.

Нигә су баса?

Без ел саен бер үк проблема тирәсендә бөтереләбез. Без дигәнем – коткаручылар, җитәкчеләр, синоптиклар, экологлар, журналистлар. Һаман бер үк күперләрнең су астында калуын сөйлибез. Аларны үзгәртеп булмыймы соң? Буа районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Илдус Гыйззәтов та ел саен су астында калучы ике күперне белеп торуларын әйтте.

– Аларны инде бернишләтеп булмый. Бу күперләргә су керүгә әзер торырга гына кирәк. Кыят һәм Бәбки күперләрен ел да су баса. Су кимегәч, алардан йөри башлыйбыз. Әмма аңарчы авылларга керү юлларын урап узарга кирәк. Кыятка яңа юл салдык. Бу күпер аша 15 чакрым булса, яңа юлдан 20 чакрым. Бәбки авылы зур түгел. Анда юл өзелә. Шуңа күрә алдан ук хәстәрен күреп куябыз. Кирәк-яракларны илтәбез, аларны ташламыйбыз, – ди җитәкче. – Безнең якларда кар эреп бетеп бара инде. Куркыныч итеп су басмас, дип уйлыйм. Әмма ни генә булса да, район халкы ялгыз түгел. Без ташуга әзер.

Эколог Наил Назаров исә, ташуның зыяны юк, ди.

– Киресенчә, су күтәрелгәч, табигатькә файда гына. Су басканда туфрак дым туплап кала. Су киткәч, бу туфракта үсемлекләр үсә, дымлы урыннарда балыклар үрчи башлый. Менә бу яктан караганда файда гына күрәбез, – ди эколог. – Көчле су басулар булганда, әлбәттә, файда турында сүз дә юк. Кешеләргә зыяны тиячәк. Елга буйларына, сулыкларга якын яшәгән кешеләргә алдан ук хәстәрен күреп куярга кирәктер.

Казан шәһәре Башкарма комитетының Гражданнарны яклау идарәсе башлыгы Фердинант Тимерханов, су басуга халыкның ваемсызлыгы да гаепле, дигән фикердә.

– Ташуга әзерлек вакытында халыкны кисәтеп йөрибез. Казанның төрле бистәләренә чыгабыз. Исем-акылым китә: хәзер кеше көрәк тотмый, өй тирәсенә канау ясамый. Безне көтеп утыралар. Салмачы бистәсеннән чыгып әйтәм мин моны. «Ник әзрәк йорт тирәләрен кардан арындырып куймадыгыз?» – дим. «Ә сез нәрсә өчен кирәк?» – дип җавап бирәләр. Менә шулай, халык ваемсызланды. Килерләр, коткарырлар дип утырсаң, су баса инде, – ди Фердинат Тимерханов. – Шушы көннәрдә башкарма комитет башлыгы Рөстәм Гафаров белән бистәләрне тагын бер кат йөреп чыктык. Кат-кат сөйләсәк тә, проблемалар җитәрлек. Әмма һәр проблеманың «исем-фамилиясе» бар. Тиешсез урынга йорт салу, су агар өчен куеласы торбаларны оныту, бөтен бистәгә керәкле канауны хуҗасыз калдыру... Саный китсәң, әллә ниләр өстәргә була. Йортларны елгадан ераграк китеп тә салып була бит аны. Үзләре үк тилмермәс иде. Халык ташуга әзерләнми. Районнарда да эшләр акрын бара. Инде без ташу турында көздән сөйләшәбез. Һәр районда су басуга комачау итүче 20 канау бардыр инде ул. Көнгә берне чистартсалар да, 20 көн эчендә әзерләп куеп була. Яз киләсен онытмаска иде.

«ЛАЙК»КА ЛАЕКЛЫЛАР

Ильяс Баһауов коллажы

Узган елның 1 декабреннән башлап җитәкчеләргә социаль челтәрләрдә («ВКонтакте» һәм «Одноклассники») сәхифә алып баруны мәҗбүри иттеләр. Россия Дәүләт Думасы кабул иткән бу канун хакимият белән халык арасын тагын да якынайтырга тиеш дип фаразлана. Кем инде якыная башлаган, ә кемнәр виртуаль «бит»ен «әйдә, ярар» өчен генә ачкан? «ВТ» шуны тикшерде.

Тикшерү өчен район башлыкларының «ВКонтакте» социаль челтәрендәге сәхифәләре алынды (Илсур Метшин, Рамил Муллин һәм Наил Мәһдиевтән кала). Сәхифәдә барыбыз өчен дә ачык булган мәгълүмат – аудиторияне колачлау, караулар саны (уртача күрсәткеч), язылучылар активлыгы файдаланылды. Рейтинг өчен уртача саннар алынды.

Без февраль аеның бер атнасын (13–19 февраль) тикшердек. Ни өчен февральме? Чөнки закон 1 декабрьдән үк «бит»ләр ачарга кушса да, бу эшне шундук оештырып булмый әле. Гыйнвар исә – актив ай түгел, ял чоры. Март ае әле төгәлләнмәгән. Шуңа күрә тулы анализ өчен февраль ае гына кала. Искәртик: язма әзерләнгән вакыттагы саннар һәм язма чыкканнан соңгы күрсәткечләр аерылырга мөмкин.

Александр Никошин	**419**	Илдус Зарипов	**1950**
Рәис Миңнеханов	**452**	Рамил Нотфуллин	**2040**
Айдар Сәлахов	**595**	Ильяс Гозәеров	**2100**
Михаил Афанасьев	**650**	Алмаз Әхмәтшин	**2455**
Альберт Рәхмәтуллин	**675**	Аяз Шәфигуллин	**2478**
Нәҗип Хаҗипов	**798**	Вячеслав Козлов	**2741**
Рөстәм Нуриев	**1034**	Айрат Җиһаншин	**2950**
Камил Гыйльманов	**1049**	Фәрит Хөснуллин	**3000**
Наил Вазыйхов	**1120**	Радмир Беляев	**3018**
Марсель Шәйдуллин	**1150**	Марат Гафаров	**3672**
Фәргать Мөхәммәтов	**1172**	Альберт Хуҗин	**3762**
Равил Хисаметдинов	**1231**	Илһам Кашапов	**3946**
Фаил Камаев	**1400**	Ранис Камәртдинов	**4081**
Марат Зыятдинов	**1516**	Дмитрий Иванов	**4316**
Ленар Зарипов	**1583**	Ленар Нургаянов	**5166**
Радик Ислямов	**1650**	Рамил Айбәтов	**5575**
Рәмис Сафиуллов	**1701**	Рәгать Хөсәенов	**5850**
Рәзиф Кәримов	**1800**	Тимур Нагуманов	**7433**
Линар Закиров	**1850**	Илшат Нуриев	**7566**

(«ВКонтакте»дагы язмаларны уртача караулар саны, 13–19 февраль арасы)

Бер кичкә – кер «бит»кә

Әгерҗе башлыгы Ленар Нургаяновның шәхси «бит»е бик рәсми. Аның 5291 язылучысы бар. Нигездә көн дәвамында ниләр башкарганы, кемнәр белән очрашканы турында хисап тота, матур сурәтләр белән «хәерле иртә» тели түрә. Тик сәхифәсендә халык тавышы гына ишетелми. Рәсми булса да, район башлыгының «ВКонтакте»дагы хәбәрләрен дуслары яратып укый булса кирәк: язмаларында караулар саны аз түгел. 7 мең, 5 мең, 11 меңгә кадәр караулар очрый.

Азнакай башлыгы Марсель Шәйдуллин үз «бит»ендә 2753 кеше белән дус. Алдарак телгә алынган коллегасы кебек үк, рәсми «бит»кә хуҗа ул. Халык авазы биредә дә ишетелми. Нигездә сәхифәдә урыс телендәге хәбәрләр урнаштырыла. Махсус хәрби операция, җыелышлар, очрашулар – барысы да «глава»ларча. Бу аралыкта башлыкның язмаларына күз салулар саны бер меңнән әллә ни артмаган.

Аксубай башлыгы Камил Гыйльмановка язылучылар – нибары 875 кеше. Аксубай халкына җитәкчеләренә теләктәшлек күрсәтергә кирәктер. Башлыкның «бит»ендә фикер калдыру мөмкинлеге дә бар югыйсә. Кайберәүләр моннан файдалана да.

Актаныш башлыгы Ленар Зарипов та сәхифәсендә халык күплеге белән мактана алмый. Аңа нибары 237 кеше язылган. Ленар әфәнде сәхифәсен татар телендә алып бара. Рәсмилек исе килсә дә, халыкка якын булуы да сизелә. Аудиториясе аз булуга карамастан, караулар саны зур. «Лайк» та җәлләмиләр башлыкка. Ленар Зарипов хәерле иртә дә тели, җомга көнен дә игътибарсыз калдырмый.

Алексеевск башлыгының да сәхифәсен җанландырып җибәрү таләп ителә. **Сергей Демидов**ка нибары 31 (!) кеше язылган! Хәбәрләре рәсми. Аның каравы башлыкның балыкчылык турында сәхифәгә язылганын күрергә була. Хөкүмәт эшеннән бушаган арада яраткан шөгыледер инде.

Ә менә **Әлмәт башлыгы Тимур Нагуманов**ка тел-теш тидерерлек түгел. Аның социаль челтәрләрдәге активлыгы күптәннән билгеле. Күренеп тора: хакимият белән халык арасында күпер салу өчен куллана ул аларны. Аңа язылучылар саны тиздән 10 меңгә тула. Рәсми хәбәрләрне дә кызыклы итеп бирә, сәхифәдә халык активлыгы сизелә. Тимур әфәнде, атна саен «туры эфир» оештырып, кешеләрнең гозерләрен тыңларга гадәтләнгән. Администрациясе дә халык мөрәҗәгатьләрен игътибарсыз калдырмый, кайбер мәсьәләләр шунда ук җавабын да таба.

Апас районы башлыгы Айрат Җиһаншинның сәхифәсен 1020 кеше күзәтә. Иң гаҗәпләндергәне: Айрат әфәнде халык язганнарга шәхсән җавап бирергә дә вакыт таба. Әйтик, махсус хәрби операциядә катнашучыларга гуманитар йөк илтүен хәбәр иткән яңалыкка бер ханым: «Энемә сәлам әйтегез!» –дигән. Айрат Җиһаншин исә: «Алла боерса, әйтәм!» – дип җаваплаган. Күңел эретерлек сүзләр бар инде ул.

Тукай якташы – **Арча башлыгы Илшат Нуриев** та, Әлмәттәге коллегасы кебек, «ВКонтакте»да бик актив булып чыкты. Аны 9 меңнән артык кеше карый. Урнаштырган хәбәрләренә фикер белдерүчеләр дә күп. Үзе дә алар белән элемтәдә. Күпчелек яңалыклар – татар телендә.

Әтнә районын җитәкләгән Габделәхәт Хәкимовка да активлык җитми әле. 124 дустына аның сәхифәсендә бик күңелсездер.

Баулы районы башлыгы Ильяс Гозәеров 2045 кешелек сәхифәсендә нигездә кая баруы, нинди объект ачуы, кем белән очрашуы турында бәян итә. Аны караучылар саны сәхифәсендәге кешеләр санына тәңгәл килеп тора үзе. Үлем-китем, ил-көн хәбәрләренә бәйле язмаларына күз салучылар артыграк булырга мөмкин.

Балтач районы башлыгы Рамил Нотфуллин 3055 кешелек сәхифәсен нигездә татарча алып бара. Халык сорауларына да җавап бирә, «лайк»лар да куеп утыра. Аның «бит»ендәге халык та бик актив.

Бөгелмә җитәкчесе Линар Закиров ниләр эшләп йөрүләрен видеолар аша күрсәтергә ярата икән. 400ләп язылучысын рәсми хәбәрләр белән «куандырып» тора ул.

Буа районы башлыгы Ранис Камәртдинов та язылучыларының күплеге белән мактана алмас (243 кеше). Атна дәвамында нишләгәнен, кем белән очрашканын бәян итеп торган башлык, атна азагында нәтиҗә дә ясарга онытмый. Буа районы ничек яшәгән икән бу атнаны дип баш ватасы юк, шул атналык инфографикага күз салу да җитә. Башка җитәкчеләрдән аерылып торган ягы бар икән ичмаса!

Югары Ослан районы җитәкчесе Марат Зыятдинов 3455 кеше белән дус. Хәерле иртә теләп, көнен башлый башлык. Табигать сурәтләренә аеруча мөкиббән булуын аңларга мөмкин, сәхифәсенә керсәң. Халык аралашуы гына җитми.

Биектау районы башлыгы Равил Хисаметдинов сәхифәсен нибары 73 кеше күзәтә. Кызыгырлык мәгълүмат та юк шул: рәсми чаралардан сурәтләр, «алдым-бардым», «киттем-кайттым» ише яңалыклардан кызык эзләп булмыйдыр.

Чүпрәле башлыгы Марат Гафаров 7 меңләп кеше белән дус. Чын татар җанлы кеше икән: ат кочаклап басып торган фотосурәтен төп фото итеп куйган! Видеолар кертә, табигатьне үз итә булса кирәк. Ара-тирә татар телле клавиатурасы гына юкка чыгып ала менә.

Рәсмирәк, әмма халык авазы ишетелеп торган, «хәерле иртә»ле һәм «хәерле кич»ле, концертлардан өзекләр булган, кыскасы, җанлы сәхифәләрне **Чистай башлыгы Дмитрий Иванов**та (7118), **Ютазы җитәкчесе Аяз Шәфигуллин**да (3774), **Тукай районы башлыгы Фаил Камаев**та (654), **Сарман районы башлыгы Фәрит Хөснуллин**да (4248), **Мамадыш җитәкчесе Анатолий Иванов**та (3195), **Мөслим башлыгы Альберт Хуҗин**да (826), **Тәтеш җитәкчесе Рәмис Сафиуллов**та (86), **Чирмешән җитәкчесе Рамил Айбәтов**та (3836), **Яшел Үзән районы башлыгы Михаил Афанасьев**та, **Лениногорск районын җитәкләгән Рәгать Хөсәенов**та (7407) очратырга мөмкин. Соңгысында табигать күренешләре аеруча өстенлек итә. Башлыкларыбызның кайсылары шәп фотограф та икән! Ә менә **Саба районы җитәкчесе Рәис Миңнеханов** (80) социаль челтәрләр белән әллә ни дус түгел бугай. Сәхифәсендә район газетасында чыккан хәбәрләр өстенлек итә, халык аралашуы юк. **Кайбыч районы башлыгы Альберт Рәхмәтуллин**ның соңгы хәбәре 15 февральдә урнаштырылган.

Минзәлә районы башлыгы Айдар Сәлахов та (88) актив түгел. **Балык Бистәсен җитәкләгән Радик Ислямов** (334), **Нурлат районы башлыгы Алмаз Әхмәтшин** да (764) аккаунтларын коры гына алып баралар. **Теләче җитәкчесе Нәҗип Хаҗипов**ка (320), **Кама Тамагы башлыгы Наил Вазыйхов**ка (1064), **Спас башлыгы Фәргать Мөхәммәтов**ка да әле тырышасы бар. Рәсмилектән котылу **Лаеш башлыгы Илдус Зарипов**ка да (180), **Алабуга башлыгы Рөстәм Нуриев**ка да (2224), **Әлки районы башлыгы Александр Никошин**га да (78) комачау итмәс. Рәсми яңалыклардан өземтә һәм тәбрикләмәләр кертеп кенә халык күңеленә якынаеп булмый бит ул, хөрмәтлеләребез!

Яңа Чишмә районын җитәкләгән Вячеслав Козлов әнә сәхифәсендәге дусларына үзе дә җавап биреп утыра. Аны 2751 кеше күзәтә. Башлык эшчәнлеген видеолар аша күрсәтергә ярата. **Менделеевск районы башлыгы Радмир Беляев** та (694) шул юлдан атлый. **Питрәч районы башлыгы Илһам Кашапов** (122) язмаларын ике телдә урнаштырып баруы белән җәлеп итте. Ике дәүләт телен дә тигез итеп алып баруы, әлбәттә, «лайк»ка лаеклы итә аны!

«Бардым», «очраштым», «күрдем» рәвешендәге «бит»не **Кукмара башлыгы Сергей Димитриев** алып бара. 447 дусты бар, «лайк» һәм караулары шактый.

«Смайлик»лы «бит»не **Зәй башлыгы Рәзиф Кәримов** алып бара. Дуслары 2 меңнән күбрәк. «Смайл» булса да, рәсми инде, нишләтәсең.

P.S. Урталыкны саклап калган, халкы өчен чынлап та кызыклы мәгълүмат белән бүлешеп барган түрәләр бик аз. Күзәтүебезгә үпкәләмәсен иде җитәкчеләр. «Лайк»ка лаек булуыгызны эшегез, көндәлектә халыкка мөнәсәбәтегез белән бик яхшы күрсәтүегездә шик юк. Тик шуларны социаль челтәрләргә дә элеп куярга була инде.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

ҺӘРБЕРСЕНӘ БЕР ТУКАЙ

ПРЕМИЯГӘ БЫЕЛ КЕМНӘР ДӘГЪВА КЫЛА?

Әле кандидатлар исемлеге игълан ителгәнче үк, кемнең тәгаен лауреат булачагы билгеле иде шикелле. Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла Тукай премиясенә лаеклы шәхес шагыйрә Флера Гыйззәтуллина исемен атады. Бу, анынча, әлеге шәхескә карата кылынган тарихи хатаны төзәтү өчен кирәк.

Сүз уңаеннан, Флера Гыйззәтуллина кандидатурасы әлеге премиягә тугызынчы мәртәбә куела. Әмма премия күләменең ике тапкыр артып, 1 миллион сум икәне игълан ителгәч, көрәшнең кызу булачагы аңлашылды.

Шулай итеп быел Тукай бүләгенә 13 кеше дәгъва кыла. Алар – мәдәният-сәнгатьнең алты өлкәсе вәкилләре. Кемнәр соң алар һәм үзләрен ни өчен Татарстанның иң мәртәбәле бүләгенә лаек дип саный?

Театр өлкәсендә быел «Адәмнәр» спектакле белән «Әкият» курчак театры иҗат коллективы һәм Чаллы театрының «Абага алмасы ачы була» спектакле иҗат төркеме әлеге бүләккә дәгъва кыла.

Курчак театры баш режиссеры **Илгиз Зәйни** әлеге премиягә номинант булу гына да 89 еллык тарихы булган театр эшчәнлегенә зур бәя дип саный. Анынча, әшенне тану мөһим, премиянең күләме түгел:

– Бу спектакль безне Россия күләмендә әйдәп баручы театрлар рәтенә бастырды. Хәзер бик күп фестивальләргә чакыралар, безне беләләр. Шул ук вакытта, Тукай премиясенә номинант булу да – курчак театрының 89 еллык эшчәнлегенә зур бәя ул. «Адәмнәр»дә, күпләр уйлаганча, бәхәсле тема күтәрелми. Без анда сәясәт, ачлыкның барлыкка килү сәбәпләрен ачыклау белән шөгыльләнмәдек, шул хәлгә калган адәм баласы психологиясен күрсәттек. Билгеле, спектакль бу хәлләргә игътибар уятты, бактың исә яшьләрнең күпчелеге 1921 елда Идел буе халыклары кичергән ачлык турында белмәгәннәр дә икән. Алар спектакльдән соң бу мәсьәләне өйрәнә, үз фикерен булдыра икән – бик яхшы. Ник дигәндә, бу тема безнең милли кодка да салынган. Элек-электән, икмәк кыерчыгын калдырырга ярамый, ризыкны хөрмәт ит, әйбернең кадерен бел, дигән тәрбия, ачлыктан курку – барысы да канга сеңгән. Безнең әлеге премиягә баруыбыз аның күләменә бәйле түгел. Мондый эштә акча берничек тә беренче урында була алмый.

Зур премияләрне мисалга алсак та, «Оскар» булсынмы ул, «Алтын битлек»ме – анда номинантларда беренче финанс кызыксынуы юк. Чөнки аларда гомерлеккә бара торган дәрәҗәле исем, җаваплылык аласың. Татар кешесе өчен Тукай премиясе шулай.

Гадәттә кандидатлар исемлеге игълан ителгәч, матбугатта аларның хезмәтләренә бәя биргән язмалар басыла башлый. Быелгы кандидатлар арасында моны кирәкмәс гамәл дип әйтүчеләр дә бар. Илгиз Зәйни дә шундый ук фикердә. «Әгәр дә синең Тукай премиясенә дәгъва кылырлык хезмәтең бар икән, аның турында ишеткән булырга тиешләр. Сине һәм хезмәтеңне белмиләр икән, димәк, премия уставындагы «за выдающиеся заслуги» дигән билгеләмәгә туры килмисең», – ди Илгиз Зәйни. Хак сүзләр бит?

Язучы **Равил Сабыр** исә, премия әсәргә бирелә һәм авторның шушы өлкәгә фидакарьләрчә хезмәт итүе дә исәпкә алына, дигән фикердә:

– Чаллыда юк җирдә бар итеп театр төзегән, аны эшләткән, үстергән режиссер Фаил Ибраһимов лаек булса, мин һичшиксез шат булыр идем. Чөнки Тукай премиясенә беренче чиратта сәнгатьтә тирән эз калдырган шәхесләр лаек булырга тиеш дип саныйм. Алар бармак белән санарлык кына. Фаил Ибраһимов – шуларның берсе. Аңа, әйдә, үзеңне генә чыгарабыз, дип тә тәкъдим иткәннәр иде. Ул исә, театр – күмәк хезмәт, алай дөрес булмас иде, дип баш тартты.

Әдәбият өлкәсендә «Яну дәверләрендә» һәм «Вөҗдан үре – йөрәк түре» китаплары өчен Флера Гыйззәтуллина, шулай ук «Су буенда учак яна» китабы өчен Наил Касыймов һәм «Ачы җыры», «Чоңгыл», «Иман капка ачканда», «Саберем – үз җирем» җыентыклары өчен Себердән татар шагыйре Шәүкәт Гаделша кандидат булып бара.

Алар арасында, яшерен-батырын түгел, иң саллы кандидат – **Флера Гыйззәтуллина**. Шагыйрә, бу премия миңа зур җаваплылык өсти һәм аны китапларымны чыгаруга тотачакмын, дип белдерә:

– Мин – авыр язмыш кешесе. Кичергән кайгы-хәсрәтемне әле яза да башламадым дисәм дә була. Гәрчә кулдан каләмнең төшкәне булмаса да. Менә шул язмышым гел Шүрәле кебек кытыклап тора һәм Ватан турында, халык турында язарга әйди. Мин иҗат белән яшим һәм беркайчан да, Тукай премиясе алам, дип язмадым. Әгәр инде лаек дип табалар икән, ул миңа тагын да күбрәк «нагрузка» бирәчәк. Тукай исемендәге премия лауреаты булу ул бит – бик зур җаваплылык. 12 китабым булса да, үземне зур язучы дип санамадым. Әгәр инде зур язучы дип таныйлар икән, ул миңа «задурлык» өстәячәк. Мин болай да алны-ялны, ару-талуны белмим.

Әйтер сүзем дә бар: Ходай гомер бирсеп, күңелләргә иҗат куәсе дә салган икән, аны мәхәббәт темасын куертып әрәм итәргә ярамый. Ватан темасын күтәрергә кирәк. Хәзер бигрәк тә шундый чор.

Кинематография өлкәсендә премия номинантлары – «Күктау», «Байгал», «Исәнмесез?!» фильмнары өчен Илдар Ягъфәров белән Мансур Гыйләҗев, шулай ук «Заступница», «Осанна», «Святитель» документаль-нәфис трилогия өчен Алексей Барыкин.

Татар милли кинематографиясе дисәк, аның юл ярып баручысы, нәфис фильм жанрында пионеры режиссер Илдар Ягъфәров дисәк, ялгыш булмас. Казан мөселман кинофестивале 2005 елда оеша. Ә Илдар Ягъфәров 2004 елда ук «Күктау» фильмы белән «Кинотавр» фестивалендә кинопродюсерлар гильдиясе призын ала. Бу фильм ни өчендер мөселман киносы тарихына керми кала. «Брелок» кыска метражлы фильмы белән исә ул Татарстанның кино өлкәсендә потенциалы зур икәнен 2009 елда ук раслаган иде. Кино жанры бәяләнерме? Язучы, сценарийлар авторы **Мансур Гыйләҗев** менә нинди фикердә:

– Татар кино сәнгате әһелләренә Тукай премиясенең әлегә кадәр бирелгәне булмады. Дөрес, сиксәненче елларда рус режиссерына бирелде ул, әмма татар фильмына андый игътибарның әлегә кадәр күрсәтелгәне юк. Илдар белән безне нәфис фильм сәнгатенә нигез салучы дисәң дә, артык булмас. Бу эш бик авыр барды. Бердән, тәҗрибә дә юк, моңа финанс та каралмаган, Илдар исә бирешә торган кеше түгел. Чыгымнарны үзе күтәреп булса да, ерып чыга килде. Тукай премиясенә тәкъдим ителгән фильмнар – татар киносының беренче адымнары, нигезе. Алар төрле фестивальләрдә гран-при алды, Татарстанны танытты.

Сүз уңаеннан, икенче кандидат – продюсер, режиссер Алексей Барыкин Татарстанга «Су анасы», «Айсылу» кебек наив фильмнары белән дә билгеле. Ә менә премиягә Мәрьям Ана Казан иконасы турындагы «Заступница», императрица туганы Елизавета Федоровна турындагы «Осанна», патриарх Гермоген турындагы «Святитель» дигән фильмнары тәкъдим ителгән.

Музыка сәнгате өлкәсендә кандидатлар – «Халкым моңнары», «Из коллекции фольклориста: татарско-мишарские песни», «В мире татарской музыки», «Яруллиннарның туган җир җырлары», «Татарская музыка: история и современность», «Нурлат районының татар җырлары», «Очерки по татарской музыке»

хезмәтләре өчен Земфира Сәйдәшева һәм Татарстан Республикасы халыкларының җыр-инструменталь традицияләренә керткән өлеше өчен Геннадий Макаров.

Һичшиксез, саллы кандидатлар. **Геннадий Макаров** бу җәһәттән, әлеге юнәлештә башкарылырга тиешле эшләр дә саллы, дип бәяли:

– Номинантлар – музыка өлкәсендә хәл итилергә тиешле мәсьәләләрнең саллы икәненә дәлил. Сүз, әлбәттә, татар сәнгате турында бара. Татарстанда яшәүче халыкларның музыкалары да бер-берсенә бәйләнгән. Татар мәдәнияте ул үзенең эчендә дә төрле. Аларның һәрберсен өйрәнергә һәм сакларга кирәк. Чөнки алар хәзерге заман мәдәниятен баету чыганагы булып тора. Бу җәһәттән булган мирасны барлауны дәвам иттерергә кирәк. Ә иң әһәмиятлесе – фән белән гамәл бергә барырга тиеш. Бездә исә фән аерым, гамәл еш кына аерым «яши». Фәнни эзләнеп язылган хезмәтләр бик күп, ә алар бүгенге мәдәнияттә файдаланыламы? Менә бит хикмәт нәрсәдә.

Сынлы сәнгать өлкәсендә милли темага багышланган декоратив паннолар өчен Наилә Кумысникова һәм Татарстанга багышланган сәнгати фоторәсемнәр өчен Фәрит Гобәев кандидатуралары күрсәтелгән.

Фоторәсем белән күн мозаикасын янәшә кую гаҗәбрәк, билгеле. **Наилә Кумысникова** исә бу премия күн мозаикасына игътибарның булу-булмавын күрсәтәчәк дигән фикердә:

– 1958 елда Тукай премиясе гамәлгә кертелгән. Бу – минем туган елым. Беренче премияне минем әнием (сүз – Камал театры артисты Асия Хәйруллина хакында. Ул елны Камал театры коллективы Кәрим Тинчуринның «Җилкәнсезләр» пьесасын сәхнәләштергән өчен Тукай премиясенә лаек була. – **Авт.**) алган. Ул – Тукай премиясен алган беренче хатын-кыз. Минем өчен номинант булу – бик зур вакыйга. Ләкин минем шәхесемдә генә түгел хикмәт. Миңа игътибар итәләр икән, бу инде – күн сәнгатенә игътибар итү. Мин әлеге сәнгать төре белән 1995 елдан бирле шөгыльләнәм. Аны Мәскәүдә дә, гомумән, беркайда да белмиләр диярлек. Безнең чиктәләрне казахныкы, кыргызныкы, үзбәкнеке дип тә язалар. Минем аларны дөньяның бик күп музейларында күргәнем бар, әмма башка халык сәнгате итеп тәкъдим итәләр. Мин безнең күн сәнгатенең абруйлы булуын телим. Ул – безнең горурлыгыбыз. Ул – борынгы сәнгать һәм Болгар чорыннан ук бара. Бу премия әлеге юнәлешне күтәрүдә ярдәм булыр иде.

Архитектура өлкәсендә быел Түбән Кама шәһәренең милли архитектура әсәрләре өчен Фирдәвес Ханов һәм Татарстанның агач архитектурасына багышланган җиде томлык альбомы өчен Равил Айдаров көч сынаша.

Фирдәвес Ханов – шулай ук берничә ел рәттән премиягә дәгъва кылучы кандидат. Ул сынлы сәнгатьтә кадрлар җитәрлек, әмма милли кадрлар бармак белән генә санарлык дип исәпли. Фирдәвес Ханов, һичшиксез, милли кадрларның берсе. Шәһәрләрнең милли йөзе турында сүз алып барсак, шундый шәхесләргә игътибар итү зарурдыр, бәлки. Хәер, анысын инде премия комиссиясе хәл итәчәк.

Без юнәлешләр һәм кандидатлар белән таныштырдык. Социаль челтәрләрдә тавыш бирү дә оештырачакбыз. Сезгә кайсы кандидатура якынрак, катнашсагыз һәм фикерегезне калдырсагыз иде, кадерле укучыларыбыз.

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

НАИЛ ШӘРИФУЛЛИН

ЯКУТЛАРГА КИТКӘН ВАКЫТЛАР

(ПОВЕСТЬТАН ӨЗЕК)

Дәвамы. Башы 17 март санында >

– Менә бит, ниһаять, икебез дә бер сүз сөйли, бер дулкында аралаша башладык.

– Миндәге кирелек белән үзем дә аптыраган. – Алинәнең кыйгач күзләре нур бөркеп елмая иде. – Йә ышандыра беләсең, йә башка берәр сәбәп...

Алар улак буйлап агучы таныш инешкә килеп җиттеләр. Инеш һаман да элеккечә салмак кына чылтырый иде. Чылтырамый хәле юк агымсуның. Ясалмага әверелдерелгән, бетонга охшаш ят материалга төрелгән, кечерәйгән очракта да үзе булып кала ул. Улакның берсе тәмамланып, икенчесе – аз гына тәбәнәк урнашканы башланган урындагы бусагаларда яралган кечкенә шарлавыклар җанга якын тавыш белән шаулый, чылтырыйлар иде.

Ерганакка калган инеш аша салынган матур курчак күпер янәшә булса да, алар анда менеп тормадылар. Зөфәр кызны кулыннан алган хәлдә, улак аша сикереп кенә чыктылар. Егет учына икенче тапкыр яткан нәфис кулны икенче як ярга чыккач та җибәрмәде. Алинә дә ашыгып тартып алмады. Киресенчә, йомшак озын бармаклар кинлек әле булмаган. Мөмкинлек тууга, мин менә сезнең хозурда...

Эчке бер тоем белән Зөфәр сиземләде: ышануы кыенрак булса да, яңа танышын алдакчы итеп кабул итәсе килми иде кебек кызның.

– Мин сине резервациядә туып-үскән кеше дип уйлап бара идем. Вакыт буйлап сәяхәткә чыккансың, димәк. Шулай да булсын. Андыйны мөмкин эш дип ишеткәнем бар. Ә ни өчен нәкъ менә Ташлыярга? Ник башка җиргә түгел? Ник безне, безнең йортны сайлап алдың? Мине монда алып чыгып үртисең килепме? Шаяртасың килеп сөйлисең, ахры, боларны. – Алинәнең йөзенә кабат елмаю кайткандай булды.

– Чөнки мин, чыннан да, шушы авылда дөньяга килгән кеше. Тик моннан йөз дә унбиш ел элек. Туганнан соң биредә унсигез ел яшәгән затмын. Һәм мин авылымны аз гына да танымыйм. – Зөфәр моны артык җитди, хәтта кырыслык итеп тә әйтте. – Танымауга әтиең сөйләгәннәрне дә китереп кушсаң әле...

– Минем сиңа ышанасым килә, тик...

– Авыл, ярар, үзгәрсен дә, тик аның тирә-ягы да бөтенләй үк башка – төз җирләр – түмгәк, түмгәк җирләр – төз дип ко-

Зөфәрнең учын әле аз гына кыскандай итәләр дә кебек. Инешне кичеп, биш-алты адым узгач кына куллар кулдан аерылды.

Шунда Зөфәр тәвәккәлләде. Билгеләп чакта ук алып киткәннәр, фәлән-төгән, дип гүзәл затның гүзәл күзләренә төтен җибәрү өченме ул биредә? Алинә хакыйкатьне, ул артык гаҗәеп кимәлдә булса да, кабул итәчәк, аңа ышаначак. Тик шулай да башта дежур сорау биреп карарга булды ул.

– Сиңа мин киенгән кием гаҗәбрәк тоелмыймы? Мине каян, кай тарафлардан бирегә килеп чыккан дип уйлыйсың?

– Дөнья зур, шәһәрләр күп, туган җирен якын иткәннәр бирегә каян да килеп чыгарга мөмкин. Магнит мендәрле юл буйлап көненә йөзәрләгән электромобиль уза авыл кырыеннан. Киемеңә килгәндә, бераз ятрак, башка, искерәк модага ияреп тегелгән кебек, тик һәркем үзенә ничек ошый, шулай киенә. Аның өчен кешене гаепләп булмый.

– Алинә, киемем генә түгел, мин үзем дә – бик иске кеше.

– Моны ничек аңларга?

– Мин үткәннән килдем. Туксан биш ел элек булган көннәрдән. – Зөфәрнең әле тагын: «Син минем оныгымның оныгы белән яшьтәш», – дип тә өстисе килгән иде. Чибәр кыз янында алай ук тугарылып китү, бабайга әйләнү ярамас, ике арада, мөнәсәбәтләрдә яралып килгән җылылыкны юкка чыгарыр, дигән уй гына аны чабуыннан тотып калды.

– Безнең бүгенге кунак әле шаяртучан да булып чыкты...

– Әтиең белән аралашканда, бәлки шаяртканмыйдыр да. Бүтән алай кыланасым килми. Егерме беренче гасыр башы кешеләреннән кайнар сәлам сиңа...

Моңарчы елмаеп сөйләшкән кыз аңа җитди итеп карап куйды. Әлбәттә, ышанмады.

– Ник әле унберенче яисә унбишенче гасырдан түгел ул сәлам?

– Мин җитди сөйләшәм. Егерменче йөздә, аның ахырында да андый мөм-

тыла торган гына түгел. Урманнар, агачлыклар, иген кырлары кая киткән? Кая гына карама, мин теләмәгән үзгәрешләр күзгә килә дә төртелә... Синең ышанмавыңнан бигрәк мине шулар гаҗәпләндерә.

– Ярар, әлегә ышанып торыйм инде алайса. – Кыз хәйләкәррәк караш белән Зөфәргә карап куйды. – Сүзләрең чын икән, гаҗәпләнми хәлең юк. Барысы да элеккечә калса, тагын да ныграк гаҗәпләнер идең әле... Һәр дәвернең – үз манзарасы, үз кешеләре, үз тәртипләре. Ни өчен әле без үз акылыбыз белән яшәмичә, барысын да консервацияләп, әллә кайчангы тәртипләр белән яшәргә тиеш?

– Җирдә яшәп киткән буыннарны, бер, ике гасыр элек гомер иткәннәрне сезнең чор кешеләреннән гадирәк, беркатлы, акылсызракка чыгару, үзең дә сизәсеңдер, хата. Мин әле кайчакта, киресенчә түгел микән, дип тә уйлап куям. Без – син әйткән «борынгы»лар үз алдыбызга куйган бурыч гади һәм мәрхәмәтле – җирне, табигатьне, андагы күптөрлелекне, гүзәллекне саклап калу. Бары шул гына.

– Сезнең миссияне – ни өчен йөргәнне, үзең әйткән сәяхәтнең максатын аңлыйм, сиңа да ышана башладым кебек. Бүгенге көннең, чорның ни өчен нәкъ менә сез теләгән кимәлдә булырга тиешлегенә дә бераз төшенәм. Үсемлекләр, тереклек ияләре кубрәк булсынга, исән калсынга, җирне элеккечә урманнар капласын, елгалар мул сулы булсынга тырышасыздыр. Иң кечкенә халыклар да яшәсенгә. Тик сез безнең хакта уйладыгызмы? Сез кертергә мөмкин, кертәчәк төзәтмәләр безнең бүгенге дөньяны гел башка, безнең өчен бөтенләй чит итәчәк бит. Без биредә андый үзгәрешләрне телибезме? Мин – Алинә, беркөнне йокыдан уяныйп китәм дә гел башка, ят дөньяны, башка чынбарлыкны күрәм. Уянып китәм дә, шул көннән башлап сез теләгәнчә тәттереп татарча сиптерәм буламы? Бу бит мөмкин түгел.

– Алай түгел, Алинә. Җиһан үсеше, андагы үзгәрешләр, киләчәк өчен җан атучы галимнәр теләге тормышка ашкан җәһәттә, башка колея буйлап китәчәк. Барысы да салмак рәвештә үзгәрәчәк. Әти-әниең татарча аралашу сәбәпле, сабый чакта ук телең, Ходай кушып, татарча ачылачак. Чөнки җиһан бүтән юнәлеш сайлап, шуның нигезендә алга киткән булачак.

– Хәзерге мин урынына башка мин була, димәк. Мин – бүгенге көннең, бүгенге чынбарлыкның бер кисәкчеге юкка чыгачакмын, шулаймы?

– Син юкка чыкмыйсың. Бүгенге син ул – синең мөмкин вариантларыңның берсе генә. Тышкы шартларга, әйләнәтирә мохиткә карап, җан иясе күпсанлы вариантларның берсе буенча үсеп формалаша.

– Димәк, мин, сезнең хәер-фатиха, тырышлык белән Алинәнең икенче номерлы версиясе рәвешенә керәчәкмен. Әллә егерме икенче номерлысы булачакмынмы?

– Ничәнче генә булмасын, синең камил, киләчәге шәйләнгән дөньяда яшәвең кыйммәт, Алинә. Бөтен төс, бизәкләрен, күптөрлелеген саклаган дөньяда.

– Бар тирә-як, дөнья үзгәргәч, икенче тапкыр килүеңдә син мине эзләп таба да, күрә дә алмаячаксың икән. Исемем дә башка булса... – Кызның татарлыгы кычкырып торган кыйгач күзләрендә янә шаян чаткылар кабынды.

– Табачакмын, син йөз дә егерме икенче версиядә булсаң да тапмый калмам. – Бер үк вакытта шаян да, җитди дә булган шушы сүзне әйткәч, Зөфәр, янәшә атлаган кызның сак кына җилкәсенә кагылды, аннары, кыюланып китеп, кулын аның нечкә биленә төшерде, биленнән алып, талчыбыктай сылу гәүдәне үзенә таба тартты. Шул чакта ул Алинәнең чәчләренең табигый, шул ук вакытта исерткеч исен тойды. Нәфис тәннең мизгелгә генә үзенә сыенып алуының бар ләззәт, рәхәтен татыды. Шул рәвешчә үзенең кызга мөнәсәбәтен, бик тә ошатуын белдерәсе килде кебек аның. Кулын алгач, тәвәккәлләп, әйтте:

– Мондый гүзәлне тапмый мөмкин түгелдер ул. Андыйлар бары туган авылымда, Ташлыярда гына туа һәм яши...

Алинә сүзне башка яккарак борды:

– Кайчандыр авыл бик зур булган. Мин Ташлыяр тарихын глобаль базадан эзләп табып карадым. Йортлар саны гына да ярты меңнән артып киткән. Кеше дә күп яшәгән.

– Әйе, бигрәк тә егерменче гасыр башында. Халык саны ике мең ярымга җиткән чорда. Шул дәвердән бирле кечерәю, кимү бара. Хикмәт кеше санында түгел, хикмәт гармониядә. Кешеләрнең, халыкларның үзара һәм табигать белән санлашып яшәвендә. Бирегә килгәннән бирле чыпчыктан башка кош күрмәдем. Һуш китмәле фәкыйрьлек. Чебен булып, алар да очмый. Чирәмгә ятып, туйганчы бер аунармын дигән идем, анысы да ихтимал, хыялда гына калыр.

– Йортлар янында бер дигән газоннар. Мин үзем дә аска ни булса да җәеп, шунда чыгып утырырга ятарам. Кайчагында җәеп тә тормыйм. Кайтып җиткәч, сиңа да җәеп бирермен, алай бик тансыклагач. Чебен дигәндә, алар бар. Былтыр җәй берсе ике атна буе өйдә яшәгән иде, аннан соң каядыр югалды. Кошлардан соры түшле бер чыркылдык ел саен өй янына оя кора, күгәрченнәр сирәк кенә ашарга сорап килә...

– Чыркылдык дигәнең чыпчыктыр инде ул. Ә нәкъ шушы вакытларда басуны моңга тутыра торган тургай, балаларына кабаланып ризык ташучы яз хәбәрчесе сыерчык кайда? Карга, саескан, чәукәләр ник күренми?

– Биредә андыйлар яшәми шул. Син санаган кошларның кайберләре турында ишеткәнем бар. Алар ихтимал башка урыннарда, йомшаграк климатлы тарафларда гына калгандыр...

Ахыры бар >

ЭЧ ПОШКАНДА

эшләргә файдалы 7 гамәл

- Белгән догаларыгызны укыгыз.
- Борчуның сәбәбен билгеләгез. Сәбәп җитдиме?
- Минуслардан плюслар эзләп карагыз.
- Дүрт тапкыр тирән сулыш алыгыз.
- «3-3-3» дигән күнегү эшләгез: шушы мизгелдә күргән 3 әйберне атау, ишеткән 3 тавышны тасвирлау, 3 әгъзагызны тотып карау.
- Кулыгыздагы пульсны капшап, санап карагыз.
- Соңгы вакытта ишеткән иң күңелле шаярыну исегезгә төшерегез.

Әз-мәз мәзәк

Безнең директорның ике кәчтүме бар. Кыйбатлысын киеп, ул акча сорарга бара. Ә безгә акча сорарга килсәләр, арзанлысын кия.

* * *

– Тышындагы түгел, эчендәге мөһим!
– Мисал китер.
– Суыткыч.

* * *

ЗАГСта бәдрәфкә кергән идем, тәрәзәдә тимер читлек. Бөтен нәрсә уйланылган!

* * *

Минем бөтен өзгәләнүләремне ике төргә бүләргә була:
1) зрә әйттем;
2) зрә дәшмәдем.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: чаң, улак, буран, Алиш, Рубин, ямансу, яулык, ис, әрәпә, үтә, Изаура, басым, ун, Рио, Базилио, ничек, ми, Денди, Арча, Аврил, килү, Нурия, алпавыт, Чаллы, Оз, ля, кавык, зимагур, кош, фа, Динә, Рөстәм, рәт.

Вертикаль: Урманче, Ясин, ир, чиле, Алабама, нык, Муса, Сәрби, ау, Айфара, ура, Лавров, Сабир, ризык, Ост, кушу, пародия, код, ел, шикәр, Азалия, Бонн, Аяз, мә, нужа, Идел, имән, Сочи, ката, күмәк, Ив, алышу, Шәйхи, үт.

«КАРПАТКА» һәм «КАРНИКА»
токымлы 4әр рамлы умарталар сатам.
Бал корты личинкалары – 2–3 рам.
Бал икмәге – 1 рам.
+7 96 55 99 88 67
+7 96 25 61 60 93
Реклама



Беләсең килсә...

1 Өчпочмакның почмаклары суммасы ничә градусны тәшкил итә?
а) 90;
б) 180;
в) 360.

2 ЛДПР партиясе элек ничек аталган?
а) ЛДСП;
б) ЛДПС;
в) ЛДПСС.

3 Казандагы Карл Маркс урамы 1918 елга кадәр нинди исемне йөрткән?
а) Әрмән урамы;
б) Грузин урамы;
в) Казах урамы.

4 Бу илдә акчага аяк белән басу канун нигезендә тыелган:
а) Таиланд;
б) Алжир;
в) Венесуэла.

Җаваплар: 1.б); 2.в); 3.б); 4.а).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15281 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 241

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+